АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
имени Г. ИБРАГИМОВА

**ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ**

# НАШЕ ИМЯ – ТАТАРЫ

Казань
2022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ**

# БЕЗ – ТАТАРБЫЗ

Казан
2022

**УДК 17.035.3**
**ББК 63.52(=632.3)**
**И 15**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

«Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2014 – 2022 еллар)»
Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында
нәшер ителә

**Төзүчеләр:**
*М.И. Ибраһимов, Ф.Г. Фәйзуллина*

**Текстларны, аңлатмаларны һәм искәрмәләрне әзерләүчеләр:**
*Ә.Х. Алиева, К.Г. Әхсәнов, Э.М. Галимҗанова,*
*З.Г. Мөхәммәтшин, Ф.Г. Фәйзуллина, Г.М. Ханнанова,*
*Г.А. Хөснетдинова*

**Рус теленә тәрҗемә:**
*М.И. Ибраһимов, Б.Ю. Хәйретдинев, Р.И. Такташ*

**Ибраһимов Г.Г.**
И 15 Без – татарбыз = Наше имя – татары / Д.Ф. Заһидуллина редакциясендә. – Казан, 2022. – 308 б.: ил.
ISBN 978-5-93091-407-8

Китапта татар әдәбияты классигы, галим, җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимовның милли үзаң, татар теле, әдәбияты, тарихы, мәдәнияте мәсьәләләренә багышланган хезмәтләре тупланган.
Хезмәт әдип иҗаты, татарларның XX йөз башы иҗтимагый һәм мәдәни тормышындагы миллият фикере белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

**УДК 17.035.3**
**ББК 63.52(=632.3)**

**ISBN 978-5-93091-407-8**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2022

## «ҺИЧБЕР ВАКЫТ БЕЗДӘН "ТАТАР" ДИГӘН СҮЗ АЛЫНА АЛМАС»

*«Бу соңгы унтугызынчы гасыр тарихында иң мөһим роль уйнаган фикер, һич шөбһәсез, милләт фикере булды... Хәлбуки милләт фикере – бөтен җир йөзендә бер дәрәҗә таралган бер куәтле фикердер, яхуд фикер-куәттер... Милләт фикере нинди зур вакыйгаларда гамәл булганын санап бетерү мөмкин түгел. Әле һаман да ул үзенең хөкемен йөртеп тота. Мин уйлыйм ки, истикъбальдә һәм бик озак заманнар, бик күп гасырлар эчендә милләт фикере кешелек тарихында хөккям фикерләрдән бере булачактыр».* 1913 елны күренекле татар иҗтимагый һәм сәяси эшлеклесе Садри Максуди тарафыннан әйтелгән бу сүзләр милли үзаң мәсьәләсенең XX гасыр башы Россия иҗтимагый-сәяси, мәдәни һәм гаклый тормышында нинди зур әһәмияткә ия булганлыгына дәлил итеп китерелә ала. Милли үзаң рус фикер ияләре Н. Бердяев, Н. Трубецкой, Г. Шпет, П. Струве, С.Н. Булгаков, Д. Овсянико-Куликовский, И.А. Бодуэн де Куртенэ һ.б.ның фәлсәфи һәм фәнни эзләнүләрендә үзәккә куела. Бу мәсьәләгә татар зыялылары Р. Фәхреддин, Г. Гобәйдуллин, Җ. Вәлиди, Г. Шәрәф, Г. Рәхимнәр һ.б. да мөрәҗәгать итә.

Әлеге фикер ияләре арасында Галимҗан Ибраһимов шәхесе аерым бер урын тота. Беренчедән, язучы, галим, публицист, сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе буларак, ул үз эшчәнлегенең төрле тармакларында милли тел, әдәбият, тарих, татарларның

---

*Хөккям* – өстенлекле.

*Гаклый* – интеллектуаль.

милли үзаңы, үзбилгеләнүе мәсьәләләренә зур игътибар бирә. XX гасыр башы татар зыялылары йолдызлыгында милли аң проблемасын иңләү киңлеге ягыннан Г. Ибраһимов белән тиңләшерлек кешеләр, бәлки, юктыр да.

Икенчедән, XX гасыр башы татар вакытлы матбугаты битләрендә башланган татар үзаңы хакындагы бәхәсләрдә Г. Ибраһимов үзен татарчылык әйдаманы, эзлекле рәвештә «татар» этнонимын һәм төрки телләрнең мөстәкыйль үсүен яклаган шәхес итеп таныта. Күп кенә язмаларында ул гомумтөрки әдәби тел идеяләрен хуплаучыларга (И. Гаспринский, Р. Фәхреддин һ.б.) каршы чыга, бу идеяләргә төрки телләрнең күптөрлелеге фикере белән җавап бирә.

Өченчедән, 1920 елларда милли мәдәнияткә нисбәтле яңа дискурс формалашуга карамастан, Г. Ибраһимов милли мәдәниятләрнең һәм телләрнең төрлелеге идеясеннән баш тартмый, аларның үз үсеш юлларын мөстәкыйль билгеләвен яклап чыгыш ясый.

## *«Без – татармыз»*
## *(Г. Ибраһимов хезмәтләрендә милли үзбилгеләнү мәсьәләләре)*

1910 елларда Г. Ибраһимов «Шура» журналы битләрендә татарларның милли үзбилгеләнүе турында кабынган бәхәсләрдә актив катнаша. Ш. Мәрҗани фикерләрен дәвамчан үстереп, ул «татар» этнонимын төркичелек һәм болгарчылык тарафдарлары һөҗүмнәреннән яклый: *«Егерменче гасыргача "татар" дип аталып килгән бер кавемне "Инкыйраз" иясе егерме икенче гасырда "болгар" ясап мөнкариз кылды. Гәзитә вә журналларымыздан күбесе "төрекчә" яки "җәридәи төркиядер" дип йөртеләләр. Шагыйрьләремездән бәгъзеләр берничә еллар "татар" дип язып килгән иде, бөекләремездән берәүнең тәнбиһе саясендә, "татар" дигәнне "төрек"кә алыштырды»*[1].

Татарларны «төрки» дип билгеләүчеләр белән сүз көрәштергәндә, Г. Ибраһимов төп дәлил итеп «татар» этнонимының бө-

---

[1] *Ибраһимов Г.* Без – татармыз // Шура. 1911. № 8. Алга таба Г. Ибраһимов хезмәтләреннән өзекләр аның 15 томлы академик басмасыннан томы һәм бит саны белән күрсәтелә.

тен җирдә таралуын, киң кулланылуын телгә ала: *«Дөнья безне “татар” дип атый. Бер эш эшләгән булсак, безнең хакта: “Татарлар фәлән итә!” – дип сөйләгәннәр һәм сөйлиләр»* (11, 161).

Бер ел узгач, «Шура» журналының 9 нчы санына Г. Ибраһимов «“Без кем?” бәхәсе» дигән зур булмаган мәкалә урнаштыра, анда үзенә карата әйтелгән тәнкыйть сүзләренә җавап бирә. Асылда, «Без – татармыз» мәкаләсендә китерелгән дәлилләрне кабатлый: *«Әмма аңа карап, һичбер вакыт бездән «татар» дигән сүз алына алмас... Андый бер мәртәбә бирелгән исемнәрне, яңлыш булса да, әүвәлгечә дәвам иткәнлегенә адәмнәрдә, фәнни истыйляхларда, милләтләрнең, мәмләкәтләрнең, хәтта Америка шикелле бөтен бер кыйтгаларның, исемнәрендә дөнья тулы мисал. Шуңа күрә ул моназарәне үзенең фәнни җәһәтенә хозар кылып, “безне татар димәгез” җәһәте күптән сөкүт ителергә иде. Юк гауга, җирне күчәреннән бераз читкә чыгару планыннан да еррак хыял!..»* (11, 177).

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Г. Ибраһимов татарларның төрки дөньяның аерылгысыз өлеше булуын кире какмый, аның сүзләренчә, ул дөнья славян, алман яки романнарныкы кебек үк төрле: *«Төрек наме, славян, герман, романнар кебек, гомуми бер исем булып, соңгылар эчендә төрле исемнәр белән йөргән әллә ничә милләт булдыгы кебек, төрек (төркеме) дә төрле исемнәр белән йөртелгән кавемнәргә аерылган»* (11, 163). Бер үк вакытта төрекчелекне татарларның милли үзбилгеләнүенә яный торган куркыныч дип күрсәтә: *«Димәк, хас исемебезне ташлап, «төрек» дип атала башласак, без башка төрек кабиләләре белән исемдә аерыла алмыйбыз»* (11, 163).

Исмәгыйль Гаспринский, Риза Фәхреддиннең һәм аларның фикердәшләренең татарлар аерым милләт буларак тәңгәлләшкән очракта төрки әдәбиятара (мәдәниятара) бердәмлекнең таркалу ихтималы уңаеннан борчылулары да Г. Ибраһимовка нигезсез тоела: *«Исмәгыйль бәк буны: “Татар, казакъ вә фәлән дип аерылачак булсак, Яубашы белән Эстәрлебашының һәрбере үзенә*

---

*Хозар кылып* – калдырып.

*Сөкүт ителергә* – туктатылырга.

*бер әдәбият, үзенә бер мәдәният тудырырга калыкшачак", – дип тәгъбир итә. Риза казый: "Татар әдәбияты дигән аерым бернәрсә вөҗүдкә килсә, мондый шивә аерылуның зарурый нәтиҗәсе уларак, башкорт әдәбияты, мишәр әдәбияты, типтәр, нугай вә башка аерым әдәбиятлар туачак", – ди*» (7, 53).

Г. Ибраһимов аерым этник төркемнәрдәге (мишәр, башкорт, нугайларның һ.б.) уртак татар үзаңын (татарлыкны) географик (гомуми яшәү урыны), сәяси (бердәм дәүләт – Россия кысаларында тормыш) факторларга, шулай ук Урал-Идел буе төрки халыкларының матди һәм рухи тормышына йогынты ясаучы икътисади һәм мәдәни үзәк буларак Казанның тарихи статусына таянып аңлата.

### *«Көне килер, без тәмам эшләнгән "милли тарих"ка малик булырмыз»*

*(Тарих һәм иҗтимагый тормыш мәсьәләләре)*

1911 елның ноябрендә «Вакыт» газетасында Г. Ибраһимовның Фатих Кәрими язган «Мохтәсар тарих гомуми» дәреслегенә рецензиясе дөнья күрә. Гомумән алганда, бу хезмәтне уңай бәяләсә дә, рецензент аның төп җитешсезлеге итеп авторның борынгы чорлар тарихи шәхесләренә – Атилла, Чыңгыз хан, Аксак Тимергә карата тискәре мөнәсәбәтен күрсәтә. Г. Ибраһимов фикеренчә, укучыларга адресланган китап аларда үз халкының үткәненә карата горурлык хисе тәрбияләргә тиеш: *«Мондый китап язучы кеше иң әүвәл үзенең татарлыгын хәтергә алырга, шуңа күрә тарихын татар баласына татарлыкка мәхәббәт иттерерлек кылып эшләргә тиешле...*» (11, 175).

Бу рецензиягә җавап итеп, тарихчы Газиз Гобәйдуллин «Шура» журналында (1912, № 6) «"Тарих гомуми" тәнкыйтенә каршы» мәкаләсен бастыра, анда, Г. Ибраһимов карашларында тар милләтчелек күзәтелә, дип белдерә. «Ихтилаф вә риваять» («Шура», 1912, № 10) мәкаләсе белән бу гаепләүләргә җавап биреп, Г. Ибраһимов болай ди: *«Һәр милләт "үзем!!!" ди. Һәр милләт үзен күтәрә. Бу күтәрүгә әдәбиятны да, фән-*

*не дә, фәлсәфәне дә, мәдәниятне дә корал итә. Тарихны да шуңа хезмәтче ясый. Бу – заманның, әлбәттә, ямьсез булган бер агымы. Ул булмаска тиеш иде. Ләкин бар. Ләкин ул – факт. Шуны күрә торып, инде бу бичара татарлар гына, юк ул “тар милләтчелек” дип, киң күңеллелек күрсәтәмезме?»* (11, 180–181).

Романовлар династиясенең 300 еллыгы уңаеннан Г. Ибраһимов «Рус, төрек вә татар тарихыннан» исемле зур мәкалә әзерли. Киевта[1] язылып, «Йолдыз» газетасында (1913, 3, 5, 17 март саннары) дөнья күргән язма төрле халыклар тарихында хәрәкәткә китерүче көчләрне чагыштыру тәҗрибәсе кебек тоела. Рус тарихын төрки-татарлар тарихы белән чагыштырганда, ул төркиләрдә тарихи процессны хәрәкәткә китерүче төп көч булып аерым шәхесләр (Атилла, Чыңгыз хан, Батый, Аксак Тимер), ә русларда халыктагы руслык тойгысы дигән нәтиҗәгә килә: *«Русия рус дәүләте дә, рус шәүкәте үзенең хәзерге бөек мәртәбәсен алуда, аерым шәхесләрдән бигрәк, рус халкының рухына, халыкның руслык куәтенә бурычлыдыр. Әмма безем бөтен тарихыбыз, бигрәк тарихыбызның шәүкәтле минутлары, гомумән, беренче куәтнең аерым шәхсиятләремез дә була килгәнен күрсәтәләр. Безнең тарихыбызда халык куәте, халык рухы дигән мәфһүм үк юк»* (11, 196). Шунысы игътибарга лаек: Г. Ибраһимов тарих белән генә чикләнми: мәкалә ахырында ул әдәбият турында фикер уртаклаша, рус әдәбиятын югары бәяләп, анда милләт (халык) рухының ачык чагылышын билгели: *“Милләт рухы вә милләт табигатенең көзгесе булган әдәбиятка күз салсак, рус кавемендә халык, халык куәте дигән мәфһүмнең ни дәрәҗәдә тирән тамыр җәйгәнлеген, халыкчылык боларның каныына сеңгәнлеген ачык күрәчәкмез»* (11, 198–199).

---

[1] 1912 елның көзендә Г. Ибраһимов Казаннан Киевка китә, анда татар теле һәм әдәбиятыннан дәресләр бирә. Киевта ул мөселман студентлар түгәрәгенә йөри, шуның өчен полиция күзәтүенә эләгә. 1913 елның 17 апрелендә түгәрәкнең 16 әгъзасы белән бергә кулга алына, Киев губерна төрмәсенең бер кешелек камерасына утыртыла, аннан шул елның 13 июнендә азат ителә. Июньнең 20 ләрендә Киевтан китеп бара.

Г. Ибраһимов позициясенә тәнкыйть күзлегеннән карарга да мөмкин (татар әдәбиятында да халык рухын чагылдырган әсәрләр аз түгел бит). Әмма биредә язучының тарихны позитивизм кысаларында ниндидер объектив көчләр һәм закончалыклар гамәлләре итеп аңлатудан котылырга омтылуы мөһим. Әлеге тәгълиматка каршы килеп, Г. Ибраһимов тарихның менталь нигезләренә кагыла, анда (әдәбияттагы кебек үк) милли характерларның тасвир-сурәтен таба.

Революциядән соң аның гыйльми карашларында бу фикер югала: 1910 ел ахыры – 1920 елларның беренче яртысында барган социаль-сәяси процессларда актив катнашкан Г. Ибраһимов татар тарихына һәм иҗтимагый хәрәкәтенә караган хезмәтләрендә инде марксистик методология тарафдары буларак чыгыш ясый.

Мәсәлән, «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» («Безнең юл», 1922, № 1–2) мәкаләсендә ул татар җәмгыяте һәм әдәбияты барышын өч баскычка бүлеп карый: Борынгы заман (Урта гасырлар), Мәгърифәтчелек чоры (аның чишмә башында – татар мәгърифәтчеләре Курсави, Мәрҗани, Акмулла һ.б. эшчәнлеге), Инкыйлаблар дәвере (1917 елның Февраль революциясе вакыйгаларыннан башлана). Бу хәрәкәт Г. Ибраһимов тарафыннан алга китеш, үсеш итеп күзаллана, һәр киләсе этап җәмгыять һәм мәдәниятнең узган чорына караганда югарырак баскыч дип бәяләнә.

### *«Тел – халыкның рух, фикер һәм хисләр хәзинәсе»*

Г. Ибраһимов хезмәтләрендә тел үзтәңгәллеге мәсьәләләре мөһим урын алып тора. Морфология, синтаксис, татар теле орфографиясеннән шактый хезмәтләр авторы буларак, галим күп кенә мәкаләләрендә татар һәм башка төрки телләрнең мөстәкыйльлеге, аларның тигез хокуклылыгы идеясен эзлекле рәвештә яклый. Бу уңайдан «Фәнни истыйляхлар» («Аң», 1913, 18 декабрь) мәкаләсе аеруча кызыклы. Анда татар телендә фәнни терминология булдыру мәсьәләсе алга куела. Асылда, Г. Ибраһимов махсус фәнни тел булдыру кирәклеге турында яза һәм бу бурычны милләт төзелешенә бәйләп куя: *«Бер төркем халыкның аерым бер милләт мәртәбәсенә күтәрелүе өчен, –*

*дип яза ул, – ана телендә әдәбияты булу гына җитми, аның үз телендә фәне дә булырга тиеш*» (9, 166).

Татар телендә фәнни терминологиянең кирәклеген нигезләсә дә, Г. Ибраһимов гарәп телендәге барлык терминнарны татар телендәге вариантлар белән алыштырырга теләгән галимнәргә (лингвистикада, мәсәлән, гарәп терминнарының татар эквивалентларын кертергә тәкъдим иткән Гыймад Нугайбәк) кушылмый. Татар теленең өстенлеген таныган хәлдә, Г. Ибраһимов бары тик татар телле терминнар куллануны бердәнбер дөрес юл дип карамый: аның өчен милли тел – башка телләр белән (шул исәптән фәнни терминология өлкәсендә дә) үзара бәйләнештә үсә торган ачык система. Шуңа күрә галим тел үсешенең үз тенденцияләрен исәпкә алмаган ясалма лингвистик төзелмәләргә каршы чыга.

Бу турыда ул, татар теленең чисталыгын саклау яклыларга беркадәр ирония белән төрттереп, «Татар теле һәм татарча язу хакында бер-ике сүз» («Йолдыз», 1910, 30 март) мәкаләсендә искәртә. «*Татарча язу вә садә телдә язуның мәгънәсенә һичбер чит лөгать кертмәү дип аңлау билкөлле хата идеке мәгълүм булса кирәк*, – дип яза Г. Ибраһимов. – *Садә телнең төп максаты һәркем аңларлык ачык язудан гыйбарәт булып, баш кагыйдәсе – мәҗбүрият булмаган урында тәкәллефан чит лөгатьне кертмәү ләзем димәктән гыйбарәт идеке дә мәҗһүл дәгелдер*» (9, 34). Телнең чисталыгын тикшерүчеләрнең урынсыз гамәлләренә бер мисал итеп, ул тәрҗемә әсәрләрендә еш очрый торган «мөтәрҗим» (тәрҗемәче) сүзен татар телендә «татарлаштыручы» дип үзгәртү очрагын китерә. *«Менә бу бичара бәндәләр*, – дип яза автор, – *“татарча язу тиеш” дигән сүзне яңлыш аңлаучылардыр. Әгәр дә әдәбият мәсьәләләреннән вә ана телендә язуның мәгънәсеннән хәбәрләре булса, бундый тел әйләнми (торган), ишетергә мәкруһ һәм кирәкмәгәнчә озын вә килешсез сүзләрне әдәбиятка кертмәсләр иде. Һәр әдәбият үзен мондый тәнаферләрдән саклый вә боларга урын бирмидер. Безгә дә буны онытырга ярамый»* (9, 33).

---

*Тәнаферләрдән* – каршылыклардан.

Телләрнең күптөрлелеге идеясе «Телләре башка булса да, күңелләре бер» («Аң», 1916, № 5) мәкаләсендә чагылыш таба, анда Г. Ибраһимов телләрнең милли тәңгәллеген бетерүгә, халыкка нинди дә булса башка телне көчләп тагуга каршы чыга: *«Һичбер халыкның авызына һичбер вакытта аның табигый телен тартып алып, үзең теләгән яңа бер тел куяр хәл юк»* (7, 117). Татар һәм казакъ тел белеме арасындагы мөнәсәбәтне татар галиме аларның үзара бәйләнышы, бер-берсен баетуы дип карый: казакъларның үзенчәлекле халык авыз иҗатын өйрәнү, Г. Ибраһимов фикеренчә, татар әдәбиятының милли хәзинәсен баетырга мөмкинлек бирәчәк: *«Безгә, казакъларны татар теле вә татар әдәбияты астына кертү хыялыннан бигрәк, әдәби хәзинәмезне баету өчен, казакъ халкы әдәбиятын киң рәвештә өйрәнү тиешледер»* (7, 118).

Г. Ибраһимов хезмәтләрендә милли тел проблемасы аны укыту мәсьәләсе белән дә тыгыз бәйләнгән. Галимнең методик хезмәтләре үзенең укытучылык тәҗрибәсенә нигезләнә: 1915–1917 елларда Г. Ибраһимов Уфаның «Галия» мәдрәсәсендә укыта (бу мәдрәсәдә ул 1906–1908 елларда белем алган була).

«Татар телен ничек укытырга» (1916) мәкаләсендә Г. Ибраһимов, тел һәм фикерләү бәйләнеше турындагы идеяне теоретик нигезгә алып, туган тел дәресләрен укучыларда милли үзаң үстерүнең төп факторларыннан берсе буларак карый: *«Тел вә миллият адәмдә табигый. Боларның орлыгы һәркемнең табигатендә бар. Ләкин яхшы тәрбия ителмәсә, йирдә булган орлыкларның йимеш бирми калуы, бирсә дә начар булуы бик мөмкин. Төп максаты – хәятка хәзерләүдән гыйбарәт булган мәктәп бу мәсьәләдә тик торып кала алмый, бу йә теге якка үзенең тәэсирен күрсәтә»* (9, 242). Г. Ибраһимов өчен тел – халык рухының, аның фикерләренең һәм хисләренең тупланмасы, олы бер мирас. Туган тел дәресләрендә ул, барыннан да элек, баланы милли тормышның рухи нигезләренә җәлеп итү, якынайту мөмкинлеген күрә.

## *Милләтнең алтын баганалары*

Г. Ибраһимов телне, әдәбиятны, сәнгатьне милләтнең рухи нигезләре дип билгеләп, аларның үсешенә зур өлеш керткән татар мәдәният әһелләренә, зыялыларга аерым игътибар бирә. Әмма аерым шәхесләрнең татар халкы иҗтимагый һәм мәдәни тормышындагы ролен билгеләве һәрвакытта да дөреслеккә туры килми. Әйтик, ул татар әдәбиятында Г. Тукайның урынын аңлауда субъективлыктан котыла алмаган (бәлки, бу очракта Г. Тукай белән ике арадагы аңлашылмаучылыклар да тәэсир ясагандыр). Татар мәдәниятенең 1917 ел революциясеннән соң эмиграциягә китәргә мәҗбүр булган күренекле вәкилләрен (Г. Исхакый, С. Максуди, Ф. Туктаров һ.б.) совет идеологиясенә туры китереп каралтып күрсәтүдән дә читтә тормаган. Бер үк вакытта Г. Ибраһимов татар халкы язмышында, аның гаклый һәм рухи тормышында хәлиткеч роль уйнаган шәхесләрне: Ә. Курсави, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Г-р. Ибраһимов, З. Камали, М. Вахитов һ.б.ны югары күтәрә, аларның эшчәнлеген татар телен, әдәбиятын, сәнгатен, иҗтимагый һәм милли аңны үстерүгә керткән өлешләреннән чыгып бәяли.

Ш. Мәрҗани – Г. Ибраһимов өчен галим-реформатор гына түгел, ә, барыннан да элек, беренче булып татарларның милли үзтәңгәллеге, үзбилгеләнүе мәсьәләсен көн тәртибенә куйган тарихчы.

Каюм Насыйри – татар тел белемендә тамырдан үзгәреш булдырган шәхес (ул аның бөеклеген татар теленең, халык әдәбиятының мөстәкыйль, бөтенлекле үзтәңгәллеккә ия кыйммәтләр булуын раслауга юнәлдерелгән фидакяр хезмәтендә күрә).

Габдерәшит Ибраһимов аның тарафыннан, Муса Бигиев, Зыя Камали, бертуган Бубилар һ.б. белән беррәттән, татарларның милли үзаңында дини тәңгәллекнең аерылгысызлыгын аңлаган мөселман лидерларыннан берсе буларак, югары бәя ала.

Г. Ибраһимовның революциядән соң күп кенә татар зыялыларына карашы-мөнәсәбәте тамырдан үзгәрә. Сүз яңа идеологияне кабул итмәгән, аны татарларның милли һәм дини

үзтәңгәллеген җимерә дип санаган язучылар, җәмәгать эшлеклеләре турында бара (Гаяз Исхакый, Муса Бигиев, Фуат Туктаров, Садри Максуди һ.б.). Революциядән соңгы аерым хезмәтләрендә (мәсәлән, «Кара маяклар»да) бу шәхесләргә карата сөйләме агрессив төс ала, төрлечә бәяләү штамплары: «панисламистлар», «контрлар», «кәләпүшләр һәм фәсләр кигән «милли» акгвардиячеләр» һ.б. белән чуарлана. 1920 еллар башында барлыкка килгән мондый сөйләм стиле бөтен җирдә дошманлык, сыйнфый нәфрәт уята торган тел формалашуны күрсәтә. Революциядән соңгы сәяси процессларда Совет власте ягында актив катнашучы Г. Ибраһимов та бу риторикага еш мөрәҗәгать итә. Менә тагын бер мисал:

РКП(б) ӨК Секретариатының 1925 елның 20 февралендә узган утырышы беркетмәсе нигезендә Г. Ибраһимовка, «карт язучы һәм аның (Риза Фәхреддин) белән шәхсән таныш иптәш буларак», «мөселман интеллигенциясе белән мөнәсәбәтләргә, Хәлифәт һәм Көнчыгыштагы дини вазгыятькә кагылышлы кайбер мәсьәләләрне ачыклау өчен, шәхси әңгәмә оештыру” бурычы йөкләнә». Үзенең РКП(б) Обкомына тапшырган Ризаэддин Фәхреддин белән очрашу турындагы хисабында (документка 1925 елның 27 феврале датасы куелган) Г. Ибраһимов болай дип яза: *«Бу ике сөйләшүдән мин түбәндәге нәтиҗәләргә килдем: мөселман руханилары артык комсыз, алар Совет власте рус руханиларына биргән өстенлекләр белән генә канәгатьләнмиләр. Асылда, идеологик фронтның чын хуҗалары булырга һәм мөселман-татар өммәте өстеннән хакимлек итәргә телиләр. Монысы һичшиксез. Хәер, алар бу хакта ачыктан-ачык әйтмиләр, әмма бу һәрнәрсәдә сизелә. Шуңа күрә минем фикерем: әлеге мәсьәлә белән җитди шөгыльләнә башларга һәм аларның үтенечләренә карата бернинди йомшаклык күрсәтмәскә кирәк»* (15, 249–252).

Г. Ибраһимовның мәдрәсәләрдә төпле белем алуын, кайчандыр борынгы ислам мәдәнияте турында күләмле хезмәт язуын («Борынгы ислам мәдәнияте») белгән укучыга мондый бәяләр сәер тоелырга мөмкин. Әмма Совет власте дошманнарына каршы идеологик көрәшкә кушылган язучы яңа хаки-

мият тарафыннан ят идеология тарату куркынычы тудыручы дип каралган руханилар турында башкача сөйли алмаган, күрәсең.

Хәер, ике ел узуга, Г. Ибраһимов үзе дә, «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән китап бастыруына нисбәтле, партия һәм мәдәният әһелләре тарафыннан каты тәнкыйть утына эләгә.

### *Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?*

1927 елның 25 гыйнварында Г. Ибраһимов ВКП(б) Татар Өлкә Комитетының киңәйтелгән утырышында «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» дигән темага доклад ясый. Соңрак ул аерым китапчык булып басылып чыга.

«Интернационалист пролетариат хәрәкәте, пролетариат революциясе һәм социализм эчендә аерым милли мәдәниятләрнең язмышы ни булачак? Болар үзләренең милли төсләрен югалтачакмы? Яки шул нигездә үскән хәлдә интернациональ максудлар өчен хезмәт кылачакмы?» – Г. Ибраһимов үз мәкаләсендә менә шундый мәсьәләләр куя.

Аларга җавап биреп, ул туган телле мәдәниятне (беренче чиратта мәгарифне) үстерү зарурлыгына игътибар бирмәүче совет эшлеклеләрен тәнкыйтьли. Мондый позицияне кире кагып, Г. Ибраһимов аны патша Россиясендәге милли телләргә караш белән чагыштыра. Заманасы өчен абруйлы В.И. Ленин, И. Сталин, тарихчы-марксист М.Н. Покровский хезмәтләренә мөрәҗәгать итеп, пролетар революция милли телләр һәм мәдәниятләр өчен ачкан яңа киңлекләр турында сөйләгәндә, Г. Ибраһимов яңа татар мәдәниятенең милли үзтәңгәллеге турындагы мәсьәләне күтәрә: *«Татарлар, бу пролетариат хәрәкәте нигезендә милли мәдәният үстереп, социализмга баручы милли мәдәниятләр кәрванында аерым бер отряд булып дәвам кылырлармы, әллә татар хезмәт халкы мәнфәгате ягыннан караганда, башка берәр мәдәни хәрәкәт эченә кушылып китү файдалырак булачакмы? Кушылса, кемгә? Чувашкамы, французгамы, башкорткамы, урыска яки*

*үзбәккәме?»* (10, 266). Әлеге сорауларга җавап биргәндә, галим телнең милли мәдәният нигезе булуыннан чыгып эш итә. *«Без югарыда мәдәниятнең баш коралы тел икәнен күргән идек. Бичара татар теле үзен саклауда, үзен үстерүдә дә зур мәшәкатьләр, газаплар кичерде. Иске замандагы мирзалар һәм муллалар карашы турында тукталмыйм; миссионерларның бу телгә һәм татар язуына ни дәрәҗәдә ачу белән карап, бетерү өчен чаралар эзләгәненә кайтып тормыйм. Патшачылык хөкүмәтенең мәшһүр руслаштыру сәясәте аркасында татар теленең нинди кысрыклыкларга төшүен сөйләргә дә керешә алмыйм, – дип яза Г. Ибраһимов. – Менә болар һәммәсе татар теленә киртә булдылар. Бердән, аның таралуына, икенчедән, үзенең үсүенә, эшләнүенә юл куймадылар. Югарыда без Октябрь революциясе соңында татар теленең рәсми хокуклы дәүләт теле булганын күрдек. Гамәлгә керүен дә тикшердек. Әгәр без бу телнең, бу мәдәни коралның үзенең эшләнүенә килсәк, бу бездә тик Насыйри бабайдан гына башлана. Әмма революциядән соң бу эшләнү бик зур адымнар белән алга атлап, татар мәдәниятенең баш коралы камилләшү юлына төште»* (10, 275).

Автор татар теленең кыска гына вакыт эчендә төрле дәрәҗәдәге рәсми учреждениеләрдә, мәгариф, фән системасында актив кулланылуын (рус теле белән беррәттән) раслый торган ышандырырлык дәлилләр китерә (Ибраһимов 1925–1927 елларда үзе җитәкләгән Татнаркомпрос каршындагы Академүзәкнең татар телендә фәнни терминология булдыру, сүзлекләр әзерләү өлкәсендә актив эшчәнлеге турында сөйли). Бер үк вакытта мәктәп программаларында милли мәдәнияткә кагылышлы мәгълүматларны киңәйтү-тирәнәйтү кирәклеген дә искәртә: «*Әле монда зур җитешмәгәнлекләр бар. Әле идеалдан ераклар, ләкин бернәрсә факт – милли мәдәният революция аркасында урта мәктәпләрне бөтенләй үз элементы белән тутырып бара, көннән-көн үсә, тирәнәядер. Киләчәктә мәсьәлә тагы югарырак куелачак*» (10, 274).

Г. Ибраһимовның татар мәдәниятенең бүгенгесенә һәм киләчәгенә кагылышлы бу чыгышы рәсми партия органнары

тарафыннан тәнкыйтькә дучар ителә: 1927 елның 14 июнендә ВКП(б) Татар Өлкә Комитеты бюросында Г. Ибраһимов тезисларында җитди кимчелекләр барлыгы ассызыклана, алар арасында милли мәдәниятнең мөстәкыйльлеген арттырып күрсәтү, пролетариатның ролен киметү (милли интеллигенциянең ролен арттыру белән бергә) аерып әйтелә.

Г. Ибраһимовның брошюрасы дәүләт хакимиятенең үзәк органнары эшлеклеләре игътибарыннан да читтә калмый. ВКП(б) ҮК политбюросы әгъзасы Михаил Калинин, үз чыгышында аның эчтәлегендәге «яшерен шовинизмга» ишарәләп, республика партия җитәкчелеген аны бастыруда, дөньяга чыгаруда гаепли. «Бу тезисларның башка бер куркыныч ягы да бар: татар теле Көнчыгышның барлык халыклары өчен дә аңлаешлы. Шуңа күрә бу тезислар алардагы партактивлар арасында фикер төрлелеге тудырырга, «рус мәдәниятеме яки милли мәдәниятме» дигән сорауны калкуландырырга мөмкин, – дип яза М. Калинин (15, 279–280).

Моның белән чагыштырганда, Г. Ибраһимовның кайбер татар зыялылары, аерым алганда, аның тезисларын милли мәдәният мәсьәләләрен яктыртканда сыйнфыйлыктан баш тартуда, вак буржуаз либерализмда гаепләгән Г. Толымбайский тарафыннан тәнкыйтьләнүе күпкә радикальрәк тоела[1].

Авыруының көчәюе һәм шуңа бәйле Кырымга дәваланырга китеп баруы, күрәсең, язучыны 1920 еллар ахырында кулга алынудан коткара. Бу фаҗига 10 елдан соң, татар зыялыларына каршы канлы һөҗүме белән билгеле 1937 елда баш калкыта. Г. Ибраһимов кулга алына, этап белән Казанга озатыла, 1938 елның 21 гыйнварында төрмә хастаханәсендә вафат була.

Г. Ибраһимов шәхесенә төрлечә карарга, аның фикер-карашларын төрлечә бәяләргә мөмкин. Кемнәр өчендер ул – XX гасыр башында татарларның милли үзбилгеләнүен, аларның мөстәкыйль милләт дип аталу хокукын яклаган татар әйдаманы; кемдер аны, 1920 еллар урталарында татарны академик өйрәнү

---

[1] *Толымбайский Г.* Искермәгән бер уңлык турында // Безнең юл. 1929. № 11. Б. 25.

белемен мәйданга чыгару өчен, үзе җитәкләгән Академүзәктә күп көч куйган фәнне оештыручы буларак таный; кемдер инкыйлабтан соң татар милләте төзелешенә керткән өлешен югары бәяли. Әмма шунысы ачык: Г. Ибраһимов өчен эшчәнлегенең барлык чорларында да милли тел, әдәбият, мәдәният, тарих мәсьәләләре өстенлекле булган.

Укучы игътибарына тәкъдим ителгән җыентыкта Г. Ибраһимовның «милләт», «милли үзбилгеләнү» төшенчәләренә бәйле мәсьәләләргә багышланган, төрле елларда иҗат ителгән хезмәтләре тупланды. Язучының мәкаләләре һәм язмалары тематик яктан системалаштырылды: милли тел һәм әдәбият, милли тарих, милли үзаң, күренекле шәхесләр.

Җыентыкка кертелгән мәкаләләр һәм хезмәтләр кыскартулар белән тәкъдим ителә. Рус теленә тәрҗемәдә беренче тапкыр басыла.

*Филология фәннәре кандидаты*
*Марсель Ибраһимов*

# «ТЕЛНЕҢ ЭЧЕНДӘ ХАЛЫКНЫҢ РУХЫ, МОҢЫ, УЙ ВӘ ТОЙГЫСЫ ЯШЕРЕНГӘН»

*(ТЕЛ-ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬТӘ МИЛЛИЛЕК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ)*

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ТАТАРЧА ЯЗУ ХАКЫНДА БЕР-ИКЕ СҮЗ

«Әдәби лисан вә тәүхид лисан» хыялларыннан котылып, мөмкин кадәрле татарча вә халкымыз аңларга җиңел булырлык рәвештә язу ягын алга тотканлыгымыз шатлык илә күрелсә дә, бу хакта ифрад вә тәфридләр очраштыргалыйдыр.

Бәгъзе бер мөхәррирләремез, «саф татарча язам» дип, әдәбият юлыннан чыгып китәләр вә бөтен әдәбиятлар тарафыннан тәкъбих кылынган бәгъзе бернәрсәләрне әдәбиятка кертәләр. Мәсәлән, яңарак чыккан «Хатыннар эше» дигән бер әкиятнең[1] тышына «татарчалаштыручысы Апанай»[2] дип куелган. Кайбер әсәрләрдә «татарчага әйләндерүчесе» яки «татарчага тәрҗемә кылучысы» дигән сүзләр очрый.

Менә бу бичара бәндәләр – «татарча язу тиеш» дигән сүзне яңлыш аңлаучылардыр. Әгәр дә әдәбият мәсьәләләреннән вә ана телендә язуның мәгънәсеннән хәбәрләре булса, бондый тел әйләнми [торган], ишетергә дә мәкруһ һәм кирәкмәгәнчә озын вә килешсез сүзләрне әдәбиятка кертмәсләр иде. Һәр әдәбият

---

*Лисан* – тел.
*Тәүхид лисан* – бердәм тел.
*Ифрад вә тәфридләр* – артыкка китү, арттырып бозулар.
*Тәкъбих кылынган* – бозылган (стилистик яктан).
*Мәкруһ* – ягымсыз, ямьсез.

үзен мондый тәнаферләрдән саклый вә боларга урын бирмидер. Безгә дә буны онытырга ярамый.

Ләфыз вә аһәң җәһәтеннән мәнфур вә мәкруһ тоелган вә шуның өстенә мәгънә җәһәтеннән дә ифадәсез вә чыгышсыз булган «татарчалаштыручысы», «татарчага әйләндерүче» кеби ямьсез сүзләр урынына[3] «мөтәрҗим» дип куйсалар, һәм кыска, һәм матур, һәм аңлаешлы булыр иде.

«Мөтәрҗим» сүзе асылда гарәпчә булса да, ул инде шу дәрәҗә татарлашкан[4] ки, ул татарча язу мәсләгенә дә мөхалиф түгел, һәм аны һәркем аңлыйдыр да. Шулай булгач, ул истигъмальгә ярый.

Татарча язу вә садә телдә язуның мәгънәсенә һичбер чит лөгать кертмәү дип аңлау билкөлле хата идеке мәгълүм булса кирәк. Садә телнең төп максаты һәркем аңларлык ачык язудан гыйбарәт булып, баш кагыйдәсе – мәҗбүрият булмаган урында тәкәллефан чит лөгатьне кертмәү[5] лазем димәктән гыйбарәт идеке дә мәҗһүл дәгелдер.

Саф татарча вә садә телдә язу мәсләгенең иң куәтле тарафдарларыннан булган мөхтәрәм Гаяз әфәнде[6] әсәрләрендә чит лөгатьне юк диярлек дәрәҗәдә аз күрсәк тә, без[гә] бөтен әдәбиятны шундый булыр дип уйларга мөмкин түгелдер. Гаяз әфәнде ул фәкать иске татар тормышын тасвир кыла. Шунлыктан ул әҗнәби лөгатьсез дә язарга мөкътәдир. Әмма

---

*Тәнаферләрдән* – ярашмаулардан, капма-каршылыклардан.
*Ләфыз* – сүз, әйтелеш.
*Мәнфур* – нәфрәт уята торган (колакка ятышсыз).
*Ифадәсез* – аңлау, кабул итү өчен уңышсыз.
*Шу* – шул.
*Мөхалиф* – каршы килгән, ярашмаган (сүз).
*Истигъмальгә* – кулланышка.
*Лөгать* – сүз, атама.
*Билкөлле* – бөтенләе белән.
*Тәкәллефан* – кыланып, ясалма рәвештә.
*Лазем* – тиеш.
*Мәҗһүл* – билгесез.
*Әҗнәби* – чит, башка (халык, тел).
*Мөкътәдир* – сәләтле.

татарга борыннан мәҗһүл булган нәрсә хакында яза башлаганда, ул да аның кадәр татарча гына чыгармаячагында шөбһә юктыр.

Хосусән гыйльми вә фәнни нәрсәләр язганда, чит лөгатьсез бер эш тә чыгарып булмый. Бу фәкать бездә генә түгел, һәр милләттә шулайдыр. Бөтен әдәбиятны фәкать үз лөгатендә генә язу һичбер милләткә мөяссәр дәгелдер. Бездә дә шулай булмый хәл юк.

Садә язу, татарча язу дип, бөтенләй татарлашып беткән чит сүзләрне алыштырырга омтылу да урынсыздыр. Мәсәлән: *...гамәл, итагать, ... мәктәп, мәдрәсә, көтепханә, кыйраәтханә, китап, каләм, журнал, әдәбият, мөмкин, мөхаль, мәҗбүр, мөхәррир, мөтәрҗим, нашир, матбага, никях, талак* кеби бик күп сүзләр шулкадәр татарлашкан ки, болар урынына татарча сүз эзләп маташуның лөзүме дә юк һәм эзләп таптым диюче дә халыкка аңланмаган «мөтәрҗим» сүзен «татарчалаштыручысы» дидеке бер мәгънәсезлек кылудан башка бернәрсә чыгара алмас.

Беркөнрәк «Шура» мөҗәлләдәсе[7]: «нерв»ны *гасеб* дип тәрҗемә ялгыш икән, дөресте ничек булыр?» дип, бер сөаль куйгач, төрле якның хиффәтләре әллә нинди яңа мәгънәләр чокырга, «сеңерле»ме, «сеңер авыруы»мы дип, гайре-мәфһүм тәрҗемәләр тәкъдим кыла башладылар. Болар һәммәсе – татарча вә садә язуның мәгънәсен яңлыш аңлаудан килгән афәтләрдер.

<…>

Хасыйл, бер мәҗбүрият күрелмәгән тәкъдирдә чит лөгать кертмәү лазем мәгънәсендә булган садә язу мәсләген ифрадтан да, тәфридтән дә сакларга лөзүм күренә. Шунлыктан

---

*Хосусән* – аеруча, аерым алганда.

*Мөяссәр* – ирешкән, унышка ирешкән.

*Лөзүме* – кирәге.

*Мөҗәлләдәсе* – төпләнгән журналы.

*Хиффәтләре* – җиңел акыллылары, җилбәзәкләре.

*Гайре-мәфһүм* – төшенчәгә туры килмәгән.

*Хасыйл* – кыскасы, җыеп әйткәндә.

«мөтәрҗим» кеби тәмам татарлашкан бер сүз урынына «татарчалаштыручысы» кеби ямьсез вә мәгънәсез бер сүз кую һәм һәр кеше яки һәр милләт диясе урында «көлле мәүҗүдате натикыйя» дию кебиләр урынсыздыр, яңлыштыр, телемезгә җинаятьтер.

## ӘДӘБИЯТ
*(Еллык хисап урынында)*

<...>

Бу елның матбугатында берничә яңа мәүзугълар кузгатылып, үзләренең әһәмиятенә күрә киң генә урын алдылар. Болардан берсе – хәреф вә имля мәсьәләседер.

Тарих агымы илә татарның муенына тагылган гарәп хәрефләренең шул ничә йөз елдан бирле изеп килгән авырлыгы астында халкымыз ыңгырашмакта; аның бер данәсен үзгәртергә уйланса да, бөтен торышы илә яңартырга, алмаштырырга мөмкин булыр дип уйлаудан үз алдына куркылмакта, гүя бу мәңгелек бер бәла кеби тоелмакта иде. Унберенче елда татарлар ул хәрефләрне бу хәлдә калдырырга мөмкин түгеллеген бик җитди рәвештә матбугатта кычкырдылар. «Идел» буны берничә мәртәбә кузгатып, гарәп хәрефенең безгә һичбер төрле килмәвен, безгә ничек кенә булса да, аңардан котылырга кирәклеген сөйләде һәм үз тарафыннан гарәп хәрефен әсасе илә ташлап, аның урынына латинны алырга тиеш, диде[1].Үзе, татар сүзләрен латин хәрефе илә язып, нәмунәләр күрсәтте.

Оренбургтан дәхи икенче төрле тавыш чыкты.

Анда борадәран Рәмиевләр[2], үзләренең күптән эшләп килгән ляихәләрен тәмам итеп, матбугат өчен «Айры хәрефләр» атлы яңа хәрефләр чыгардылар[3] һәм шуны, нәмунәләре илә

*Мәүзугълар* – темалар (проблемалар).

*Әсасе илә* – төбе-тамыры, нигезе белән.

*Нәмунәләр* – үрнәкләр.

*Борадәран* – бертуган.

*Ляихәләрен* – проектларын.

басып, халыкка гарыз иттеләр. Бу хәрефләр, гарәп хәрефеннән бик ерак китмәк илә бәрабәр, бик күп уңгайлыкларны шамил. Үзләре матур һәм мәдәни. Кабул ителгән тәкъдирдә бик зур җиңеллек бирәчәк.

Бу айры хәрефләрне шул көенчә гамәлгә кертергә ярыймы, ул безнең матлубны тәмам бирәме? Бунысы, – әлбәттә, тикшереләчәк мәсьәлә. Ләкин анларның дөньяга чыгулары, ярау-ярамауларыннан катгый нәзар илә берничә җәһәт илә зур әһәмиятле.

1. Бунлар гарәп хәрефенең ул иске вә авыр хәленчә калуы мөмкин түгеллеге халкымызга аңлашыла башлаганын ачык күрсәтте. Хәреф алмаштыру мәсьәләсендә бунын нинди зур әһәмияте барлыгы мәгълүмдер.

2. Моңарчы галәме исламның төрле ягында чыккан хөруфләрдән боларның күп җәһәт илә алда улучылыгы тасдыйк ителеп, халкымызның шул хакта уйлавына сәбәп булды.

Фәнни бер әсәрнең фән ноктасыннан булган кыйммәтен тәкъдирдә һичбер вакыт аның кем тарафыннан чыгарылган булуы игътибарга алынмый. Әмма мондый низаглы мәсьәләләрдә ул эшне башлаучының кем идеке бик зур роль уйный. Бертөрлерәк адәм буны кузгатса, эш башында торган «бөекләр» яшьлек һәвәсе, хыялпәрәстлек дип карарга яраталар, әмма халыкның һәр сыйныфы кашында могтәбәр тотылган затларның бондый эшкә тотынуы матлубка таба зур бер адым атлау димәктер. Шуның илә бәрабәр, татарда башлап туган бу мәсьәләнең, матбугат мәйданында тиешенчә мөзакәрә вә тәфтиш ителмичә,

---

*Гарыз иттеләр* – тәкъдим иттеләр.

*Шамил* – эченә ала, үзенә җыя.

*Матлубны* – көтелгән максатны, теләкне.

*Катгый нәзар* – кистереп фикер әйтү, катгый фикер.

*Галәме исламның* – мөселман дөньясының (илләре, халыклары).

*Хөруфләрдән* – хәрефләрдән, шрифтлардан.

*Тасдыйк ителеп* – расланып.

*Һәвәсе* – м о н д а: мавыгуы.

*Хыялпәрәстлек* – хыялга бирелү, фантазия.

*Мөзакәрә* – уй, фикер алышу.

*Тәфтиш ителмичә* – тикшерелмичә, өйрәнелмичә.

гәзитәләрдә берничә мәкалә илә генә калуы[4] – шаян тәәссеф бер хәлдер. Халкымызның тәмйиз куәсе чамалы булгангамы, әллә башка бер сәбәптәнме, бу хәрефләр үзләренең мөстәхәкъ булган мәртәбәсендә тавыш ясый алмадылар. Никтер, тынрак кичте. Ләкин ул алай калмас, кайчан да булса ул хәрефләрнең выставкага куелган рәсем кеби карап үткәрер өчен генә чыгарылмавын уйларлар, аны гамәлгә кую мәсьәләсен яңадан кузгатырлар дип уйлыйм.

Хәрефләр төзәтү мәсьәләсендә бу ел дәхи өченче бертөрле фараз да булды. Моннан берничә ел элек Габделмәннан Рәхманколый әфәнде һәрбере баш, урта, азак, ялгыз димәктән гыйбарәт улган хәрефләрне бер шәкелгә калдыру хакында бераз маташып баккан икән[5]. Ләкин ул, заманы җитмәгәнгәме, шул көенчә ятып калган. Шул мәсьәлә бу ел җитди рәвештә янәдән кузгатылды. «Шура»да ике мөгаллим[6], татар хәрефләрен бергә калдыру өчен, ялгыз, урта, ахырларны ташлап, һәр йирдә баш хәрефне алырга кирәк, дип яздылар. Матбагалар да буны кирәксенәләр икән. Хәзер берничә матбага шул ляихә буенча хәреф койдырмакта. Озакламый шул яңа хәрефләр илә берничә китап та, мәктәп өчен әлифба да чыгачактыр. Бу елда хәреф төзәтү хакында чыккан ляихәләр җөмләсеннән итеп, «Йолдыз» тарафыннан тәкъдим ителгән[7] «Хатте касыйр»ны да зикер итмәле.

Бу ел хәреф вә имля мәсьәләсен җитди тикшереп, Гыймад Нугайбәков та берничә нәрсә нәшер итте. Имля мәсьәләсендә Гыймад әфәнденең күрсәткән яңа галәмәтләре кайчан да булса гамәлгә керер дип уйлау читен исә дә, аның моңарчы мөсаһәлә

---

*Шаян* – бәлки, мөгаен.

*Тәәссеф* – үкенеч(ле), кызганыч, аяныч.

*Тәмйиз куәсе* – монда: зәвыгы, нәзакәтлек тою хисе.

*Мөстәхәкъ* – хаклы, тиешле.

*Фараз* – монда: «проект» мәгънәсендә.

*Матбагалар* – типографияләр.

*«Хатте касыйр»ны* – өзек, кисек хәрефләрне.

*Зикер итмәле* – искә алырга, әйтергә кирәк.

*Мөсаһәлә* – йомшак, җиңел; монда: дикъкатьсез, игътибарсыз(лык).

илә үтелгән ун данә мәд авазын казып чыгарып, шуны мисал вә нәмунәләр илә ачык исбат итүе – татар имлясының төзәлүе юлында, һич шөбһәсез, мөһим бер баскычтыр.

<...>

## ФӘННИ ИСТЫЙЛЯХЛАР

*(Г. Батталның «Нәзарияте әдәбия»се мөнәсәбәте белән)*

<…>

Бездә хәзер киң мәгънәсе белән алынган әдәбиятның нәүбәттәге мәсьәләләреннән берсе, – шөбһәсез, шул фәнни истыйляхлар мәсьәләседер. Бездә һәммә мөхәррирләр халык эченнән чыкты, һәммәсенең тәрбиясе, теле вә гыйлем байлыгы шул халыкның үзеннән булган мәртәбәдә генә иде, ягъни көчле рәвештә читләр тәэсиренә төшәрлек рәвештә яшәгән мөхәррирләр булмады, һәммәсе – татар йимеше, татарча гына уйлый, татарча гына яза алырлык икътидарда иде. Шуңа күрә дә татар әдәбияты баштан ук, бердән, реальный, икенчедән, гавәми, өченчедән, садә телле була килде. Хәзер исә буны инде нәзари яктан да чишелде дияргә ярый. Чөнки «Тәрҗеман»ның күп иснадларына карамыйча[1], әдәбият белән гәзитә вә журнал галәме* халык теленә якын бер юл белән агуында дәвам итә.

Әдәбият та шулай. Буны өзелгән бер мәсьәлә итеп карарга ярый.

Әмма фәнгә, фәнни истыйляхларга киленсә, эшләр башка әле. Бездә фәнни истыйляхлар ничек булырга тиешле? Мотлак үз телемездән ясалсынмы? Рустан алынсынмы, әллә гарәпчәдәнме? Нәзари рәвештә моназарәсе кузгалмаса да, хәзер бу өч агымның һәр өчесе дә үзләрен бераз сиздерәләр.

---

*Мәд авазын* – сузык авазны.

*Истыйляхлар* – атамалар, терминнар.

*Икътидарда* – сәләтле, талантлы.

*Гавәми* – массовый, халыкчан, демократик.

*Нәзари* – теоретик.

*Иснадларына* – биредә: яла ягуларына.

* Ягъни журналистика, публицистика.

*Мотлак* – абсолют, тулысынча, тулаем, тик.

Гыймад Нугайбәк әфәнденең[2] «Башлангыч», «Төрлек»е (татар сарыфы) бар. Мөәллиф гыйльми рәвештә күрсәтә ки, ул мотлак истыйляхлар татарчадан булсын ди. Чөнки китабында һәммә истыйляхларны үз телебездән куйган. Хәтта халыклашып беткән «сарыф» сүзен дә ул «төрлек» белән алмаштырган.

Икенче бер агым исә, бер дә ватылмыйча гына, гарәби истыйляхлар илә файдалана. Гыймад әфәнде хәзергә ялгыз күренсә, бу икенче агым бөтен мөәллифләрне диярлек эченә алган.

Сез тәҗвидтән, гыйльме хальдән башлап имля, сарыф, нәхү, кавагыйде әдәбия, тарих, җәгърафия, хисап, һәндәсә, кимия фәннәренә кадәрле барыңыз – һәммәсендә шыкырдап торган гарәп сүзләре күрәчәксез. Монда татар сүзе тик кушымталар урынында кысылып, куркып кына тора.

Өченче бер агым рус тәэсиренә төшәргә ихтималлана. Оренбургта чыккан «Урал» гәзитәсен[3], аның нәшриятын күрүчеләргә бу, ихтимал, ачык мәгълүмдер. Кулымда анлардан нөсхә юк, мисаллар китерә алмыйм. Ләкин ул ачыктан-ачык татарчадан таба алмаса, шул йиргә рус сүзе, рус истыйляхы кыстыра идекен хәтергә китереп үтә алам.

Замана фәне белән танышкан мәдрәсә әһелләре, фән язарга тотынса, үзенең хәзинәсендәге гарәби лөгатьләрне куллана. Бу табигый. Шуңа күрә дә хәзер фәнни әсәрләр гарәпчә истыйляхлы.

Әмма рус дарелфөнүненнән чыккан затлар фәнгә тотыну белән, бу картинаның үзгәрәчәге тагы табигыйдер. Чөнки анлар

---

*Сарыф* – морфология.

*Мөәллифләрне* – авторларны.

*Тәҗвид* – орфоэпия (күбесенчә Коръән укылышына караган; соңыннан башка жанрларга да күчә).

*Гыйльме хальдән* – иске мәдрәсәләрдәге дини предметтан (шул ук исемдә дәреслек).

*Кавагыйде әдәбия* – әдәбият кагыйдәләре.

*Һәндәсә* – геометрия.

*Кимия* – химия.

*Лөгатьләрне* – сүзләрне, лексемаларны.

*Дарелфөнүненнән* – университетыннан.

русча уйлый, русчадан истифадә итә, хәзинәләрендәге сүзләр – йә русча, йә руска кергән Европа истыйляхы.

Моның шулай булачагына дәлялә́тләр бар: югарыда әйтелгән «Урал»лар, дәхи кайбер фәнни тәҗрибәләр. Мәсәлән, «Аң»да Хәнәфи әфәнде[4] исемнәрдә дә, истыйляхларда да кайбер вакыт рус тәэсирен азрак күрсәтә: «ысул» сүзен – «систем» дию, «Фисагорис»не – «Пифагор»[5] дию кебек.

<…>

Агымнар шулай.

Ләкин табигый юл, безгә хәзердән тотарга, якларга тиеш булган юл кайда?

Фәнни истыйляхларда һичбер чит сүз кертмәүдәме? Гыйлемдә остаз булганлык өчен, рус тәэсиренә якынаюдамы? Әллә тарихи барышымызга буйсынып, гарәпчә йөртүдәме? Менә бу инде мәсьәлә!

Без гарәпчәнең канымызга, миемезгә сеңгәнлеген, аның хәтта үз ана телемезне дә җиңгәнлеген инкяр итә алмыйбыз. Ул кирәкми дию белән генә аңардан котыла алмаячагымыз да көн кебек ачык. Бу – бер.

Икенчедән, үзенең зур куәте белән һәрьяктан чолгап алган, безне җиңеп, үзенә шәкерт ясаган рус мәдәниятенең тәэсиреннән бөтенләй азат булуны уйлау да зур бер садәдиллек булачак. Шулар илә бәрабәр уртада халык дигән, халык теле аталган бернәрсә бар. Бұның хакимияте исә башка һәрнәрсәдән артык булырга тиеш[6]. Әлбәттә, һәр мәдәният башта читләр тәэсирендә яши. Ләкин үзендә бераз куәт сизү белән, истикъляль юлы тотуы да табигыйдер. Башка һәр турыда булган кебек, фәнни истыйляхлар мәсьәләсендә дә без шундый юл тотарга тиешлемез.

Телә-теләмә – барыбер табигать үз дигәнен кылыр. Бер як гарәпчәгә чума, икенчеләр әзер рус юлы белән файдаланмакчы

---

*Истифадә итә* – файдалана.

*Дәлялә́тләр* – дәлилләр, аргументлар.

*Садәдиллек* – беркатлылык.

*Хакимияте* – хакимлеге (көч-куәте, тәэсире).

*Истикъляль* – мөстәкыйльлек.

була икән, болар – вакытлы хәлләр, һәр милләтнең үткәнендәге билгеле дәверләрдер. Көне килер – яшь мәдәниятемез үзенә бераз вакыт алу белән, фәне дә садәләшер, ул да кеше киемен ташлар. Буны ачык мисалда күрү өчен, әдәбиятны хәтерләргә кирәк. Бездә төрек, гарәп тәэсиренең көчле вакытлары булды. Ләкин халыкның үзе дигән куәт тизлектә югары менеп, табигый агымга юл ачты.

Фән дә шулай булачак. Ләкин аның татарчалашуы әдәбиятка караганда күп мәртәбә акрын, күп мәртәбә талашлы барачак. Чөнки әдәбият халыктан, халыкның хәятыннан, халыкның күңелендәге мәгънә вә хисләрдән бәхәс итә. Шуңа күрә дә анда халыкның үз сүзе, үз лөгате җитә яза. Читтән алу мәҗбүрияте, һәрхәлдә, үтә күп булмый.

Әмма фән – яңа нәрсә. Ул милләтнең тарихында юк. Димәк, халыкның аңында фәнни мәфһүмнәр тумаган. Башында фәнни мәгънә булмагач, ул халыкның телендә фәнни ифадә кылырлык лөгатьләр булмавы да таби-гыйдер.

Бәс, ул фәнни мәгънәне әйтү өчен, чит телләрнең ярдәменә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр буламыз.

Менә шуңа күрә дә Гыймад әфәнделәрнең һәр турыда татарчадан гына истыйляхлар ясау мәсләге, – ничаклы матур идея булса да, гамәлгә кертергә, гомумны шуңа күндерергә читен, хәтта мөмкин түгел үк юллардан берeдер.

Шуның илә бәрабәр һәр турыда гарәп истыйляхларын алу, татарга дип язган фәнни әсәрләрне Гарәбстан сүзе белән тутыру да – киләчәк буыннар тарафыннан шелтәгә сәбәп булачак бер хатадыр.

Ләкин, тәэссефемезгә каршы, фән язучыларымызның һәммәсе хаталы юл белән китеп баралар. «Тәҗвид», «Гыйльме хальне» әйтмибез: болар – мотлак дини нәрсәләр. Дин үзе – бик

---

*Садәләшер* – гадиләшер, катлаулыгы бетәр.

*Мәфһүмнәр* – төшенчәләр, сүзләр.

*Ифадә кылырлык* – тәгъбир итәрлек, белдерү чарасы булырлык.

*Тәэссефемезгә* – кызганычка, үкенечкә.

артык мөхафәзәкяр бер куәт. Ул кайсы халыктан алынган булса, шуның истыйляхы белән йөри бирер.

Әмма дөньяви фәннәргә – тарих, җәгърафияләргә, хисап, һәндәсә, һәйәт вә кимия кебиләргә киленсә, менә монда ни әйтергә?

Күз алдымда – Гобәйдулла Фәйзи әфәнденең[7] дүрт мәртәбә басылган, димәк, халык кашында мәкъбүл тотылган «Җәгърафияи гомумия»се. Сез теләгән йирдән ачыңыз да, истыйляхларына күз салыңыз... Баштанаяк, көррәи Арз, хәрәкәте Арз, горуке бәни бәшәр... кебек, тик Гарәбстан балаларына язылган җәгърафияләрдә генә булырга мөмкин истыйляхлар күрәчәксез.

Аның артыннан Харис Фәйзи әфәнденең «Ысуле җәгърафия»сендә[8] дә шулай ук татар китабында бер дә урын алмаска тиешле «минтакаи харрә», «минтакаи мөгътәдилә», «бәхре мөхит», «мөнҗәмиде шимали» «бәхре мөхит кәбир», «нисъф-ен-нәһар» кебек истыйляхлар очратачаксыз.

Һәйәтләрдә, Шөнаси әфәнденең[9] «Кимия» вә «Педагогия»ләрендә булган гарәбизмны әйтәсе дә юк.

---

*Мөхафәзәкяр* – искелекне яклаган.

*Хисап* – биредә «хисап гыйльме (арифметика, математика)» мәгънәсендә.

*Һәйәт* – астрономия.

*Мәкъбүл тотылган* – кабул ителгән.

*Җәгърафияи гомумия* – гомуми география.

*Көррәи Арз* – Җир шары.

*Хәрәкәте Арз* – Җир әйләнеше, хәрәкәте.

*Горуке бәни бәшәр* – адәм балаларының төрләре, ырулары; кешеләр расалары.

*Минтакаи харрә* – тропик зона, пояс.

*Минтакаи мөгътәдилә* – урта пояс, зона.

*Бәхре мөхит* – океан.

*Мөнҗәмиде шимали* – төньяк бозлары (бозлыгы).

*Бәхре мөхит кәбир* – Бөек океан (Тын океан).

*Нисъф-ен-нәһар* – меридиан, төшлек сызыгы.

Кимия бер дәрәҗәгә кадәр мәгъзүр дә. Чөнки ул – халык хәятыннан артык ерак бернәрсә. Ана телемездә аны ифадә итмәк – хакыйкатән, мөшкил эш. Башка милләтләр дә монда үз телләрен аз керткәннәр. Ләкин аның фән тәдрисе дә татар телендә фән булсын дигән адәмне, хакыйкатән, шашырлык мәртәбәдә гарәпчә истыйляхат белән тулыдыр.

Г. Мостафа әфәнденең «Һәндәсә»се[10] дә шундый хәл. Татарча һәйбәт итеп: сызык, туры сызык, кыек сызык, почмак дип әйтү һәрьяк өчен матур икән, шул урында хатте, хатте мөстәкыйм, завия, завияи хаддә дип, татарга китап язуны һичбер төрле аңларга мөмкин түгелдер.

Тагы бераз түбән төшеп, һәркем өчен кирәк булган, шуңа күрә мөмкин кадәрле һәммәгә җиңел аңлашуы лазем булган бер фәнне* тик Гарәбстан балаларына гына ярый торган бер истыйляхат белән тутыру – бу инде нә фәнгә, нә мантыйкка сыймый, нә бер ихтыяҗга җавап бирми, нә бер гозергә керә алмый. Мисал өчен алыйк «Хисап»ларның иң соңгысын, «Хөсәения»[11], «Касыймия»[12], «Мөхәммәдия»[13] кебек күп мәдрәсәләрдә дәреслек итеп кабул ителгән һәм ике мәртәбә басылган, димәк, гомум тарафыннан мәкъбүл табылган бер әсәрне – Габбас Ибраһимов нәшер иткән «Хисап» китабын[14].

Монда, китапның тышында ук, татар күңелен тәхкыйрь итәчәк сүзләр тулы. Мәсәлән: «әгъдаде бәсита», «әгъдаде

---

*Мәгъзүр* – гафу ителерлек (чарасыз, гаҗиз булганлыктан).
*Хакыйкатән* – чыннан да, чынлап та.
*Тәдрисе* – дәрес бирү, укыту (методикасы).
*Хатте* – сызык, линия (геом.).
*Хатте мөстәкыйм* – туры сызык (геом.).
*Завия* – почмак (геом.).
*Завияи хаддә* – кысынкы почмак (геом.).
*Лазем* – тиеш, кирәк.
* Текстта: *фәндә.*
*Мантыйкка* – логикага, логик мәгънәлелеккә.
*Гозергә керә алмый* – гафу итәр өчен, акларга сәбәп юк.
*Тәхкыйрь итәчәк* – рәнҗетәчәк, кимсетәчәк.
*Әгъдаде бәсита* – гади саннар.

мөрәккәбә», «кәсре гади», «кәсре әгъшари», «сөлясәи мөфрәдә», «сөлясәи мөрәккәбә», «хәлита» илх...

Китапның эченә керсәң, тагы җан рәнҗеткеч «әгъмале әрбага», «җәмегъ», «тарех», «зареб», «тәкъсим»... Тагы алгарак барсак, мәсәлән, шундый сүзләр:

«Күб ханәле, вахид белән сыйфрдан мөрәккәб булган гадәдләргә тәкъсим идәр өчүн, мәгъсумнең уң тарафындан мәкъсуме галәйһидә сыйфрлар кадәр ханә айрылуб алынур, бусы – кәсер булур да, сул тарафда калганы «хариҗе кыйсмәт» булур...»[15].

Хуш, боңа [ни] дияргә?

Татар телендә фән булсын, хисап, тарих, җәгърафия шикелле һәммәгә кирәк нәрсәләр халык теленә мөмкин кадәрле якын булсын дип аңлар мәртәбәдә тәрәккый итә алган затлар тарихта* ник «коруне вөста» ди? Ник урта гасырлар, урта заман түгел? Ник «көррәи Арз» ди, ник Йир шары түгел? Рус – ПОЯС ди, гарәп – МИНТАКА ди. Без ник үз телемезчә, һәркем

---

*Әгъдаде мөрәккәбә* – кушма саннар.

*Кәсре гади* – гади вакланма.

*Кәсре әгъшари* – унарлы вакланма.

*Сөлясәи мөфрәдә* – гади өчлек.

*Сөлясәи мөрәккәбә* – кушма өчлек.

*Хәлита* – кушылма, катыш, катнашма һ. б.

*Илх* – һ.б.

*Әгъмале әрбага* – дүрт гамәл.

*Җәмегъ* – күплек; б и р е д ә: кушу.

*Тарех* – чигерү; б и р е д ә: алу гамәле.

*Зареб* – сугу; б и р е д ә: кабатлау, тапкырлау.

*Тәкъсим* – бүлү.

*Тәрәккый итә алган* – үскән, эволюция, прогресс кичергән (б и р е д ә: аң-белем ягыннан).

* Ягъни алар язган тарих дәреслекләрендә.

*Коруне вөста* – урта гасырлар.

*Көррәи Арз* – җир шары.

*Пояс* – русча гади сөйләмдә «билбау, пута» дигән сүз, термин буларак – географик зона, Җир шарының климат поясы.

*Минтака* – гарәпчә гади телдә: пута, билбау, урау; геогр.: пояс, зона, климатик полоса (буйлак).

аңларлык мәртәбә туп-туры «билбау» димибез? Ник «Бәхре кәбир»? Ник «Олуг диңгез» генә түгел?[16]

Хисапта сан, дүрт гамәл, кушу, бүлү, арттыру, алу дисәк, һәммәгә җиңел аңланачак икән, «гадәд», «әгъмале әрбагә», «җәмегъ», «тарех», «тәкъсим», «зареб» дип утыруда ни мәгънә булырга, мөәллифләрнең мондый мөсаһәләсене ни белән тәэвил итәргә мөмкин? – Мин монда, мисал өчен, кайбер әсәрләрне генә алдым. Әмма вакыйгда шул «Тәҗвид»тән, «Гыйльме халь»дән башлап, «Сарфы төрки»ләр, «Нәхүе төрки»ләр, «Кавагыйде әдәбия»ләр, хисап, тарих, җәгърафия хакындагы һәммә әсәрләр шундый, һичбер мәҗбүрият булмаган, татарча бик һәйбәт итеп әйтү мөмкин булган урыннарда кирәкмәгән Гарәбстан сүзләре белән тулыдыр[17]. Хәлбуки язучылар кайда, кемгә язганлыкларын онытмаска бик тиешлеләр иде.

Бездә фәннең яңа туып килгән чагы. Хәзер ул юл сала. Шулвакыт без әллә нинди авыр гарәбизм белән тутырсак, мөмкин була торып та, чит сүзләр кертсәк, киләчәк буын кашында зур җинаять эшләгән булачакмыз.

Бездә госманлы төрекләренә иярәләр. Истыйляхатны шулардагыча ясап, гүя тел берләшү әмәлен күзәтәләр. Хәлбуки бу – адәм көлкесе бер эштер. Чөнки бүген госманлы төрекләре үзләренең телләреннән, фәнни истыйляхларыннан риза түгелләр. Анлар хәзер садәләшү юлына кереп бара. Хәзер анлар үзләренең телләрен, фәнни истыйляхларын үзгәртеп, булдыра алган чаклы үз ана телләрен кулланырга, истыйляхларын шулардан куярга тырышып яталар[18]. Инде без дә килеп, «тел

---

*Мөсаһәләсене* – б и р е д ә: игътибар итмичә җиңел генә үтүен, аңлатмыйча китүен.

*Тәэвил итү* – аңлату; б и р е д ә: сәбәбен аңлатырга, акларга.

*Вакыйгда* – чынбарлыкта.

*Сарфы төрки* – Төрки морфологиясе.

*Нәхүе төрки* – Төрки синтаксисы.

*Кавагыйде әдәбия* – Әдәбият кагыйдәләре (теориясе).

*Кашында* (иск. сүз) – каршында, алдында.

*Садәләшү* – гадиләшү (гади халык теленә якынаю).

берләштерү»ме-фәләнме максаты белән анлардагы истыйляхатны алырга тырышып ятсак, бу ни була?!

Бу анлар яратмый ташлаган бер хатаны алып, шуның белән гамәл итү була түгелме?!

Белмим, моның ник кирәге бар? Берәүнең үзе ташларга торган хатасына ияреп, истыйляхларны, тәгърифләрне анлардагыча гарәбизм хөкеменә бирүне нинди мантыйк сыйдыра да, моңарда[н] нинди мәгънә көтелә? Яхуд мөәллифләр, бу мәсьәләләрне һичбер уйламыйча, шулай җиңелрәк булганга гынамы гарәбизм сазына баталар?[19]

Мин моны «саз» дим, һәм бу – хакыйкатән, саз. Бер кереп баткач, яңадан борылып чыгу кыен булган саздыр. Госманлылардан гыйбрәт алырга кирәк[20]. Анлар тарихи агымнан килгән бер хата белән бу сазга килеп батканнар; инде ничек чыгарга белми интегәләр. Шуны күрә торып, безнең дә ул сазга барып батуымыз бу инде фән кашында зур, бик зур җинаять хисап ителергә тиеш.

Рус тәэсиренә төшү әле аз рәвештә. Шуңа күрә ул хакта сүз озайтырга, аның мәгънәсезлеген сөйләп торырга кирәк күренми.

Яшим дигән халык һәрнәрсәдә үзен алга куя. Без дә, тарихта җинаятьчеләр исемен алырга теләмәсәк, буны аңларга да, фәнни тел, фәнни истыйляхат хакында һәр милләт өчен табигый булган бер юл тотарга – нә руска, нә гарәпкә җиңелмәскә тиешлемез. Ул юл исә:

– Халыкның үз телен асыл итеп алып, мәҗбүрият булмаган урында чит сүзне кертмәүдән гыйбарәттер.

Шул нәзария нигез итеп алынса, безнең фәнни телемездә, фәнни истыйляхларымызда зур үзгәреш туачак, һәм шул юл белән яңа китаплар язылганнан соң гына, без «татар фәне, татар телендә фән» диеп сөйләшергә хаклы булачакмыз.

---

*Тәгърифләрне* – билгеләмәләрне.

*Истыйляхат* – атамалар, терминнар.

## «АЛЬБОМ» МӨНӘСӘБӘТЕ БЕЛӘН БЕР-ИКЕ СҮЗ

<...>

Бәни адәмне тау тишекләрендә вәхшәт белән гомер иткән дәверләрдә үк сәнаигы нәфисәнең башлангычын тудырырга истигъдадлы итеп яраткан табигать, әлбәттә, бер безне моннан мәхрүм калдырмаган. Безнең халкыбызда да бу бар, тагы ачыграк әйткәндә, халкымызның табигатендә сәнаигы нәфисәнең орлыгы юк түгел икәнлегенә галәмәтләр бар.

Булган Гайшәләр: алар йөрәкләрендәге авыр хәсрәтне мәгълүм бер көй – «Тәфтиләү» белән ифадә кылыр мәртәбәдә сәнгатькяр булып яратылганнар. Чыккан «Ашказар», «Сакмар су» көйләре. Болар бар да – табигать тарафыннан куелган композиторлык орлыгының бик аз бер сәбәп булгач та тишеп чыгып, үлән рәвешендә үсә башлаган хәлләредер. Ул орлык матур гөл булып үсеп, яфрак яра, чәчәк ата алмаган, «Ашказар» вә «Тәфтиләү» ияләре русның Чайковскийлары[1], полякның Шопеннары[2] була алмаган икән – моның өчен табигатькә түгел, тарихка, язмышка үпкәләргә мәҗбүрмез. Теләгән гөлнең тууы өчен, орлык кына җитми, аның яхшы туфракка чәчелүе, вакытында яңгыр вә кояш тиюе, таш белән, фәлән белән басылып калмавы шарт. Безнең халыкның табигатенә чәчелгән музыка истигъдадлары – орлыклары – шул шартлар булмаганнан гөл булып үсә алмый калганнар. Чәчәк ату вә җимеш бирүне хәтергә дә китереп булмый инде: музыка хәрәм иде, аның белән шөгыльләнү адәмнең бөтен игътибарын юк итә иде. Шулай да табигатькә каршы булган бу хөкем халык йөрәгенә чәчелгән музыка орлыгын бөтенләй юк итә алмады. Ничаклы капланса, ничаклы бетерергә тырышылса да, ул һаман бер җирдән тишеп чыга: кызлар мунчага барып кубыз тарта, аулак өйләргә җыелып гармун уйный, егетләр, көн буена эшләп арганлыкларына карамыйча, җәйнең кыска төнен атка куна барган җирләрендә музыка уйнап үткәрәләр, никрут чакларында, бераз усаллыклар

---

*Истигъдадлы* – сәләтле.

гафу ителәчәк булганга, урамда җыелып уйнар мәртәбәдә батырлык күрсәтәләр иде.

Җыр да шулай музыка мәртәбәсендә үк тыелса да, ул һаман бөтенләй туктатыла алмый иде. Безнең халык җыры бик бай. Ул дәрт белән, хәят белән, сөю белән, табигать тасвиры белән, матурлык хисе белән тулы. Алар эчендә шундыйлары бар ки, авыр язмышлы бу халыкның шунча агыр көннәр, газаплар соңында да матурлык хисләрен югалтмавына, мондый уңайсызлыклар эчендә дә аның табигатенә чәчелгән сәнаигы нәфисә орлыгының кибеп, корып юк булмавына хәйран калмаска мөмкин түгел.

Халык тарафыннан көйләр чыгарылган. Нинди дә булса гадәттән тыш бер кайгы, бер хадисә булдымы, аның табигатендәге сәнәгате әдәбия орлыгы хәзер тишеп чыга – солдатка киткән шәкертләрме, яшен суккан кызмы, суга баткан Гайшәме[3] – тиз арада шул вакыйга белән уянган тәэсир, сүзләр аркылы укучылар алдына тәҗәссем итеп килә – ул хакта бәетләр чыга.

Болар һәммәсе безнең халыкта сәнаигы нәфисә орлыгының барлыгына ачык шәһадәт бирәләр. Каплап яткан таш соңгы елларда ярылды, һәм шуның белән сәнаигы нәфисәнең иң садәсе булган әдәбият баш күтәрде – халык эчендә булган иҗат вә сәнгать орлыклары яңа шагыйрьләр, хикәячеләр кыяфәтендә тәҗәссем итә, үсә башлады. Яфрак атты, инде чәчәкләре дә күренә.

Музыка белән дә, Хода насыйп итсә, шул хәл булачак. Музыка хәрәмдерме-юктырмы – хәзер аны тикшермиләр. Халык киң бер һөҗүм белән музыкага ташланды; аңар гомуми мәел, гомуми дәрт: яшь кызлар, яшь егетләр эчендә музыка коралларыннан берсен белүне үзенә идеал итмәгәннәр сирәк табылачак. Бу гомуми дәрт, бу гомуми мәел – туачак композитор өчен суларга һава, тамыр җәяргә туфрактыр.

<...>

---

*Сәнаигы нәфисә* – нәфис сәнгатьләр.

*Тәҗәссем итеп* – күз алдына китереп.

Икътисад, гыйлем, һөнәр – боларның һәркаюсы бәйнәлмиләл нәрсәләр. Русмы, татармы, французмы – моңар карап аерылмый. Ике җирдә ике французга да дүрт, татарга да; Җир шары руска да түгәрәк, немецка да! Болар турында икенче халыктан алырга ихтыяҗ миллият ноктасына кагылмый. Ләкин сәнаигы нәфисә алай түгел; музыка, тәрсим, әдәбият – болар халыкның рухы, болар һәр халыкның үзенә, тик үзенә махсус. Рәссам Маковский белән музыкант Чайковский тик руста гына туарга, рус халкының рухыннан гына чыгарга[4], Шопенны фәкать шул үткәне шанлы, хәзерге көне кайгылы, киләчәге өмид вә куркыныч эчендә булган агыр язмышлы мәгърур Польшаның йөрәге генә тудырырга мөмкин[5]; шулай һәр халыкның сәнгате – аның үзенең аерым җаны, аерым йөрәге, аның тик үзенә генә мәгълүм, тик үзе генә аңлый ала торган серле руханиятедер. Миллиятнең асыл тамыр җәячәк җире дә шулдыр. Сәнаигы нәфисәнең бере – әдәбият – туып килә, архитектураны, һәйкәлтәрашлыкны тиз арада өмид итәргә имкян күренми, ләкин музыка белән тәрсим сәнгате хакында якты өмидтә булырга хакыбыз бардыр. Боларны каплаган авыр таш күтәрелде, боларга гомуми мәел, гомуми дәрт бар – халыкның йөрәгенә табигать тарафыннан салынган орлык шул гомуми мәел, гомуми дәрт туфрагы эчендә акрынлап борынлый башлавын, бәхетле яшь егетләрнең берендә шулар җитешкән бер сәнгатькяр тудыруын өмид итүдән үземезне тыя алмыймыз.

Кыш үтте, җир ачылды, кояш та карый – бераз җир кипсен, рәхмәт яңгырлары булсын – менә үләннәр күренер, арадан берсе чәчәк тә атар.

Табигать моны безнең өчен түгел, шулай үзенең гади кануны теләвенчә эшләр, ул бер максат белән түгел, үзеннән-үзе, үзенең эчке агымы белән килеп чыгар, ләкин, үз рәхәте өчен үскән гөлләр безнең рухыбызны тәрбияләгән кеби, ул сәнгатькярләребез дә миллиятнең бердәнбер азыгы булырлар.

---

*Бәйнәлмиләл* – интернациональ, халыкара.

*Тәрсим* – рәсем сәнгате.

*Имкян* – мөмкинлек.

*Мәел* – кызыксыну, теләк.

Милли рух азыкка мохтаҗ, милли зәвыклар, милли тойгылар кибеп корымаулары өчен рәхмәт яңгыры көтәләр. Хәзергә шигырь вә хикәя бар, ләкин сүз, әдәбият – болар, гомумән, сай йөзә торган нәрсәләр. Миллиятнең тамырларын, халык йөрәгендә мәңге суырылмас мәртәбәдә тирәнәйтә алу тик милли музыка, милли сәнаигъның могҗиз куәте аркылы гына мөмкиндер.

Милләт уйганды, ләкин аңар тамыр җәяргә туфрак, тын алырга һава кирәк. Ул хәзер сыек матдә шәкелендә. Миллиятнең, милли рухның җилгә аумас, суга батмас, утка янмас мәртәбәдә куәт алуы һәм дә мәдәни бер калыпта корычка әйләнүе өчен, ул үзенең сәнаигы нәфисәсенә мохтаҗ. Безне моңарчы дин саклады, тәгассыб саклады, ләкин яңа тип зыялылар рухында диннең ул куәте калмады инде.

Аны яныбыздан шаулап аккан мәдәният диңгезенә кереп, татар өчен мәңгегә юк булуыннан, мәдәни халыкларга йотылуыннан фәкать аның үз йөрәгендәге эчке тамырларын тибрәтәчәк милли сәнгать кенә алып калыр.

Бөтен хәят, бөтен тарих безгә бер хакыйкатьне тәкрар итә: «Сәнгать – яңа заманның дине, бөек сәнгатькярләр – ул диннең пәйгамбәрләреder».

Бездән – өмид итмәк, Ходадан – бирмәк, башка ни диик!!!

<...>

## ТЕЛЛӘРЕ БАШКА БУЛСА ДА, КҮҢЕЛЛӘРЕ БЕР

*(Матбугатта казакъ яшьләре тарафыннан кузгатылган тел мәсьәләсе мөнәсәбәте белән)*

### I

Җир йөзендә җитмеш-сиксән миллион чамасында төрек җаны* хисаплыйлар[1]. Кайчандыр бер-беренә якын яшәгән бу

*Шәкелендә* – формасында.

*Тәгассыб* – фанатизм.

* «Төрки халыклар» мәгънәсендә.

халык соңгы берничә гасырда бик таралганнар, бик аерылганнар. Боларны икълим вә җәгърафи вазгыять* аера. Соңгы берничә гасырлык тарихлары аера, сәяси, икътисади вә хокукый хәлләре аера. Шулар нәтиҗәсендә бер атаның балалары милли гадәт, милли ганганә буенча да бер-береннән ераклашалар.

<…>

Безгә әдәбият тугрысында ике генә юл бар иде:

1) җирле шивәне бөтенләй басып, «Тәрҗеман»ча, гомуми вә әдәби телдә язмак;

2) шул җәгърафи, тарихи вә башка сәбәпләр нәтиҗәсендә берничәгә аерылмак.

Болардан әүвәлге хәлгә хәят каршы барды. Бер тел урынына Анатулыда – «госманлы», Кавказда – «азәрбайҗан», Төркестанда – «чыгтай»мы диик, Татарстанда «татар» телләре мәйдан алды. Бәс, шулар белән янәшә «казакъ теле», «казакъ әдәбияты» дигән бер нәрсәнең тумавы мөмкин түгел. Башкорт, мишәр, типтәр вә башкалар «татар теле вә әдәбияты» дигән бер җәмигъ астына җыела алганнар. Чөнки бөтен хәят боларны шуңа хәзерләгән. Шулай ук Төркестандагы таҗик, үзбәк, сарт вә башкалар бер әдәбият астына керәләр. Чөнки болар – бер туфракта үскән якын нәрсәләр.

Әмма үзенең соңгы заман тарихы, җәгърафи халәте, тормышы белән башка төрки кабиләләрнең һичберенә охшамаган алты-җиде миллионлы бер халыкны** «татар теле вә әдәбияты» астына кертү фикере бу хәяттагы табигый куәтне аңламаудан башка нәрсә түгелдер.

Тюркологларның һәммәсе казакъларны иске төреклекнең иң нык сакланган җире диләр. Бу көнгә казакъ халкы үзенең көнкүреше, хәят ихтыяҗлары белән башка төрки кабиләләрдән

---

* Җирнең географик бүленеше, урыны.

*Икътисади* – экономик.

*Ганганә* – традиция.

*Шивәне* – диалектны, сөйләшне.

*Җәмигъ* – җыючы бергәлек.

*Җәгърафи халәте* – географик хәле (урын).

** Казакъ халкын.

бик нык аерыла. Бу халыкның рухында бик куәтле самобытность* бар. Боларның халык әдәбияты башка һичбер төрле кабиләнекенә охшамас дәрәҗәдә бай һәм зурдыр. Безгә, казакъларны татар теле вә татар әдәбияты астына кертү хыялыннан бигрәк, әдәби хәзинәмезне баету өчен, казакъ халкы әдәбиятын киң рәвештә өйрәнү тиешледер.

Озын сүзнең кыскасы, кайчандыр киң бер даирә эченә кергән халыклар язмыш иҗбары белән аерылганнар. Шул аерылуның күп сәбәпләре бар. Шул сәбәпләр казакъ халкыннан да үзенә бер әдәбият тудыруны лазем итә.

Бондый аерылулар, бәлки, күңелсездер, бәлки, аның начар яклары бардыр. Ләкин ул аерылуга каршы торырга һичкемнең тәкатеннән килми. Гомуми әдәби телдән аерылып, Насыйрилар салган эз белән татар теленә, татар әдәбиятына кереп китүемез никадәр табигый булса, казакъның үзенә әдәбияты тууы да, мәктәпләрендә үз шивәләрен алга сөрү дә шулкадәрле табигыйдер.

Төрле фикер вә хыял белән баш авырттырганчы, дөньяга ачык күз беләнрәк карасак, булмас өмид юлында куәт түккәнче, факт белән хисаплашырга тырышсак, эшебез тагын да нәтиҗәлерәк булыр.

Казакъны «татар әдәбияты» белән канәгатьләндерү фикере тик ул халыкны вә тарихи агымны белмәүдән киләдер.

Казакъ әдәбияты инде булган бер факт. Бөтен казакъ сахрасына әдәби азык булып килгән үләң вә жырлар, безнең хәзерге шагыйрьләремездән күп элек яшәп, киң далада авазы яңгыраган Ибраһим Кунанбайлар[2], соңгы Сералин[3] вә Дулатовлар[4], «Казакъстан»[5], «Казакъ»[6], «Айкап»лар[7], казакъ мәктәпләренә кереп тамыр җәеп барган «уку кораллары», гомумән, казакъ телендә баш күтәргән әдәбият – хәзер инкяр итәргә мөмкин булмаган бер фактлыр.

* Бу сүз кириллицада басылган.

*Язмыш иҗбары* – язмыш җәберләве, язмыш мәҗбүр итүе.

*Лазем* – тиеш, кирәкле.

Буны аерым кешеләрнең фикерләре, татарга кушылырга теләмәүләре тудырмаган, хәят безнең теләвебез буенча йөрми. Аерым бер гөруһның фикере вә хезмәте һичбер вакыт хәят агымын туктата алмыйлар. Мәсьәләгә болай карау – диңгез агымын ишкәк белән туктатырга тырышу кабиленнән бер эштер.

Без «татарлык» димез, телемезне «татар теле» дип, әдәбиятымызны «татар әдәбияты» дип атыймыз – моңа кемнәрнең булса да хезмәтләре, фикерләре сәбәп түгел, моның сәбәбе – тирәндә, тарихи куәтләрнең шул юлга сөрүендәдер.

Бөтен казакъ зыялысын татарлаштырыңыз, аларны татарча язарга күндереңез, бу, бәлки, мөмкин дә булыр. Ләкин бу хәл озакка бара алмас; бондый ясалмалык вакытлыча яши алыр, әмма ахырдан барып хәят үзенекен кылыр, ясалган буа җимерелер, су үзенең табигый агымына төшәр.

Әйтергә телимен ки, гомуми әдәби тел хыялы үзенең табигый әҗәленә иреште. Аның урынына госманлы, азәрбайҗан, чыгтай, татар шивәләре мәйдан алды; менә шуларны тудырган сәбәпләр казакъны да үзенә бер әдәбият астына җыелырга мәҗбүр итә.

Бәс, аларның үз телләрендә гәзитә, роман вә дәреслек чыгарулары, мәктәпләрендә казакъ телен алга сөрүләре шул гомуми агымның бер ботагы – тәгълим вә тәрбия кануннарының да төп теләгедер.

Без бервакыт госманлы әдәбиятына шәкерт идек. Ул вакыт бездә госманлы тәэсире бар иде. Казакълар да беразгача татар мәдәниятенә вә татар әдәбиятына шәкерт булырлар. Ләкин бара торгач алар үзләренең мөмтаз рухлары белән парлак мәйданга чыгачаклар. Буны һичбер куәт туктата алмаячак.

## III

Шулай итеп, төрек дөньясы, язмыш иҗбары белән, югарыгы биш әдәбиятны тудыра.

---

*Тәгълим* – укыту.

*Мөмтаз* – үзләренә хас (үзгә).

*Парлак* – якты.

*Иҗбары* – мәҗбүр итүе.

Үзенең соңгы тарихы, җәгърафи вазгыяте вә башка әхвале белән бүтән төрки кабиләләрдән аерымрак яшәгән Кырым бар. Табигатьнең бу матур өлкәсе төрек дөньясына үзенә аерым бер гүзәл әдәбият бирә алырмы яки ул тегеләр арасына кереп югалырмы? Менә бу инде бер мәсьәлә.

Кырымлы төрекләрнең азлыгы, анда яшәүчеләрнең чуарлыгы, бер яктан, госманлы әдәбиятына, икенчедән, Азәрбайҗанга якынлыгы бу халыкның шул әдәбиятлар эченә сыену ихтималын бик якын күрсәтә.

Хәзергә кадәрле Кырым рухы, Кырым хосусияте белән сугарылган бер әдәбият вә бер гәзитә вә матбугатның булмавы шул ихтималны бик куәтли.

Һәрхәлдә, Кырымның тел вә әдәбияты мәсьәләсенең нинди юлга керүен бер якка кертеп җибәрерлек факт хәзергә мәйданда юк.

Инкяр мөмкин булмаган факт – шул югарыгы биш өлкәдә биш әдәбиятның тууыдыр. Кырымда аерым бер чәчәк үстереп, төрек агачыннан аерылган ботаклар шул биш белән калырмы, яки, алтынчы ботак буларак, Кырым да аерылырмы – менә бусы әле хәзергә ачык кала.

* * *

Мин монда «төрек агачыннан аерылган ботаклар...» дидем. Аерылудан куркып, булмас хыялларга төшүчеләр менә шул ноктага дикъкать итсеннәр.

Бу хәл өстән караганда аерылудыр. Ләкин бу аерылуның бер тамырдан чыккан биш-алты агач кабиленнән икәнен хәтердән чыгармаска кирәк. Аек реалистлар күз алдындагы фактка каршы бара алмыйлар. Шуның илә бәрабәр, аларны «аерылу» дигән бүкәй дә куркыта алмый.

Бу халыкларның телләре, әдәбиятлары башка булса да, күңелләре бер булачак. Бер тамырдан таралып, биш агач рәвешендә үскән ул әдәбиятлар, җирле туфракка җирле һава белән

---

*Җәгърафи вазгыяте* – географик урыны, хәле.

*Әхвале* – хәлләре.

сугарылсалар да, югары менгән саен, алар тагы бер-беренә якыная барачаклар. Җир йөзендә төрек ыруглары яшәгән өлкәләрнең һәммәсен эченә ала торган зур бер даирә (фәразыя) сызыйк.

Тарих шул даирә эчендәге халыкларның кайчандыр гомуми (диярлек) бер тел вә бер әдәбият астында оешканнарын сөйли, һәм ул табигый дә булган. Чөнки ул вакыт алар бер хәят, бер язмыш вә бер куәт астында булганнар.

Соңгы заманда ул куәт югалып, уртак хәят биналары ярылган. Язмыш шул киң даирә эчендә төрле тирән сызыклар ясаган. Нәтиҗәдә шул сызыклар җәгърафи тарихи, сәяси, икътисади вә рухи җәһәттән бер-беренә байтак башка булган аерым бишалты өлкә ясаганнар; болар Төркестан, Казакъстан, Татарстан, Кавказ, Анатулы вә Кырымнан гыйбарәт булып, шунда биш (яки алты) әдәбият туарга иҗбар иткән.

Бу фактлар белән хисаплашмау хәят белән әдәбият арасындагы мөнәсәбәтне аңламаудан башка нәрсә түгелдер.

Телләр, әдәбиятлар үзең теләгәнчә ясалмый. Алар хәят рухыннан ихтыярсыз килеп туа. Кемнәрнеңдер фикере, хезмәте – бу мәсьәләдә диңгез дулкынында өсткә күтәрелгән күбекләр генәдер.

## ӘДӘБИЯТ ДӘРЕСЛӘРЕ

<...>

Хис белән хыялдан туган җырлар, әкиятләр, гомумән, халык әдәбияты – һәр милләтнең әдәбият бинасы нигезендә беренче ташлар, әдәбият тарихында болар – биссмиллаһлар.

Димәк, һәр милләттә халык әдәбияты бар, һәр милләтнең әдәбият тарихы халык әдәбияты белән башлана.

Ләкин милләтләрнең яшәгән урыннары, заманнары вә башка хәлләре тәэсире белән халык әдәбиятлары камиллек җәһәтеннән бик аерылалар. Гомуми мәдәният агымыннан читтә калган мил-

---

*Фәразыя* – хыялда гына.

ләтләрнең язма әдәбиятлары шул халык әдәбиятының табигый үсүеннән бер агачның тамыры белән гәүдәсе рәвешендә бәгланып барудан гыйбарәт булса да, күп кавемнәрнең язма әдәбиятында чит тәэсире бик куәтле була. Бу тәэсир ике төрле сәбәптән килә: 1) башка бер кавемнән дип кабул итү. Мәсәлән, руслар христианлыкны кабул иткәч, аларның язма әдәбияты юнан тәэсиренә бирелә. Төрек вә фарсыларда ислам кабулларыннан соң гарәп тәэсире куәтләнә; 2) мәдәнияткә кушылу. Шул ук русларда Гареб мәдәниятен ала башлау белән, Гареб әдәбияты яңа эз сала, әдәбият андагы рәвешне ала. Төрекләрдә Гареб мәдәниятенә аяк баса башлагач, Шинасилар туа[1], әдәбиятында Гареб рухы, Гареб шәкеле хөкем сөрә башлый.

Кыскача әйткәндә, куәтле бер елга рәвешендә агып барган мәдәният үз юлына тугры килгән вак суларга яңа бер төс, яңа бер тәм бирә, үзенчә ясый.

Мисыр, Бабил мәдәниятләренең тугрыдан-тугры хәзерге мәдәнияткә бәйланышы юк[2]. Һинд-кытай мәдәнияте гомум адәм балаларын эченә алырлык[3] киң бер агым тудыра алмадылар. Никадәрле куәтле булса да, алар читтә ялгыз актылар. Башка елгалар аларга кушылмады.

Хәзерге мәдәният елгасы үзенең башын Юнаннан алган. Шул көннән бирле арада байтак тукталулар белән булса да, ул ага, куәтләнә, барган саен киңәя һәм вак елгаларны куша, һәммә җирдә үз рухын сала бара.

Тарихны нык эшләп юлга салган Гареб дөньясы әдәбиятны да шул Юнан чишмәсеннән башлатып, аның тарихи зынҗырының очын шунда илтеп тери. Башка милләтләрнең әдәбият тарихлары аз-маз тикшерелсә дә, алар, үз алларына бер агым булып, хәзерге әдәбиятны тудыруда хезмәт күрсәткән танылмыйлар.

Кыскасы, әдәбиятны Юнаннан башлап хәзерге көнгә туктаталар. Әдәбият тарихы дигәч, аның дәверләрен тикшерә башлагач, бер-берсенә бәгланып килгән алмашынуларны Юнаннан башлыйлар. Мәсәлләр, романнар, идиллияләр вә поэмаларның тарихи тәкәммелләре мәсьәләсе кузгалса, аларның бишеген

---

*Тәкәммел* – камилләшү.

Юнан мәдәнияте эчендә күреп, иң элек юл ачучысы Эзоп, Һомер[4], Софокл[5] булды дип китәләр.

Европа өчен бу хәл табигыйдер. Чөнки алар тугрыдан-тугры Юнан тәэсирендә, әмма Шәрык өчен бу хәл һәм көчләнү, һәм яңлыштыр. Ләкин без хәзер моңа каршы бернәрсә дә эшли алмыйбыз. Шәрык сүнгән, анда караңгы, шул караңгылык аның үткәнен дә җоткан. Хәзер әдәбияты нәзарияләрендә бөтенләй Европа карашы хөкем сөрә, борынгы Шәрык тукталган ноктадан алып китеп, алар әдәбият тикшерүне фәнни бер ысулга салганнар, аны тасниф иткәннәр, һәр сыйныфның тарихын тикшергәннәр.

Безнең әдәбиятымыз да Гареб эзенә төште. Гомуми мәдәният агымыннан аерылып, үземезгә бер юл тотуның мәгънәсезлеге ачык мәгълүм булганга, табигый, буңа шатланамыз гына. Гареб мәдәнияте димәк – туктаусыз алга барырга тиешле булган бәни адәм хәятының хәзергәчә ирешә алган баскычларының соңгысы димәктер. Болар бар да мөкаддимә иде. Әйтергә теләгәнем: һәр кавемнең үз эченнән, үз рухыннан халык әдәбияты тууы табигый, кай халыкларда язма әдәбият шул үз эчендә туган маддәләрдә генә үсә, кайберләрендә дин яисә мәдәнияте алу сәбәпле, чит тәэсиргә төшә, димәк, хәзер бөтен Европа мәдәнияте юлына басты. Шул сәбәпле әдәбиятларда да Гареб рухы, Гареб шәкеле хөкем сөрә. Әдәбиятны аңлауда, тикшерүдә һәммә милләтләр алар ысулы белән бара, Европада исә әдәбият агымын Юнанга барып тоташтыралар. Әдәбият төрләренең һәрберенең үсү тарихын Юнаннан башлыйлар икәнен бәян кылмак, ниһаять, безгә дә шул юлдан бару кирәклеген сөйләмәк иде. Матбугатымызда бу хакта бернәрсә дә юк. Гомуми әдәбият агымы хакында тарихи әсәр булмаган кебек, ул тугрыда тикшерергә, сыйныфта укырга һичбер тәрҗемә дә юк.

<…>

---

*Тасниф иткәннәр* – язганнар.

*Бәни адәм* – кешелек.

## ТАТАР ТЕЛЕН НИЧЕК УКЫТЫРГА?

*(Телемезнең методикасы хакында бер тәҗрибә)*

<…>

1. Адәмнең уйлавы аның теле белән бик нык багланган. Рух һәм тел галимнәре «кешедә уйлау куәтенең үсүе, уйларның ачык вә бөтен рәвеш алуы аның теленең киңәюе, сүз вә лөгатьләренең бай булуы белән бик нык баглы» икәнен, «тел – уйлауның коралы, уйның калыбы» идекен икърар итәләр.

<…>

Димәк, безнең уйлавымызда телнең хезмәте бар.

Татар телен укытуның гыйльми әһәмиятләреннән берсе менә шул ноктадандыр: ана теле дәресләре шәкертләрне сүз вә җөмләгә баета. Шуның белән уйлаулары өчен гомер буенча кирәк була торган коралларның берсен алар кулына биргән була.

Монда яңлыш аңларга ярамый: адәм уйлау вә мөхакәмә өчен кирәк булган материалларны табигатьтән, хәяттан, китаптан ала. Уйны асыл тудыручы – шул өч нәрсә. Ләкин шулар тәэсире белән туган уйны мантыйкый мөхакәмә рәвешендә ачык вә билгеле бер сурәттә алып баруында һәр уйның тышкы калыпка сугылуында телгә – сүз вә җөмләгә хаҗәт төшә.

Икенче яктан, баланың гакылын эшләтер, фәнни рәвештә уйларга хәзерлек бирү өчен, ана теле – иң уңайлы бер материалдыр. Мәктәп белем бирү белән генә калырга тиеш түгел, баланың зиһенен ачу, гакылын тугры (фәнни) уйлау юлына төшерү дә – аның төп бурычларыннан. Хәлбуки ибтидаи укучы балада үз теленнән башка һичбер материал юк. Татарча хәреф, сүз вә җөмлә аңа ят нәрсә түгел. Ана теле дәресләрендә боларны аз-аз тикшерә, араларындагы аермаларны, бер-беренә охшашларны күрә, шулардан нәтиҗә чыгарып өйрәнә. Шул нәтиҗәләрне

---

*Рух галимнәре* – психология галимнәре.

*Мөхакәмә* – логик фикерләү, хөкем йөртү, төшенчәләрне бер-берсе белән бәйләп чагыштыру.

*Мантыйкый* – логик.

яңа мисалларга татбикъ кыла. Шулай итеп, бу дәресләр кирәк нәрсәләрне белдерү өстенә баланың уйлау куәтен дә эшләтәләр. Үзенә якын әйберләрне – ана теленең хәреф, сүз вә җөмләләрен тикшертеп, акрынлык белән аның гакылын фәнни рәвештә уйлау юлына хәзерлиләр.

2. Мәктәптә ана теле дәресләренең иң зур әһәмияте – аның милли тәрбиягә хезмәт вә тәэсире ягыннандыр.

Хәзерге көндә иҗтимагый гамәлләрнең иң куәтлесе миллият идеке мәгълүм. Миллият бинасының нигез ташларыннан иң ныклысы – тел икәнлеге дә ике сүз булырга мөмкин түгел хакыйкатьләрдән. Тел вә миллият адәмдә табигый. Боларның орлыгы һәркемнең табигатендә бар. Ләкин яхшы тәрбия ителмәсә, йирдә булган орлыкларның йимеш бирми калуы, бирсә дә начар булуы бик мөмкин. Төп максаты – хәятка хәзерләүдән гыйбарәт булган мәктәп бу мәсьәләдә тик торып кала алмый, бу йә теге якка үзенең тәэсирен күрсәтә. Бу халыкның яшәргә теләве белән икенчеләрнең йотарга уйлавыннан туган көрәшләрнең иң төплесе мәктәптән, мәктәптә ана теле укыту-укытмаудан башлана.

<…>

Милли тәрбиянең куәтле чараларыннан берсе булган ана теленә ибтидаи мәктәптә беренче урынны бирү шул сәбәптән киләдер. Бер телдән чыккан китапларны – әдәбиятны зурлар да укый. Алар да миллият ноктасыннан азмы-күпме тәэсир ала алалар. Ләкин сабыйлыкта салынган тел җәүһәрләре белән зурайгач уку арасында йир белән күк арасы кадәрле аерма бар.

Сабыйның рухы ни бирсәң, шуны алучан, ни салсаң, шуны үзенең гомерлек хәзинәсе итеп урынлаштыручан. Бирелгән нәрсәләр милли тәрбиягә нигез булсын өчен, аңа иң элек үз анасының теле билгеле бер ысул белән йөрәгенә ярып салынырга тиеш. Бала иң элек үз халкының хәрефләрен күрсен, үз авазын ишетсен, үз сүзләрен, үз җөмләләрен тикшерсен. Кечкенә

---

*Татбикъ кыла* – куллана, кулланып карый.

*Идеке* – икәнлеге.

куллары иң элек үз хәрефләре белән үз ана теленең сүзләрен язсын! Һәрнәрсәне йотып алырга әзер торган сабый йөрәгендә болар – каты мәгъдәнгә үткен корыч белән казып язылган кебек, мәңге бетмәслек тирән эз салачаклар, һәм шул беренче нигез булачак. Сабыйның гакылы икенче дәрәҗәдә тора. Һәрнәрсәне ул тойгысы белән каршы ала. Аның тойгысына азык булачак нәрсәләр дә милли телнең асыл җәүһәрләре булсын: иң элек сөеп укыган әкиятләре үз телендә, үз бабаларыннан калган, үзенә таныш каһарманнар хакында булсын, иң элек ишеткән зур вакыйгалары, олуг каһарманнары иң элек исемен күргән, исемен ишеткән язучылары үз халкыннан булсын – болар аның хыялын үз халкымыз хәятына, уйларын, тойгыларын үз каһарманнарына баглар һәм бала боларны ихтыярсыз сөяр, рухы белән шуларга багланыр. Милли тәрбиянең төп нигезе дә шундадыр.

«Тел» дигән нәрсә сүз белән җөмлә генә түгел, тел дәресе димәктә имля вә сарыфның кагыйдәләрен ятлату гына түгел, болар тышкы як кына. Телнең эчендә халыкның рухы, моңы, уй вә тойгысы яшеренгән. Бу – бер хәзинә. Телнең камил алынуы нәтиҗәсендә бала ихтыярсыз шул хәзинәне сөя, шул рух белән сугарыла. Бала үзен халыкның углы итеп хис кыла. Мәктәпкә халык баласы* булып килгән Миңлебай аннан әдәби телле, әдәбиятлы бер милләтнең әгъзасы булып чыга.

<…>

## ЯҢА ӘДӘБИ ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ БАСКЫЧЛАРЫНДА

<…>

Татарның Урта Азия белән мөнәсәбәте көчле булды. Сәүдә кәрваннары йөреп торды. Шуның белән шәкерт, гыйльми ысул килә торды. Төркестан авторитет иде. Мантыйк, чалмачапан, схоластика белән безгә чыгтай әдәбиятын белүчеләр дә,

---

*Мәгъдәнгә* – металлга.

* Ягъни «җирле, кабиләви халык» (диалект) мәгънәсендә.

Бакыргани, Ясәви, Рабгузый, Нәваинең дә әсәрләре кайтты[1]. Икенче яктан, хаҗилар Истанбулдан, Анатулыдан кайбер китаплар китерделәр, «Мөхәммәдияләр» бездә үз җәүһәре кебек урын алды[2]. Менә шул ике – чыгтай һәм госманлы – тәэсире астында татарның борынгы әдәбияты яшәде, акрынлап үсте, мөндәриҗәне генә түгел, әдәбилекне дә, өслүбне, истыйляхны да шул тәэсир астында ясады.

Шул нәтиҗәдә бездә бер әдәби тел ясалды. Бу – ярым чыгтай, чирек госманлы калыбына сугылган, чобар төрки теле иде.

<…>

Каюм 1860 елларда язган әсәрләрендә үк, гарәп, фарсы истыйляхларга күп урын бирсә дә, җөмлә төзү, өслүб, тәркиб мәсьәләләрендә чыгтай һәм госманлы тәэсиреннән бөтенләй котылырга тырыша. Моның белән теге югарыгы дәвер әсәрләреннән бөтенләй башка бер юлга таба атлаганлыгы сизелә. 70 нче, 80–90 нчы елларга таба инде ул моны аермачык рәвештә нәзари яктан да нигезләргә тели. Мәкаләмнең башында китерелгән аның бер җөмләсе генә дә бабаның бөтен эшләренең программасын күрсәтергә җитсә кирәк. Ул анда «татар халкы», «татар милләте» дип атый. Бу бездә беренче мәртәбә кузгала. Телне «татар теле» дип атый. Бу нокта да аңарчы әдәби тел хакында һичкем тарафыннан кузгатылмаган бер нәрсә иде. Насыйри боларны аңлап, кирәксенеп кузгата да: «Шул юлда бер хезмәтче булаем», – дип, 35–40 еллар эшли.

<…>

Шулай итеп, ул борынгы әдәби телне ташлап, яңаны башлады. Аның истыйляхлары арасында килешсезләре күптер. Аның теле дә гарәпчәдән, фарсычадан бөтенләй котылып җитә алмады. (Бу – беренче юл ачучыларда бик табигый бер хәлдер.) Шуның белән бергә, ул үзенең теле, өслүбе белән теге югарыдагыларга һич тә чагыштырылмаслык дәрәҗәдә яңа һәм татарчадыр.

<…>

---

*Истыйляхны* – терминны, атаманы.

**Замандашлары.** Мәрҗани күп әсәрен гарәпчә язды. Татарча язган «Мөстафад»е 1897 елда гына басылганга күрә, яңа әдәби татар теленең таралуы, эшләнүе хакында зур тәэсире булмады. (Мәрҗанинең роле башкада: татар тарихын тергезүдә һәм, тәкълидне җимереп, иҗтиһад капусын ачудадыр.)

Насыйри белән Мәрҗанигә караганда кискенрәк, радикальрәк, сулрак булган Фәезханов Хөсәеннең[3] әсәрләре үз заманында басыла алмады. Шуңа күрә аның сарыф-нәхү юлындагы хезмәте гамәли яктан тик тар бер даирә эчендә генә калды.

Шулай итеп, бу тел бабындагы хезмәтнең зур төп нигез бурычы (бигрәк тә беренче адымнарда) тик Насыйрига йөкләнде. Ләкин ул иттифакый килеп чыккан хезмәт түгел иде, тарихи-мәҗбүри бер хәрәкәт иде. Заман үткән саен, моңа кушылучылар була килде. Исеме тарихка кергәннәрдән мәшһүррәге Муса Акъегетзадә[4] булып, 1886 елда моның «Хисаметдин менла» дигән хикәясе чыкты. Бу вакыт Кырымда «Тәрҗеман»[5] бөтен төрекләрне бер гомуми әдәби телгә чакыра иде. Насыйри һичбер вакыт аның тәэсиренә төшмәде. Ләкин Акъегеткә Кырым тавышы бераз әсәр иткән. Аның хикәясендә госманлык эзе юк түгел. Кечкенә бер гыйбарә моны ачык күрсәтәчәк:

«Җаным, Хәнифә ханым! Нурлы йөзегезне әүвәл күрдегем илә вөҗүдем мөтәэссир улды. Кач вакытлар хыялымда сәнең җәмаләтең тәхәйел улыныр, кач кичә уйкумдә сән мөкаддәсәйе күрмәкдәйем!..»

Ләкин Гаспринский шундый бер телгә чакырса да, Насыйри башлаган юлның киңәюен күрәбез. Мәсәлән, 1889 елда Казан шәһәрендә «Тәрбияле бала» исемендә басылган бер китап (Хәсәнгата мулла Мөхәммәд углының әсәре) баштанаяк шундый

---

*Тәкълидне* – элеккегә иярүне.

*Иҗтиһад* – тырышлык, яңаны ачу.

*Иттифакый* – очраклы.

*Төрекләрне* – биредә: төрки халык һәм кабиләләр.

*Вөҗүдем мөтәэссир улды* – бөтен барлыгым белән тәэсирләндем.

*Җәмаләтең тәхәйел улыныр* – матурлыгың күз алдыма килер.

садә, Насыйрины тәмам рәхәтләндерерлек, үз юлының көчәя башлавын күрерлек саф татарча белән язылган...

<…>

1896 елда* Заһир Бигиевнең беренче романы «Гүзәл кыз Хәдичә» басылып чыга. Бу әсәрнең өслүбендә бик аз гына госманлылык, «Тәрҗеман» тәэсире бар, ләкин ул да бик аз.

<…>

Бу рисаләнең ахырына Риза хәзрәтнең бер мәктүбе басылган. 1897 тарихлы бу мәктүбтә хәзерге карт мөхәррир тел турында, әдәбилек турында фикерләрне җыя да, моның нигезе, кыска тәгърифе: «Иң гади гавамлар авыл кешеләре укыб аңларлык... рәвешдә ачык язмак, җиңел язмакдыр», – ди.

Бу мөхәррир үзе әсәрләрендә, әле хәзер дә Насыйрилардан күбрәк гарәпчә сүзләр кушса да, аның XIX йөз ахырларында әйтелгән ул сүзе Каюм баба тарафыннан башланып, эшләнеп килгән яңа әдәби татар теле мәсләге үзенә тарафдарларын арттыруда дәвам кылганын күрсәтер. Акъегетнең «Хисаметдин»еннән 15 еллар, Заһирнең «Хәдичә»сеннән өч ел, Галимәтелбәнатның садә телле «Әдәб»еннән ике ел үткәч, Садри, Максудовның «Мәгыйшәт» дигән озын хикәясе[6] белән Г. Исхаковның «Тәгаллемдә сәгадәт, яки Гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» дигән иң беренче кечкенә хикәясе[7] чыга. Боларда гарәпчә байтак «улыр», «дил» кебек бик аз «Тәрҗеман» тәэсире күренә. Ләкин төпләре шул кырык еллар буенча туктаусыз эшләнеп килгән яңа әдәби татарча юлындалар. (Садри Максудов ни өчендер, үзенең «Мәгыйшәт»ен татар шивәсендә чыккан беренче роман дип атый.) Шуннан ике ел вакыт үтә. Каюм баба, башлап юл ачкан, гамәли-нәзари яктан эшләп, ул юлы кырык ел буенча барган яңа әдәби татар теленең көн-төн үсеп, киңәеп барганын күргән хәлдә, 1902 елда вафат була.

<…>

---

* Дөресе: 1887.

*Тәгърифе* – билгеләмәсе.

*Гавамлар* – массалар, гади халык.

Насыйриның ахыргы елларыннан башлап, бездә ике агым көрәште. Фатих Кәрими кебек кайбер мөхәррирләр («Аурупая сәяхәт», «Кырымә сәяхәт»)[8], Тукай кебек шагыйрьләр («Мөхәммәдия дәвере»)[9] байтак вакытлар ярым «Тәрҗеман», ярым госманлы тәэсирендә бардылар.

Ләкин тормышның төбеннән табигый рәвештә күтәрелеп килгән халык хәрәкәте әдәбиятны, матбугатны үзенә корал иттерергә тели иде. Буның өчен җанлы халык теле лязим иде. Бу хәл адашканнарны юлга салды, «Тәрҗеман» тәэсирен куып чыгарып, Насыйриларның «татар теле» юлын ачкан агым мәйдан алды.

Буның белән бергә «татар» сүзенә каршы Риза хәзрәт, Хәсән Гали, Гаспринскийлар тарафыннан зур бер гыйсъян ясалды[10]. «Без татар түгел» дип гауга куптардылар. Боларның гаугасы аркасында шөбһәгә төшкән бәндәләр «Төрки сарыфлары», «Төрки нәхүләре» яздылар (Фәйзи, Кәбүтәри, Һади Максуди, Әхмәдҗан Мостафа, Г. Тәүфикъ әсәрләре)[11]. Ләкин бу мәсьәләдә, бара торгач, табигый юл көчәйде. 1910–1911 еллардан алып, димәк, Насыйриның вафатыннан ун еллар үткәч, «татар теле» нәзарияттә һәм мәктәптә төрекчеләрне дә, төркичеләрне дә камил җиңде. Татар теле, татар сарыфы, татар нәхүе кебек мәфһүмнәр мәктәптә дә, матбугатта да мәйдан алды.

Тормышның тамыр тибүен дөрес сизү аркасында, баба яңа әдәби татар теленә юл ачкан иде. «Татар» дип атавы өчен дә, «татар теле» дип әйтүе өчен дә күп-күп еллар буенча аңа каршы хәрәкәтләр күп иде. Бер яктан, динчеләр: «Без татар түгел, мөселман», – диләр, татарча язып маташуны наданлыктан саныйлар иде. Болар «гарәпчеләр» иде.

Икенче яктан, төрекчеләр белән төркичеләр: «Без татар түгел, без – төрек», – дип саташалар иде. Каюм бабага мөнәсәбәтләрдә пантюркистларның әле дә бераз эчкәрәк яшеренгән агулы тешләре юк түгел.

---

*Гыйсъян* – гауга.

*Мәфһүмнәр* – төшенчәләр.

Ләкин тормыш үзенекен алды. «Тәрҗеман»ның гомуми әдәби төрек теле үзе белән бергә кабергә китте. Насыйриларның әдәби татар теле, барган саен көчәеп, яңадан-яңа көчләрне үзенә тартты, эшләтте, зур агымга – елгага әйләнеп, баеп, матурланып, хәзер инде нәзарияте, тарихы белән бергә Татар Җөмһүриятенең дарелфөнүн мөнбәрләрендә өйрәтелү дәрәҗәсенә килеп иреште.

Менә шул үсеп, баеп, киңәеп килгән яңа әдәби татар теленең иң авыр, иң мәшәкатьле һәм бик күп хезмәткә бик аз нәтиҗә биргән беренче баскычларында ялгызы диярлек беренче юл ярып баручы Каюм баба иде.

---

*Дарелфөнүн мөнбәрләрендә* – университет кафедраларында.

# «БЕЗГӘ ТАРИХ ВӘ ДӨНЬЯ ТАРАФЫННАН БИРЕЛГӘН “ТАТАР” ИСЕМЕ БАР. БУ – ВАКЫЙГ; БУ – БӘДИҺИ»

*(МИЛЛИ ҮЗАҢ ҺӘМ АНЫҢ НИГЕЗЛӘРЕ)*

## БЕЗ – ТАТАРМЫЗ

Уйласаң исең китәр: үземез татармыз, әмма «татар» дигән исемнән качамыз. Бу хәл, бу безнең үземезгә бирелгән исем белән аталырга теләмәвемез, борын яхшук көчле һәм бик тупас рәвештә хөкем сөрә иде. Татарга «татарлыгыны» белдергән өчен күңелсез дә, көлке дә булган хәлләр зоһур иткәли иде. Искечелегенең һичбер ноктасына носкан китермәгән бер «мөселманымыз»га «Син татар!» дисәң, ул моны рәнҗүсез күтәрә алмый; кулыннан килгән рәвеш илә мөдафәгагә керешеп, башкача һич булдыра алмаса, өстеңә төкереген чәчеп килә дә: «Ник мине татар дисең, татар керәшен була, мин, әлхәмделилла, мөселманмын!» – дип гайрәт ора башлый. Бу хыял түгел, бу – вакыйг, бу – тормыш.

Татар гавамына читләр тарафыннан «татар!» дип эндәшелсә, эшнең тагы икенчерәк төс алу ихтималы да ерак калмый. «Кит моннан, татарин!*» – дигән өчен чыккан тавышларны күрү, татар агайның шундый бер сүз өчен кулындагы күсәге

---

*Вакыйг* – чын (хәл), чынбарлык.

*Бәдиһи* – ачык билгеле хакыйкать.

*Зоһур иткәли* – килеп чыккалый.

*Ноксан* – кимчелек.

*Мөдафәгагә* – каршылык күрсәтергә, дәгъвалашырга.

*Гавамына* – халкына.

* Бу сүз кириллицада басылган.

белән әйтүчене сугып егу, яисә «авызын кара кан белән юу» хакындагы фәхрияле хикәяләрен ишетү – бик еш очрый торган хәлләрдәндер.

Боларга хәрфиян ышану читенрәк булса да, бу хикәяләрне тудырган эшләр барлыгыны бөтенләй инкяр кылып булмый; татарга «татар!» дигән өчен гафилрәк русның таяк ашаштыруы яки «авызы кара кан белән юылуы» бик ерак ихтималлардан түгелдер. Шуның өчен дә алар, «татар!» дип эндәшмичә, «князь» диләр. Бу искеләрдә шулай иде. Үткән эшкә салават! Элек андыйлар булгандыр да кичкәндер. Инде хәзер алар сирәкләнеп яисә бетеп үк килә, һәм бер яктан ул хәлне мәгъзүр дә күрергә мөмкин иде.

Ләкин хәзергеләрнең бу хактагы нәзарына – яңаларымызның «татар» дип аталудан качуларына ни диярргә? Берәү дә инкяр кыла алмас, бу бары борынгыларымыз кеби таяклар, кара каннар белән түгел, яңача, егерменче гасырча тарикъ илә мөтәрәкъкыйләремез «татарин» дип аталуны күтәрергә теләмиләр. Моңа төрле җирдән шаһит китерергә мөмкин.

Алыйк әдәбият бабын.

Вакыты илә, сыйрыф тарихи бер мәсьәлә улмак сыйфаты илә, «без татармы, дәгелме?» мәсьәләсе кузгатылган иде. Бу башта фәкать «гыйльми» бер даирәдә булса да, бара торгач, чигеннән чыгып китте. Бәгъзе гәзитәләргә бу бик зур мәүзугъ булды [1]; өзелә алмагач ташланган иде, ләкин безнең тирә матбу-

*Фәхрияле* – мактанулы.

*Хәрфиян* – «хәрефкә хәреф», биредә: «чынлап» дигән мәгънәдә.

*Гафилрәк* – (бу хәлләрне) белмәгән.

*Мәгъзүр дә күрергә* – акларга, гафу итәргә дә.

*Нәзарына* – карашына.

*Тарикъ* – юл, ысул.

*Мөтәрәкъкыйләремез* – алдынгы (прогрессив) кешеләребез.

*Бабын* – мәсьәләсен.

*Сыйрыф* – фәкать.

*Бәгъзе* – кайбер.

*Мәүзугъ* – тема, проблема.

гатында да моның тәрәддед хәлендә, хәтта матлубка кире якта дәвам ителгәнлегене ачык күрәмез. Менә карыйк.

Егерменче гасыргача «татар» дип аталып килгән бер кавемне «Инкыйраз» иясе егерме икенче гасырда «болгар» ясап, мөнкариз[2] кылды. Газета вә журналларымыздан күбесе «төрекчә» яки «җәридәи төрки» дип йөртеләләр. Шагыйрьләремездән бәгъзеләр берничә еллар «татар» дип язып килгән иде, бөекләремездән берәүнең тәнбиһе саясендә, «татар» дигәнне «төрек»кә алыштырды. Үзенчә, әүвәлге хатасыннан котылды.

Бу көнгәчә чыккан сарыф вә нәхүләремез, татар теле өчен яздыклары хәлдә, «төрки сарыфы», «төрки нәхүе» дип аталалар[3]. Арада «татар милләте», «татар шәкерте», «татар әдәбияты» тәгъбирләре йөрештерсә дә, күпләр, хосусән бөегрәкләр, боларны кулланмыйлар; күпләремез болар хакында мөтәрәддид булып, «милли әдәбият» вә шуңа охшаш сүзләр йөртәләр. Бу гына да түгел. «Безне “татар” дип әйтмәгез, ул исемне ташлыйк!» мәзмунендә тавышлар да чыккалады. Кемдер, бер Ходай бәндәсе, «Төрек угылы» имзасы белән: «Миңа “татар” димәгез, мин татар түгел, төрек!» – дип акырды. Шуңа кушылучылар да табылды. Тик касдан чыккан «Татар угылы» гына кушылмаска тырышкан булды[4].

Бу икенең моназарәсе гаҗәп бер төс бирә иде. Берсе: «Мин – татар!» – ди. Икенчесе: «Юк, юк, мин – төрек!» – дияр. «Ни өчен?» – дип сөаль бирелгән иде, икесенең дә тыннары кысылды... «Әйе, шулай инде... ул безнең... милләт... бит...», – дип

---

*Тәрәддед* – икеләнү, шөбһә.

*Матлубка кире* – теләгәнгә, теләккә каршы.

*Мөнкариз кылу* – юкка чыгару, бетерү.

*Тәнбиһе саясендә* – кисәтүе нәтиҗәсендә, искәртүе аркасында.

*Сарыф вә нәху* – морфология һәм синтаксис (дәреслекләр).

*Хосусән* – бигрәк тә.

*Мөтәрәддид булып* – кыюсызланып, шикләнеп.

*Мәзмунендә* – эчтәлегендә, мәгънәсендә.

*Касдан* – белә торып, алдан ук әзерләнеп.

*Моназарәсе* – бәхәсе, дискуссиясе.

*Сөаль* – сорау.

тәмам итештеләр. Менә болар – яңаларымызның «фән юлы» илә «татар»лыктан, «татар» дип аталудан качуларының берәр күренешләредер.

Ләкин хаклымы, мәгънәлеме? Күрик.

Әхвальнең эченәрәк кереп, мәсьәлә яргалаган тәкъдирдә, «төрек угыллары»ның бу моназарәләре бер аңлашылмау нәтиҗәсеннән башка бер нәрсә түгел идеке ачык күреләдер. Монда аерым ике җәһәт бар: 1) безнең бөтен дөнья тарафыннан гасырлардан бирле «татар» дип аталып килүемез; 2) безгә тагылган бу «татар» исеменең тарихи җәһәттән тикшерелүе.

Болар икесе бөтенләй башка ике җәһәткә карый. Моның әүвәлгесе – сабит вә мокаттаг бер мәсьәлә: һичкем безнең күп гасырлардан бирле дә һәм хәзер дә «татар» дип исемләнеп йөрүемезне инкяр кыла алмый. Бу – бәдиһи. Монда «Төрек баласы» да ихтиляф итәргә имкян юк. «Татар» исеме безгә тагылган. Дөнья безне «татар» дип атый. Бер эш эшләгән булсак, безнең хакта: «Татарлар фәлән итә!» – дип сөйләгәннәр һәм сөйлиләр. Бу – мәсьәләнең бер ягы. Бәдиһи вә мокаттаг булган, һичбер ихтиляф мөмкин булмаган җәһәте.

Икенче җәһәт исә – тарихның, фәннең бу вакыйга, бу фактка тәтабегъ күзе белән каравыдыр. Бу җәһәтне ачык әйткәндә: «Безгә “татар” дип ни өчен исем бирелгән, бу исем кайдан алынган, безгә кайдан кергән, безне болай дип атау тарих җәһәтенчә тугрымы, юкса яңлышмы әллә?..»дән гыйбарәт булып, сыйрыф фәнни, сыйрыф тарихи бер мәсьәләдер. Бу фәкать мөтәхассыйслар өчен фәнни бер моназарәдән башка бер эш түгелдер. Безнең «татар» дип бирелгән исемебез тарихның бу татбикатенә аслан илтифатсыз бара бирә; милләтләр эчендә без

---

*Әхвальнең* – хәлләрнең.

*Сабит вә мокаттаг* – ачык һәм хәл ителгән (өзелгән).

*Бәдиһи* – ачык (хакыйкать).

*Ихтиляф итәргә имкян юк* – карыша, каршы килә алмый.

*Тәтабегъ* – эзлеклелек, тоташлылык.

*Мөтәхассыйслар* – белгечләр, специалистлар.

*Татбикатенә* – туры китерүенә.

*Аслан* – һич тә.

«татар милләте» аталып китеп утырабыз. Тарихның моназарәсе бу бер кәррә бирелгән вә гомумчә танылган исемне алыштыруда, сарих ялгыш булса да, мең кәррә гаҗиздер[5].

Бер нәрсәгә бер исем, бер гыйлем тагылып, гомумчә, дөньяча танылдымы, дөнья аны шул исем белән атарга өйрәндеме, аннан соң вәссәлам инде, ул исемнең яңлышлыгын мең кәррә исбат итсәләр дә, ул шулай бара бирә.

Максат җиңел аңлашу гына булганга, һичкем андый гомуми исемнәрне үзгәртү хыялына төшми; түгел олуг вә карт бер милләтнең үзе белән бергә торган һәм үскән исемен алыштыру, хәтта фәннең иң караңгы бер почмагында гына, фәкать мөтәхассыйслар арасында гына мөстәгъмәл булган бер истыйляхны алыштыруны да зур мөшкилдән саныйлар. Бер исем, бер истыйлях тәмам гомумләшеп җитсә, аны, яңлышлыгы ачык мәгълүм булганнан соң да, үзгәртергә имкян үк күрмиләр. Бер кавемнең дөньяча мәгълүм исемене алыштыру шуңа кыяс кылынсын!

Әйтәләр: «Без татар түгел, безгә бу исем яңлыш кына тагылган, без – төрек; безне татар димәгез!» – дип. Буннан йә көләргә, яисә, югарыдагы рәвешчә, бөтенләй башка җәһәтләргә карый торган ике хәлне бутаганын вә шул сәбәпле кыяслары мәнсүҗ түгеллекне исбат кылырга кирәк. Беркем дә инкяр кылмый: без – төрекмез, һәм «татар» исеме, ихтимал, безгә яңлыш кына, фәлән кешеләр мөнәсәбәте белән генә тагылгандыр. Ләкин бу «безне татар дип әйтмәгез!» диюгә юл бирми. Алыйк бер мисал.

Һәркемгә мәгълүм: руслар, дөресрәк сүзгә нәзарән, диңгез артыннан килгән бер кенәзнең рус нәселенә мәнсүб

---

*Кәррә* – тапкыр.

*Сарих* – ап-ачык.

*Гаҗиздер* – көчсез.

*Мөстәгъмәл* – кулланылышта.

*Имкян* – мөмкин.

*Кыяс кылынсын* – үрнәк, мисал булсын.

*Мәнсүҗ* – беркетелгән.

*Нәзарән* – караганда, күрә.

булучылыгы сәбәпле генә, «рус» аталып киттеләр[6]. Шул бер кеше славяннардан зур бер бүлегенә исем үзгәртте. Хәл шулай була торып та, һичбер рус «Без рус түгел, без – славян; 80 миллионлы олуг бер милләтне әллә каян килеп чыккан бер варяг исеме белән атап йөртү аслан ярамый!» дип тавыш күтәргәне, һичберсенең «рус» дип аталудан качарга тырыштыгы күрелми. Тикшерсә, ни өчен «рус» дип аталганын мөәррихләр тикшерә. Тик шу кадәр. Әмма вәҗһе тәсмиянең зәгыйфь яисә яңлыш булуына карап, һичберәү «Мине рус димәгез!» һавасенә төшми.

«Безне татар димәгез, без – төрек!» дигән вә шул юлны куәтләгән бәндәләрнең тавышы да гайн шул русның «Мин рус түгел, славян!» дип игътиразы кебектер. Соңгысы никадәр мәгънәсез исә, әүвәлгесе аннан да ямандыр. Вәҗһе тәсмия теләсә нәрсә булсын һәм син аны тикшереп, яңлышлыгы, зәгыйфен мәйданга чыгарырга хакың бар; әмма шул яңлышка карап, ул исемнән качарга омтылу – һәм габәс, һәм мәгънәсез бер эштер. «Безне “татар” димәгез, “төрек” диегез!» мәзмунендәге хәрәкәт – ул финәфсиһи дә мантыйксызратыр. Безнең төреклегемезне берәү дә инкяр кыла алмый. Ләкин шул як бар: төрек – олуг бер кавем; ул берничә бүлекләргә аерылган. Бу бүлекләрнең һәрбере төрле исемнәр илә йөри; без дә шул бүлекләрдән берсе – төрек кавеменнән дә хасрак исеме татар булган бер кавембез. Без – «татар» аталган төрек кабиләсе; русның славян булучылыгы «рус» дип аталырга нәкыйз булмаган кебек, безнең дә төрек булуымыз «татар» дип исемләнеп йөрүемезгә каршы бармый.

---

*Мәнсүб булучылыгы* – бәйләнеше, нисбәте булуы.
*Тырыштыгы* – тырышуы.
*Мөәррихләр* – тарихчылар.
*Вәҗһе тәсмиянең* – исем бирүнең, атауның.
*Һавасенә төшми* – «һаваланмый» мәгънәсендә.
*Гайн* – шундый ук, нәкъ.
*Игътиразы* – каршы сөйләве, карышуы.
*Габәс* – файдасыз.
*Финәфсиһи* – нигездә, асылда.
*Мантыйксызрактыр* – логикасызрак.
*Нәкыйз* – каршылыклы.

«Төрек» наме славян, герман, романнар кеби гомуми бер исем булып, соңгылар эчендә төрле исемнәр илә йөргән әллә ничә милләт булдыгы кеби, төрек тә төрле исемнәр илә йөртелгән кавемнәргә аерылган. Хас исемемезне ташлап, «төрек» дип атала башласак, без башка төрек кабиләләре илә мөляббәс буламыз.

Кыскасы, безгә тарих вә дөнья тарафыннан бирелгән «татар» исеме бар. Бу – вакыйг; бу – бәдиһи. Һәм шулай дип, тәсмиянең вәҗһесен тикшерү бар. Соңгысы сыйрыф тарихи бер мәсьәлә булып, һичбер тәкъдирдә «гыйльми моназарә» даирәсеннән чыга алмый; бу моназарә безгә «татар» дип аталуның зәгыйфен, хәтта яңлышлыгын кояш мәртәбәсендә исбат кылса да, безнең исемемезне алыштыра алмый. Ул исбат тик тарих фәненә, тарих китапларына бер үзгәреш бирер. Әмма «татар» исемен ташлап, «болгар, төрек» йә башкача бер исем бирер вә гомум дөнья безне шулай дип йөртә башлар, «татар» сүзе онытылыр дип уйлау – бу мөхальле фарыздыр. Олуг вә карт бер милләтнең үзе белән бергә туган, бергә үскән вә гомумчә танылган бер наме алышыну мәсьәләсе – вөҗүде мөхтәмәл булмаган эшләрдән береder.

Шуның өчен без вәҗһе тәсмиянең шөбһәле булуына карап, «татар» дигән сүздән качарга, аны үземезгә иснадта мөтәрәддид булырга аслан урын юк. Ул – безнеке. Ул моңарчы килде һәм кабергәчә безнең илә барачак, һәм ул безнең төрек милләтеннән булуымызга каршы түгел. Без – төрек кенә түгел, монголбыз да[7]. Без – адәм; без – монгол; без – төрек; без – татар.

Вәҗһе тәсмиясен тикшерүне фәкать тарихи бер мәсьәлә итеп, әрбабына ташлыймыз да, вакыйгда, тормышта «татар»

---

*Мөляббәс буламыз* – буталабыз, катышабыз.

*Бәдиһи* – көн кебек ачык.

*Мөхальле фарыздыр* – «булмастайны таләп итү» мәгънәсендә.

*Вөҗүде мөхтәмәл булмаган* – булуы ихтимал да булмаган.

*Иснадта мөтәрәддид* – кушуда кыюсыз.

*Вәҗһе тәмсиясен* – исемен, аталышын.

*Әрбабына* – «(тарихның) язучыларына, белгечләренә» мәгънәсендә.

аталып бара бирәмез. Эшләремезне татар эше дип атыймыз; үземез – татар; телемез – татар теле; әдәбиятымыз – татар әдәбияты; эшләгән һәммә эшемез – татар эшләре; туачак мәдәниятемез татар мәдәнияте булачак.

## «БЕЗ КЕМ?» БӘХӘСЕ

– Ходаем, күр инде без бәхетсез колларыңны! Һаман бит үземезнең ничек дип аталырга тиешлегемезне белер мәртәбәгә дә җитә алмыймыз! Байтактан чәйнәлеп килгән «Без кем?» мәсьәләсенең батыры, «Төрек угылы», һаман ул моназарәне куерта тора[1]. Минем үткән елгы «Шура»ның сигезенче номерында «Без – татармыз» атлы бер мәкаләчегем бар иде. «Төрек угылы», үзенә каршы әйтелгән бер сүз улмак сыйфаты белән булса кирәк, аңа маддәләп җаваплар бирде, шул мөнәсәбәт белән байтак нәрсәләр сөйләде. Ул тарих сәхифәләрен актара, аннан үзенә дәлилләр эзли, «татар» дип аталуның хәзерге тормышыбызга бирәчәк зур афәтләрен, бу хәл төрек кабиләләренең әдәби җәһәттән берләшүенә зур зарар бирәчәген-фәләнен яза; хәтта, бөтенләй чыгырыннан чыгып, хөкүмәт канцелярияләрендәге язулардан үз сүзенә куәт алмак була. Әйтергә мөмкин, аның сөйләгәннәренең һичбере ялган булмас. Аңа ышаныйк. «Татар» сүзен безгә тик Карамзин таккан булсын, Уфада башкортлар өчен булган бер мәктәпкә «татар» дип аталганнарны алмасыннар. Аның тагын әллә нинди зур афәтләре булсын – һәммәсенә кул куйыйк. Ләкин боларның бит һичбере сезне «Без татар дип аталмыйк» дигән дәгъвагызда хаклы итеп чыгара алмыйлар.

Минем бу хакта әйтәчәк яңа сүзем юк. Кирәк дип тә белмим. Тик «Төрек угылы» әфәнде байтак дөрес сүзләр сөйләсә дә, моназарәнең бөтен әсасен тоткан бик садә бер ноктаны хәтереннән чыгара икәнен күрсәтү өчен, «Без – татармыз» мәкалә-

---

*Моназарәне* – бәхәсне.
*Маддәләп* – пунктлап (җентекләп).
*Әсасен* – нигезен.
*Садә* – гади.

сендәге кайбер мәфһүмнәрне бу урында тагы телгә алырга мәҗбүрмен.

Әйтелдекенчә, «Без кем?» мәсьәләсендә ике җәһәт бар: берсе – безгә «татар» исеменең ни сәбәп белән тагылуын, болай дип атау тарих буенча дөрестме, әллә яңлышмы икәнен тикшермәк. Икенчесе – бөтен дөнья тарафыннан әүвәл дә һәм хәзер дә безнең «татар» дип аталып йөрүемез. Бу, – әлбәттә, факт: күзе, колагы сау булган һичкем безгә бөтен дөнья тарафыннан бөек төрек милләтенең «татар» атлы бер кабиләсе дип каралуында, безнең «татар» дип аталуымызда, әлбәттә, шик кылмый. Әмма әүвәлге җәһәт ул сыйрыф фәнни, гыйльми булган бер моназарәдән гыйбарәт. Дәлилләр чыгып, безем «татар» дип аталуымызның яңлышлыгы якты кояш мәртәбәсендә ачык исбат ителсә, шул тәкъдирдә дә ул фәнни бер мәсьәләнең хәл кылынуыннан гыйбарәт булып кала. Әмма аңа карап, һичбер вакыт бездән «татар» дигән сүз алына алмас. Ул яңлыш булыр. Бөтен дөнья аның яңлышлыгын белер, аның зур афәте дә булыр. Шул хәлдә дә ул алыштырыла алмас. Чөнки ул – мөхаль бер эш. Андый бер мәртәбә бирелгән исемнәрне, яңлыш булса да, әүвәлгечә дәвам иткәнлегенә адәмнәрдә, фәнни истыйляхларда, милләтләрнең, мәмләкәтләрнең, хәтта Америка шикелле бөтен бер кыйтгаларның исемнәрендә дөнья тулы мисал бар. Шуңа күрә ул моназарәне үзенең фәнни җәһәтенә хозар кылып, «безне татар димәгез» җәһәте күптән сөкүт ителергә иде. Юк гауга, җирне күчәреннән бераз читкә чыгару планыннан да ераграк хыял!..

---

*Мәфһүмнәрне* – мәгънәләрне.

*Сыйрыф* – тулысынча, фәкать.

*Мөхаль* – мөмкин булмаган.

*Кыйтгаларның* – континентларның.

*Хозар кылып* – калдырып.

*Сөкүт ителергә* – туктатылырга, туктарга.

## БӘЙРӘМ МӨБАРӘК БУЛСЫН!

Без, татарлар, исламны соң кабул иттек[1]. Олуг бабамыз Чыңгыз мөселман түгел. Аның тарафыннан төзелгән бөек императорлык үзенең шәүкәтле көннәрендә ислам илә галякалы булмады.

Гомумән, тарихымызның мөмтаз шанлы көннәрендә ислам куәте тәэсирен эзләргә урын күренми. Безнең мөселман була башлавымыз олуг императорлыгымызның зәвалга таба йөз токкан... татар куәте, гомумән, кечерәя башлаган чагына туры килә...

Шуның илә бәрабәр безнең тарихи язмышымызда исламның тәэсирен бөтенләй инкяр итү, шөбһәсез, бик зур сукырлык булыр иде.

Ислам безнең куәтле көннәремездә түгел, бетәргә мәхкүм дәверләрдә үзенең зур тәэсирен күрсәтте. Һәммә тюркологларның шәһадәте илә сабит ки, төрек вә татар кавеме тәмәссел итәргә иң мөстәгыйд халыклардан санала. Кайда... кем эчендә... нинди мохиттә яши – ул миллият җәһәтеннән шуңа җотылырга, шуның эчендә эрергә бара.

Табигать биргән бу йомшаклыгымыз өстенә, язмышымыз белән дә без Казан дәүләте егылганнан соң, тәмамән тәмәссел ителү планы астында калдык. Милли табигать вә тарихи язмышның хәзерләдеге менә шул һәлакәттән коткару юлында ислам безгә каршы чыкты һәм муафыйк та булды.

Голямамыз, аның артыннан халкымыз, миллият наменнән түгел, дин наменнән, ислам наменнән үзенең «үз»легенә,

---

*Шәүкәтле* – көчле, куәтле.
*Галякалы* – бәйләнешле.
*Мөмтаз* – аеруча.
*Зәвалга* – бетүгә.
*Шәһадәте* – күрсәтүе.
*Сабит* – шиксез.
*Тәмәссел итәргә* – иярергә.
*Мөстәгыйд* – булдыклы.
*Голямамыз* – галимнәребез.

искедән килгән хәленә, милли ганганәсенә бер мөтәгассыйб киселде. Шуны җан фидасы илә саклады һәм шуның илә миллият тә сакланды һәм шуның илә «бөтен халык», көенчә тарихның авыр, караңгы кысык көннәреннән үземезне саклап алып чыгып, бу көнге аңлы «миллият» дәверенә ирештерде.

Бу – тарихи як.

Әле соңгы уяныш көннәрендә дә халыкны иң беренче уйгатучылар ислам наменнән ислам әмерләре белән тәрәккый вә тәмәдденгә дәгъвәт итте. Халыкның үз иманына якын булганлык өчен, болар көчле рәвештә тәэсир иттеләр.

Без элгәре исламның бинасы биштер: әүвәл – иман, икенче – намаз, өченче – руза, дүртенче – зәкят, бишенче – хаҗ, дип ятласак, хәзер аның урынына заман мәдәнияте икенче сабак бирә: миллиятнең әсаслары биштер. Халкымызның бөтен бер милләт булып яшәвен теләсәк, максатымызга хезмәт итә торган һичбер нәрсәне читкә тибәрмәскә тиешлемез. Ислам – шулардан бере. Аек реалистлар, үзенең шәхси игътикадын бер якка куеп, дин безем иҗтимагыятемездә олуг бер рөкен идекен аңларга, шуңа күрә аны какмаска мәҗбүрләр.

Бу көн – рабигыләүвәл уникесе. Бу көн – безем халкымызның шәхси вә иҗтимагый хәятында олуг бер куәт булып килгән исламның мөәссисе – хәзрәте Мөхәммәднең дөньяга килгән көне.

Бу көнне олуг итә белүемез, бондый көннәрне зур бәйрәмнәрдән санап каршы ала белүемез илә без яшәргә истигъдадымызны күрсәтәчәкмез: эш вакытында эшли белгән халык бәйрәмендә күңелле бәйрәм дә итә белә.

---

*Ганганәсенә* – традициясенә.

*Мөтәгассыйб* – патриот.

*Тәмәдденгә* – мәдәниятле булуга.

*Дәгъвәт итте* – чакырды.

*Игътикадын* – ышануын.

*Рөкен* – нигез.

*Рабигыләүвәл* – ай елының өченче ае исеме.

*Мөәссисе* – нигез салучысы.

*Истигъдадымызны* – булдыклылыгыбызны.

Бәйрәмнәрнең һәр көн өчен ял итү вакыты икәнлеге җәһәте үзенә... Әмма аның милли җәһәте безем өчен тагы да зур. Хәяты миллиямез төрле яктан изтыйраб эчендә. Аңа бик аз гына ярдәм итәчәк һәр дәкыйкадан файдалана алу безем аек реалистлыгымызны күрсәтәчәк. Дингә җиңел каравы илә мәшһүр булган француз халкының мәркәзе Париж бөтен дөньяда үзе рәсми рәвештә инкяр кылган диненең мөәссисе хәзрәте Гайсә[2] туган көнне, башка христиан милләтләрдән дә артыграк, тантаналы каршы алу белән мөмтаз.

Менә бөтен шу хәлләр өчен бу көнне без чын бәйрәмемез дип каршы аламыз. Һәм дә шул көн шул олуг бәйрәмнең котлы вә мөбарәк булуын ихлас күңелдән телимез.

## ХӘЯТ ВӘ ӘДӘБИЯТ

*(Еллык тәәссорат)*

<...>

Иске китаплар безгә дин, милләт, шәркыять, намус, биззат бер билигъетибар гына, башка дип өйрәтәләр иде. Унтугызынчы гасырның соңгы яртысында килеп чыккан бөек ислам реформаторы – Әфганилар, Габдеһләр дә миллиятне аңлауда ерак китмәделәр[1]. Аларга да милләт бөтен әһле ислам иде. Алардан соң Мисырның Тантави[2] вә Фәрид, вә Җиддиләре бездә Риза казый[3], Рәшид казый[4], Муса Бигиев[5] вә Зыя әл-Камали[6] кеби галимнәр шул эздән киттеләр. Мәрхүм баба Исмәгыйль бәк гомер барынча милләттән бөтен төрек кавемен аңлады[7], аның «телдә, эштә берлеген» теләде, вак бүленүләргә, аерым әдәбиятларга татар милләте дигән исемнәргә зур җинаять дип карады. 905* елларга кадәр бездә миллиятнең шул ике агымы бергә бу-

---

*Изтыйраб* – аптырау.

*Дәкыйкадан* – минуттан.

*Мөмтаз* – башкалардан аерылып тора.

*Биззат бер билигъетибар гына* – үзе бер абруйга лаек кына.

*Әһле ислам* – ислам кешесе.

* Чыганакта шулай язылган. Дөресе: 1905 ел.

талыбрак бара, һичкем аны ачык сызыклар белән аерып тормый иде. 905 ел дулкыннары башка күп яңалыклар белән бергә безнең миллияткә мөнәсәбәтемезне дә реальный бер төскә кертте – яшь буын эчендә «татар милләте» дигән сүз туды, «татар әдәбияты» дип атала башлады.

Халкымыз ниндидер бер тәэсир белән татарлыктан качкан, буның кызык, көлкеләре дә бар. Шиһаб хәзрәт моңа каршы «Татар булмый, кем соң син, әллә чуваш яки мукшымы?» мәзмунендә фикер әйтә[8]. Каюм Насыйри да татар теле ди, аның атасы булырга теләвен, утыз биш ел шуңа хезмәт кылуын сөйли. Ләкин «Тәрҗеман» тәэсире белән бу ике мөҗәддидемезнең фикере бер вакытлар бик нык астка калган, «Шура»да бу хакта «Төрек угыллары» бик кызып моназарә башлаган[9], «татар» сүзеннән ничек мөмкин шулай качарга, аңар протест бирергә тотынганнар иде.

«Шура»да бу хакта анкета сыман бер нәрсә булгач, шул юлларны каралаучы тарафыннан да «Без татарбыз» исемендә бер мәкалә[10] дәреҗ ителгән һәм анда «татар» исеменнән качуның мәгънәсезлеге, тарих вә дөнья тарафыннан танылган ул исемебездән качуның мөмкин түгеллеге, татарлыгымыз төреклеккә каршы түгеллеге, славяннар поляк, чех, руска бүленгән кебек безнең дә аерым оешу мәҗбүрияте булганлыгы сөйләнгән иде. Г. Баттал, Җ. Вәлидов әфәнделәр шул елларда язылган мәкаләләрендә инде татарлык, төреклек мәсьәләсе өзелде[11] дип мөһер дә басканнар иде, соңра аңлашылды ки, бу әле бөтенләй өзелеп бетмәгәнгә охшый. Риза казый, «Әхмәд Мидхәт әфәнде» әсәрендә бу мәсьәләгә яңадан кайтып[12], үзенең әүвәлге фикерләрен тәкрар итә, татарлык тарафдарларының Ильминский мәсләгенә хезмәт итүләрен[13], татар әдәбияты туса, аның янында мишәр, башкорт, типтәр әдәбиятлары да туачагын сөйли. Ризаэддин әфәнденең бу сүзе яңа түгел, ул инде моны берничә язды. Ләкин аның бу елгы әсәрендә, бу фикернең керүе

---

*Мәзмунендә* – мәгънә, эчтәлек.

*Мөҗәддидемезнең* – яңалык кертүчебезнең, новаторыбызның.

*Дәреҗ ителгән* – басылган.

*Тәкрар итә* – кабатлый.

татарлык яклы булган реалист яшь буынга үзенең бу мәсьәләгә карашын яңадан әйтергә бер сәбәп булды.

1914 ел «Йолдыз»ның апрель номерларында «Г.И.» әфәнде тарафыннан Риза хәзрәтнең «Әхмәд Мидхәт» әсәре хакында[14] язылган тәнкыйтьтә бу мәсьәлә җитди рәвешдә кузгатыла, татар әдәбияты дигән аерым бернәрсәнең вөҗүдкә килүе мәҗбүриятен сөйли.

Җамалетдин Вәлидовның 1914 ел эчендә язылган «Милләт вә миллият» исемле әсәрендә[15] бу мәсьәлә тагы киң рәвешдә алынган.

<...>

Хәсән Сабри әфәнде «Тәрҗеман»да һаман бу мәсьәләгә кайтырга ярата[16]. Башы Исмәгыйль бәкнең даһи хыялында булган бу идеалны агым тарафдарларының Мәрҗани, Насыйри һәм хәзерге реалист яшь буын куәтләгән «татарлык»ка каршы куйган игътиразларыннан иң реалисты – гомуми бер телдән аерылу башланса, һәркайда җирле шивә мәйдан алачак, аннан соң безнең халык иге-чиге булмаган вак аерымнарга бүленеп бетәчәк димәктән гыйбарәтдер. Исмәгыйль бәк буны: «Татар, казакъ вә фәлән дип аерылачак булсак, Яубашы белән Эстәрлебашының һәрбере үзенә бер әдәбият, үзенә бер мәдәният тудырырга калыкшачак», – дип тәгъбир итә. Риза казый: «Татар әдәбияты дигән аерым бернәрсә вөҗүдкә килсә, мондый шивә аерылуның заруры нәтиҗәсе уларак, башкорт әдәбияты, мишәр әдәбияты, типтәр, нугай вә башка аерым әдәбиятлар туачак», – ди.

Менә иң нык уйларга тиеш нокта шундадыр.

Вакыйган, бу игътираз нигезсез түгелдер шикелле. Ләкин бу игътираз – тик өстән карауның нәтиҗәсе, бу игътираз тик тышкы карашта гына әсаслы күренә. Әмма мәсьәләнең эченә кереп, бөтен горукмызның тарихи, җәгърафи халәтләре күз

---

*Игътиразларыннан* – фикергә каршы төшүләреннән, кире кагуларыннан.

*Шивә* – сөйләм, сөйләш.

*Калыкшачак* – м о н д а: калкачак, күтәреләчәк.

*Вакыйган* – чыннан да, дөрестән дә.

алдына китерелсә, оешып килгән «татарлык» мәгъдәненең эченә кергән маддәләрен тәхлил ителсә, бөтен игътиразлар үзләренең әсасларын югалтачак, Риза казый дидекенчә, «һәр волость»та үзенә бер әдәбият туу ихтималы үзеннән-үзе җимереләчәктер.

Уралдан Балтыйкка, Кавказдан Шималь диңгезенә кадәр җәелгән киң өлкә бар. Җәгърафия телендә Русиянең Ауру-падагы өлеше дип аталган бу кыйтгада безнең горукмыздан кара нугай, нугай, башкорт, мишәр, татар, касыйм, типтәр, ала-тыр кебек берничә төрле төрки кабиләләре яшиләр. Без боларны «татар иле» дип атыйк.

Моннан өч-дүрт гасырлык алдынгы бер дәвердәге тарихи язмышларында болар араларындагы яхшы ук тирән сызыклар белән аерылсалар да, Русия кул астына керүләреннән соңгы тәкъдирләре аларның араларындагы сызыкларны күмде, аларны бер-берләренә якынайтты.

Һәммәсенең рус кул астында яшәве, низам кашында һәммәсенең сәяси милке вә хокукый мәртәбәсе тәмам бер булу, җәгърафи яктан да бер-беренә җиңел катнашырлык хәлдә утыру, болар өстенә һәммәсенең бер дини мәркәзгә – Уфа мәхкәмәи шәргыясенә караулары боларны үзләрендәге эчке якынлык – дин вә кан кардәшлеге өстенә тышкы дөнья вә матди хәят көчләве белән дә якынлатты, бер-берсенә оешыр мәртәбәгә җиткерә язды.

Шул күп матдә эчендә Казан татары, гүя иң куәтлесе һәм иң уртадагы, фәннирәк әйткәндә, мәркәзнең куәте белән башкалардан югарырак торган иде.

Казанның тарихы – ярым фәҗгый сурәт белән бу кабиләләрнең һәммәсе алдында бераз томанлырак булса да, калкурак бер урында күренә, соңгы хәлләр дә Казанны, Казан татарын шул мәркәзлек куәтен арттыра торырдай рәвешкә куйган,

---

*Мәгъдәненең* – минералының.

*Тәхлил ителсә* – анализланса.

*Шималь диңгезенә* – Төньяк диңгезенә.

*Низам кашында* – канун, закон каршында.

*Фәҗгый сурәт белән* – фаҗигале сурәт белән.

казанлылар – сәүдәгәр халык, алар мал өчен Татарстанның һәр ягын гизделәр. Алар сатучы булып йөрде, ди, алар, әлбәттә, үзләренең кесә файдаларын күзәткәннәрдер.

Татарстанның һәр ягына тараткан шул комган вә кәләпүшләре, шул саурыйлы читек, буяулы башмак шәрифләре белән алар татарлык нигезенә бер таш булса да арттыра тордылар, татарлык мәгъҗүненең маддәләре арасында бергә оешу кабилиятенә җан бирә килделәр.

Бүген татар динемезме, Русиянең Европа кыйсемендә яшәгән төрки кабиләләр «татарлык» исеме эченә кереп оешып баралырмы, мишәре, башкорты, типтәр вә нугай шул татарлык рухыннан туган бер тел вә әдәбият астына җыелып барамы, шуны үзенеке итеп каршы аламы? Боларның һичбере бүген фәлән вә фәләннәрнең язулары белән генә туган түгел, бу хәл гасырлар буенча хәзерләнеп килгән һәм шул хәзерлек тә җәгърафи, сәяси вә тарихи куәтләр белән бергә үк шул атаклы Казан голямасы, шул Сатыш вә Кышкар дамеллалары[17] да үзләренең бөтен Татарстанга тараткан шәкертләре, мөдәррисләре аркылы бик зур көч куштылар.

Болар күңелләргә гомуми бер җеп сузды. Болар киң өлкәдә бер мәркәзлек имкянне тудырды, төрле кабиләләр араларында гомуми җепләр сузылып, аларның да бергә кушылган бер ноктлары була алуын вөҗүдкә китерде. Болар аркасында татарлык югарыда һәм мәркәздә күренде. Болар мишәрлек, башкортлык вә нугайлыкларның татарлык эчендә эрүенә, татар исеме астына шул ничә төрле кабиләнең керүенә, психология буенча юл ача килде. Бүгенге татарлык дәгъвасы менә шул тарихи агымның зарури нәтиҗәсеннән башка нәрсә түгелдер.

Ул шундый күп куәтләр белән хәзерләнә килгән, һичкемнең аңыннан, теләвеннән башка дәвам иткән һәм нәтиҗәдә шул киң

---

*Саурыйлы читек* – атның бот тиресеннән эшкәртелгән күннән тегелгән читек *(Тубыл-Иртыш диалектында).*

*Мәгъҗүненең* – даруының.

*Кабилиятенә* – сәләтлелегенә, талантына.

*Кыйсемендә* – өлешендә.

*Имкянне* – мөмкинлекне.

өлкәдәге төрле кабиләләр бер исем астында оешып, аерым бер вөҗүд булыр мәртәбәгә җиткәннәр.

Җәгърафиядә хәваза (русчасы – бассейн) дигән бер истыйлях бар. Бер хәвазадагы вак елгалар зурракка кушыла бара, ниһаять, алар, барлыгы җыелып барып, бер диңгезгә коялар. Идел хәвазасындагы ничә йөз вак елга берәм-берәм кушыла киләләр, боларны җота барган Идел зурая, тегеләр югалалар, мәйданда тик «Идел» исеме кала – татарлык хәвазасындагы мишәр, башкорт, алатыр, типтәр, нугай кебек вак елгаларның татарлыкка мөнәсәбәтләре дә шуның үзе үкдер.

Кара Идел, Ак Идел, Уфа, Казан суы, белмәм тагы niләр, аккан хәвазаларының тәэсире белән Иделгә кушылып юк булулары, болар бөтен Иделнең зураюы ничаклы табигый булса, Татарстандагы вак кабиләләрнең дә мәдәният вә әдәбият җәһәтенчә татарлык эченә кереп китүләре дә шул дәрәҗәдә табигый һәм заруридыр.

Татар әдәбиятында Татарстанның һәр кабиләсеннән эшчеләр бар, Татарстандагы һәр кабилә шул әдәбиятны мәктәбе өчен дә, матбагасы өчен дә үзенеке, үз бакчасының җимеше итеп кабул кылды.

Әстерхан нугайлары тарафыннан нугай акчасы белән нугайларның үз ихтыяҗларына хезмәт итәр өчен, димәк, нугай укучылары өчен чыгарылып, күбрәк язучылары нугай булган «Идел» гәзитәсе шул татар әдәбияты телендә язылды[18]. Шул хәл башка кабиләләрдә дә.

Чистай мишәрләреннән Г. Исхакый, Фоат Туктаров[19], Шәһид Әхмәдиев[20]; Касыйм татарларыннан «Нур» иясе Баязитовлар[21] һәм татарча матур язучы Шакир Мостафаев[22], Әстерхан нугайларыннан Нәҗип Гасрый[23], Златоус башкортларыннан Хәлим Искәндәров[24], Уфа типтәреннән Мәҗид Гафури[25], Ерак шимальдән тарылы Рәшид казый[26], ерак Себердә чыккан «Сибирия» гәзитәсе[27] – менә бу хәлләр, бу исемнәр безгә ачык күрсәтә ки,

---

*Хәваза* – елга, бассейн.

*Истыйлях* – термин, атама.

*Матбагасы* – басмасы, типографиясе.

татарлык – Татарстанның уртак җимеше һәм аның теле булган татар әдәбияты шул киң өлкәдәге кабиләләрнең һәммәсен эченә алган, һәммәсе шуның астына кереп, аны үзенеке ясаганнар. Бәс, «Тәрҗеман»ның Яубашы белән Эстәрлебашының һәрбере үзенә бер әдәбият тудырачагын сөйләве, Риза казыйның мишәр, нугай вә башкорт әдәбиятлары вөҗүдкә килер дип уйлавы үзен-нән-үзе төшә, җимерелә.

Яубашымы, Эстәрлебашымы, мишәр, башкорт вә нугаймы – алар шул хәвазадагы табигый халәтнең тәэсире белән татарлык елгасына кушылдылар. Моңа кем дә булса хезмәт итмәде, бу – адәм теләкләренә илтифатсыз бара торган тарихи агымның зарури нәтиҗәседер. Хәзерге әдәбият бу фактор түгел, бу сәбәп түгел, бәлки хәяттагы табигый куәтнең адәм теленә, сүзгә керүе генәдер.

Исмәгыйль бәк бөек иде. Риза казыйның сүзләре дә бер гөруһ укучылар тарафыннан, шөбһәсез, авторитет булып кабул кылыналар, «Төрек угыл»ларының да моназарәләре начар түгел иде. Ләкин тарихи агым болардан да куәтле икән: идеалист күңелләрнең бөтен иҗтиһадларына каршы татарлык, үзенә аерым бер куәт булып, мәйданга чыкты. Вак елгалар аңа кушылды, киң бөек Идел туды.

---

*Гөруһ* – төркем.

*Иҗтиһадларына* – тырышлыкларына.

# «КӨНЕ КИЛЕР, БЕЗ ТӘМАМ ЭШЛӘНГӘН “МИЛЛИ ТАРИХ”КА МАЛИК БУЛЫРМЫЗ»

## *(ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШ ҺӘМ МИЛЛИ ТАРИХ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ)*

### ЯҢА ӘСӘР

<…>

6) Киләм актык мәсьәләгә. Бусы, үземчә, иң мөһиме һәм төп максудым да.

Буңа керешүдән элек укучыларның ике хәлне хәтерләренә алуларын үтенәм: берсе – бу тарихи әсәрнең мәктәп вә мәдрәсәләрдә дәрес китабы итеп шәкерт кулына бирү өчен тәэлиф кылынган булуы; икенчесе – буны язучы олуг төрек кавеменең татар атлы зур кабиләсеннән булып, бу әсәрне шул үз милләтеннән булган укучылар файдалансын өчен вөҗүдкә китерелүе.

Бу ике хәл мөәллифкә бик мөһим бер вазифа йөкли, ул да шуннан гыйбарәт: укучы шәкертләргә төреклек вә татарлыкның тарихында булган шан вә шәрәфен, аның заманы белән дөньяның иң куәтле кавеме булып, тарих агымында гаҗәеп зур эшләр кылганлыгын мөәллиф тәмам күргәзеп китәргә, укучының күңелендә шундый хис, хыялында шундый картина калдырырга тиешле.

Фатих әфәнде тарих фәненә хезмәт язмый, татар шәкертенә бер файда булсын өчен яза. Шунлыктан ул төрек вә татар кавеме хакында булган тәмсез вә кара хәбәрләрне, аларның тарихында эшләнгән каралыкларны фараз итми, никадәрле ачы хакыйкать булса да, йә бөтенләй ташларга, яки матурлап, буяп күрсәтергә,

---

*Малик – ия, хуҗа.*

*Мөәллиф* – китап язучы, китап төзүче.

*Шан вә шәрәфен* – дәрәҗәсен һәм данын.

шулай итеп, төреклек вә татарлыкка ихтыярсыз мәхәббәт үстерергә, шәкертне бу кавемнән булу илә мактанырлык, үзен ихтыярсыз шуңа күңеле белән бәйләрлек бер хәлгә куярга кирәк. Кирәк кенә түгел, бу лазем, бу – фарыздыр.

Бунда битарафлык түгел, тар миллилек илә барырга, шуны рәһбәр итәргә тиеш. Әсәр башка тугрыда никадәрле кыска булса да, төрек вә татар хакында, болар үз каныбыз булганга, мөмкин кадәрле озын, киң итмәк милли вазифадыр.

Шулай итми хәл юк, чөнки бөтен дөнья шулай. Теләсә кайсы милләтнең үз кавеме хакында язылган мәктәп дәреслекләрен кулга алыңыз, анда иң зур вә киң урын аңа бирелә, ул дөньяның иң шәп вә яхшы милләтеннән ясала. Начар ягын сөкут итеп, төймәдәй яхшылыгыны төядәй кылына. Аның әүвәлге даһилары баштанаяк кан эчендә булса да, шундый матурлап, ялганлап, чибәрләп күрсәтелә ки, дөньяда аңардан да яхшы кеше булмый. Һичбер кавем үзенең тарихы хакында чын битараф түгел, аңа аның яхшы яклары күренә, яманы яшерелә. Мәктәп өчен булган тарихларда исә иң мөһим урын аңа бирелеп, гали бер милләт иттереп чыгарыла.

Фатих әфәнденең иң зур һәм һичбер хәлдә, милли караштан, гафу ителмәскә тиешле булган мөсаһәләсе шул хактадыр.

Бу мөсаһәлә ике җәһәттән:

1. Төрек вә татар халкын мөстәкыйль бер милләт итеп бер дә телгә алынмаган диярлек дәрәҗәдә аз зикер ителүе.

Китапның беренче кыйсемендә «төрекләр» атлы бер фасыл бар. Бу барлыгы бер биттән дә кечкенә улып, бөтен китапта иң кыскасыдыр.

Бунда бик гади рәвешдә җәгърафи әхвәл бәян кылына да төрекләрнең кайчан башлап дөньяга чыгулары әйтелә. Шуның белән вәссәлам. Хәлбуки башка кавемнәрнең дин, игътикад,

---

*Рәһбәр итәргә* – күздә тотарга, күрсәтергә.

*Сөкут итеп* – төшереп калдырып (күрсәтмичә).

*Гали* – бөек.

*Мөсаһәләсе* – игътибарсызлыгы, кимчелеге.

*Фасыл* – бүлек.

*Игътикад* – ышану, инану.

әхлак вә гадәтләре, хәтта тәфсыйләте илән үк бәян кылынган. Тарих никадәрле мохтәсар булса да, төрек вә татарның хәят вә тормышын беркадәр тәфсыйл итәргә, ничек кенә булса да, аны укучының күз алдына куәтле, мөстәгыйд бер кавем иттереп куярга тиеш улып, дине, игътикады да, әхлак, гадәт вә тормышлары да беркадәр күргәзелмәле иде. Дөрест, Фатих әфәнденең мөкаддимәдә күрсәтелгән мәнбәгъларында ул хакта артык нәрсә юк, ләкин төрек вә татар хөрмәте өчен ераграк, киңрәк рәвештә мөрәҗәгать иткәндә дә зур улмас иде. Әсәрдә без Мисыр, Юнан вә Гарәп кавеменең мәдәнияткә зур хезмәт кылганлыгын, Иранның бу хакта артык зур эш кыла алмаганлыкларын күрәмез. Әмма төрек кавеме ни кылган? Төрек гонсырының гыйлем вә мәдәният юлында күргәзгән ни хезмәтләре бар? Бу хакта бернәрсә әйтелмәгән.

Бу сөальгә тышкы караштан «юк!» белән җавап бирергә мөмкин булса да, бер татар, бер төрек өчен аның хезмәтләрен санап бирергә юл юк түгел. Соңгы еллардагы бәгъзе бер әсәр, бәгъзе бер конференсалар бу мәсьәләне тикшереп, яхшы ук мөһим мәгълүмат бирде. Бер татар, үз бабасының тарихын язганда, «Анларның гыйлем вә мәдәнияткә хезмәте дип», шуларны тиз үк эләктереп алырга, Аурупада фәлән гасырда җитешкән гыйлем вә фәлсәфә әһелләреннән мәшһүрләрене санаган бәрабәренә, кыска гына булса да, иске төрекләрдәге мәдәниятне, анлардан җитешкән Олугбәк[1] вә Ибн Синаларны[2] телгә алып китәргә иде. Анлар өстенә Фөзули кеби берничә шагыйрьләрен[3] дә телгә алырга иде. Әсәрнең татар тарафыннан, татарлар өчен язылган булуы шуны тели, бу – мөәллифнең фарыз вазифаларыннандыр.

2. Татар вә төрек кавеменнән җитешеп, үзләренең куәт вә истигъдадлары илә бөтен дөньяны дәһшәткә салган даһила-

---

*Мөстәгыйд* – сәләтле, булдыклы.

*Күргәзелмәле* – күрсәтелергә тиеш.

*Мөкаддимәдә* – керештә.

*Мәнбәгъларында* – чыганакларында.

*Гонсырының* – төркеменең, токымының.

*Истигъдадлары* – сәләтләре, зирәклекләре, үткенлекләре.

рымызның гел кара, ямьсез яклары илә күргәзелүе. Мәсәлән, төрек кавеменең иске даһиларыннан булган Атилла[4], укучыга «минем атымның аягы баскан йиргә үлән үсмәскә тиеш!» диярлек мәртәбәдә булган бер мохриб сыйфаты илә күренә. Аның гел сугышып, харап кылулары сөйләнә. Соңгы бер тараф мөәррихләр тарафыннан «Наполеон[5] илә Искәндәр кәбиргә[6] сугышу җәһәте илә бәрабәр булса да, башка сыйфатлары һәм фәүкылгадә табигатьлелеге илә дөньяның һичкеменә охшамый, шул дәрәҗәдә югары!» дип танылган татар даһисы Чыңгыз хакында[7] ачык бәян «ислам мәмләкәтләренең астыны өсткә китерүче, аңарчы күрелмәгән вәхшәт, тәхриб, катиле гам иҗра кылучы» улучылыктан гыйбарәт булып калган. Мәшһүр Аксак Тимеремез[8] дә, «Урта Азияне, Төркестан вә Бакчасарайны хәрабәгә әйләндереп, дәхи дә йөз мең халыкны катил кылдыручы» итеп күрсәтелә. Болар инде – күптән, ләкин гел «гайре дустлар» тарафыннан сөйләнеп килгән хәлләрдер. Алар арасында ихтималы, дөресте дә булыр. Ләкин без аны ишеткәнчә алмаска, татар булуымыз ягыннан аны тикшерергә, дөрест булган тәкъдирдә мәктәп китапларына кертмәскә тиешлемез, бондый китап язучы кеше иң әүвәл үзенең татарлыгын хәтергә алырга, шуңа күрә тарихын татар баласына татарлыкка мәхәббәт уятырлык итеп эшләргә тиешле. Безнең ул даһиларымызда бөтен дөнья тарафыннан тасдыйк кылынган әллә ничаклы яхшы сыйфатлар да бар. Без иң элек күренә торган урынга шуларны куеп, начар якларын сөкүт итәргә, ул да мөмкин булмаса, буярга, төзәтергә тиешлемез.

---

*Мохриб* – ватучы, җимерүче, һәлак итүче.

*Бер тараф мөәррихләр* – бер төркем тарихчылар.

*Фәүкылгадә* – гадәттән тыш.

*Вәхшәт* – кыргыйлык, ерткычлык, вәхшилек.

*Тәхриб* – җимерүче, харап итүче.

*Катиле гам иҗра кылучы* – бөтен халыкны үтерүче.

*Гайре дустлар* – дус булмаучылар, дошманнар.

*Тасдыйк кылынган* – дөрес дип табылган, расланган.

Тарихи бер әсәрнең фәне тарихка хезмәт җәһәте алда тотылып язылуы илә халык вә шәкерт өчен язылуы арасында, бик күп аерма булырга тиеш, һәм башка милләтләрдә шулай языла да.

Фатих әфәнденең үз әсәрендә үк «вандализм»нан бер истәлек бар. Аның тарихын мөрәттәб укып торганда сәясәт мәйданына чыгып, беркадәр куәт алган һәркемнең «вандалистлык»ка якынаеп калганын күрәмез.

Инде һәркемгә мәгълүм үк мәсьәлә – «Көчленеке замана!» диләр. Бу сүз башка һәр йирдән бигрәк сәясәт бабында туктаусыз ригая кылына торган бер кагыйдә хөкемендә. Сугыш вә сәясәт бабында зур эш кылган кайсы гына даһины телгә алсаң да, аның аяклары адәм гәүдәсе, адәм башы өстеннән йөрегәнлеге, тәрҗемәи хәленең кан белән тулганлыгы ачык күренә. Бөтен милләтләрдә гомуми булган бу хәлдән бер безнекеләрнең генә имин булу ихтималы юктыр.

Буны һәркайчан хәтердә тотып, татарның борынгы даһиларын «изге каһарманнар» итеп, гел яхшы ягыннан сыйфатлап, мәктәп өчен булган тарихларда зур вә югары урынга утыртып куярга тиешле. Бөтен дөньяда шулай булып торганда, бер безнең моңардан качуга һичбер лөзүм юк.

Рус милләтенең тарихи каһарманнарыннан бере улган мәшһүр Иван Грозный кем?[9] Ул ниләр кылган? Ә шул затны мәктәп вә мәдрәсәләр өчен язылган рус тарихларында нинди кеше итеп күрсәтәләр? Без дә шундый хәлләрдән гыйбрәт алырга тиешлемез дип беләм.

## МИЛЛИ ТАРИХ

<…>

Безем халыкның үз тарихына мөнәсәбәтендә, чыннан да, гаҗәеп бер хәл бар: ни-нәрсәдер безне үткәнебездән аерган. Ниндидер бер хәл татарның хатирәсеннән тарихи дөньясын юып, себереп ташлаган. Башка халыкларның иң җаһилләрендә

---

*Мөрәттәб* – тәртип белән.

*Ригая кылына* – игътибар ителә.

*Җаһилләрендә* – наданнарында.

дә, һич булмаса, дин голямасы һәр эшне илаһи бер куәткә терәп, үз заманында булган вакыйгаларны яза барган; шулар сакланганнар, укыла килгәннәр. Ә халык исә, буның белән генә канәгатьләнмичә, үзенең куәтле хыялын милли тарих юлында бик нык эшләтеп, әллә ничаклы тарихи әкиятләр тудырган, булган каһарманнарны зур итеп, үзе ясап, ничек тә үткән көн хакында башында бер дөнья, бер күренеш саклап килгән.

Мәсәлән, русның иң надан, иң караңгы почмакларында да үзләренең тарихи дөньялары хакында байтак нәрсәләр беләләр, бик күп әкиятләр сөйлиләр. Үзләренә дин табып биргән олуг Владимирлар[1], газиз Ольгалар[2], әллә нинди зур куәткә ия булган Муромецлар[3], хыялый батырлар, фәләннәр бар да аларның хәтерендә һәм телендә. Алар буны китаптан күреп сөйләми, бәлки аны халыкның ничәмә гасырлык хатирәсе саклаган – ул телдән-телгә килгән.

Ничек кенә булса да, кара гавам үзенең тарихи халык икәнен, күптән яшәп килеп, заманында әллә нинди куәтләр күрсәтә алдыгын белә.

Ә бездә юк.

Безнең тарихи дөньямыз бик күп халыкларныкыннан да әллә ничә мәртәбә артык бай, киң һәм мөмтаз булса да, ни өчендер, голяманың каләме тик торган, халык хыялы да аны бер якка ташлап, кырык башлы аждаһалар белән сугышкан Гали батыр (хәзрәте Гали)[4] әкиятләренә бирелеп киткән.

Халык Батыйны[5] белми, Мамайны[6] ишеткәне дә юк, бөек йөрәк Сөембикәне[7] дә хәтерләми, хәтта бөтен дөньяның телендә һәр көн чәйнәлмәктә булган даһи Чыңгызны[8] да бик азлар, тик азлар исемен генә белә.

Шундыйлар хакында ни бер әкият булсын, ни бер мисал сөйләнсен; болар хакындагы сүзләр кара татарның бер дә йөрәгенә җитми; гавам боларга үзенеке итеп карый белми, баланың атага мөнәсәбәтенә охшаш бер якынлык тумый.

---

*Голямасы* – галимнәре.

*Мөмтаз* – башкалардан өстенрәк.

Ә иске голяма исә боларның барына берьюлы, бер дә кызганмыйча, ләгънәт кенә яудыра: алар залим, алар хунхор, алар дөньяны харап иткән, хәтта бу җүләрлек яңа матбугатта да урын алгалый, ягъни ул пычрактан, ул мәгънәсез әкияттән әле һаман зыялымын дигән татар башы да арынып җитә алмый.

II

Ләкин тарих бабындагы агым хәерлегә таба.

Тәрәккыйпәрвәр каләмнәрдән борынгы хатага карап, тарихи дөньямызга пычраклар чәчрәткәләү дәвам итсә дә, матбугат вә әфкярнең куәтле агымы хакыйкый эзгә төште инде.

Көне килер, без тәмам эшләнгән «милли тарих»ка малик булырмыз, һәм ул безнең йөземезне кызартмас, безгә үткән көннәремезне үзенең чын кыяфәтендә ак вә якты сурәттә күз алдымызга китерер.

<…>

«Милли тарих» димез. Соң ул бездә бармы? Хәзергә юк. Ләкин булачак. Аңа нигез салынган. Аның мәсьәләләре мәйданга чыгарылган. Байтак материалы да хәзерләнгән. Чит кавемнәр эчендә безем тарихымызның хадимнәре бар. Анлар эзли, тикшерә, татар оныткан мазыйны заманның томаны эченнән күз алдына чыгарырга тырыша.

Бу мөкаддәс хезмәткә кул сузучылар үз эчемездә дә, мең шөкер улсын, күренә башлады.

Берничә тарихи язма әсәрләр табылды. Төрле юллар белән, әлбәттә, бик зур мәшәкать кертеп эшләнгән байтак тарихи китаплар матбугат дөньямызны зиннәтли башладылар.

---

*Хунхор* – канэчкеч, тиран.

*Әфкярнең* – күпчелек фикеренең.

*Малик булырмыз* – ия булырбыз.

*Тарихымызның хадимнәре* – биредә: тарихыбызны өйрәнүчеләр (тарихчыларыбыз).

*Мазыйны* – үткәнне.

*Мөкаддәс* – изге.

Башлыйк заманнар тәртибе белән:

1. Мөхтәрәм Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтенең «Мөстәфадел-әхбар»ы[9].

Һәрбер әсәрне иң әүвәл алган мәүзугысының әһәмияте ягыннан; икенче, шул мәүзугъта бунының ничаклы хезмәте тия алу җәһәтеннән; өченчедән, ул әсәрнең язылган заманы – тарихи җәһәттән карап тәкъдир итәргә вә шул өч җәһәттән мөляхәзә белән кыйммәт бирергә тиешле. «Мөстәфадел-әхбар» исә бу өчнең каюсы белән генә карасаң да, бик бөек кыйммәткә җаиздыр.

Ул безгә иң әүвәл үз исемемезне бирде: «татар» дип атады. Бөтен татар дөньясында татар тарихы хакында һич нәрсә уйламаган заманда, башлап «милли тарих» сүзен кузгалтты, хезмәтенә ни мадди ярдәм күрмәдеге, ни мәгънәви тәшәккер ишетмәдеге, хәтта шуның өчен бөтен замандашлары тарафыннан сүгелдеге хәлдә, һичберенә карамый, армый-талмый, кабер ташлары эзләп йөрде.

Ул заманда моның шикелле бер әсәр чыга алуның чын әһәмиятен күрсәтү өчен, гыйбарә табып булмый. Бондый урыннарда матур язуны белдереп, иртә килүче сандугачка охшаткалыйлар.

«Мөстәфадел-әхбар» да безем милли тарихның башлангычы – аның киләчәген хәбәр бирүче бер әсәр иде. Шуның илә бергә аның бик ныклы нигезедер.

2. Рәшид казыйның «Чулпан йолдыз»лары[10].

Бу әсәрнең милли тарихка фән рәвеше белән хезмәт җәһәтләре булмаса да, заманнарында яхшы тел, куәтле инша илә язылган әсәрләрдән булып, халкымызның эчендә азмы-күпме тарихи мәгълүмат бирергә хезмәтләре тиде.

---

*Мәүзугысының* – темасының, проблемасының.

*Тәкъдир итәргә* – бәя бирергә.

*Мөляхәзә белән* – игътибар белән уйлап, фикер йөртеп.

*Каюсы* – кайсысы.

*Җаиздыр* – яраклы, туры килә торган.

*Тәшәккер ишетмәдеге* – рәхмәт ишетмәгәндә.

3. Ризаэддин бине Фәхреддин әфәнденең «Асар»ы[11].

Менә болар, чыннан да, хезмәт, күп көч кертеп язылган әсәрләр урынында нәмунә итеп күрсәтелерлек нәрсәләрдер!

Буның хәзергә чаклы унбиш җөзьә чыкты. Һәммәсе үз бабында береннән-бере мөһим. Һәммәсе – татар тарихы өчен бик вә бик кыйммәтле материаллардыр.

Менә болар китап язып, рисалә чыгарып акча алу, шөһрәт казану гына түгел, болар чын мәгънәсе белән хезмәт, хезмәт, хезмәт инде. Боларны йокы арасында башыңа кергән хыял буенча берничә көндә сызгалап ташларга мөмкин түгел. Болар өчен, боларның бер бит, бер юлы, хәтта гади бер цифры өчен бәгъзан мөәллифләренә әллә ничаклы иске, кулъязма китаплар актарырга, әллә ничаклы тузан йотарга, әллә кемнәр, әллә нинди васиталар аркылы, әллә кем муллалар хакында мәгълүмат җыярга, әллә кайдагы кабер ташларыннан язу укып йөрергә, шул һәвәстән адәм укырлык бер нәрсә чыгару өчен, әллә ничаклы баш ватарга лазем буладыр.

Боларга киткән куәтнең һичбер төрле мадди ярдәм китермәвен, әсәр язылып беткәч бастыру өчен һәрбер җөзьәләрендә, әллә ничаклы азап чигәргә туры килүен дә игътибарга алсак, «Асар»ның хадименә тагы бер мәртәбә ихтирам артырга тиеш.

<…>

Ризаэддин әфәнденең «Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре» атлы әсәреннән[12] ике җөзьә чыкты. Боларның да тарихымыз юлында әһәмиятләре шөбһәсез.

---

*Нәмунә* – үрнәк.

*Җөзьә* – кисәге, бүлеге.

*Бабында* – бүлегендә, б и р е д ә: «өлкәсендә» мәгънәсендә.

*Рисалә* – кечкенә китап.

*Бәгъзан мөәллифләренә* – кайсыбер язучыларына.

*Васиталар аркылы* – чаралар, юллар белән.

*Һәвәстән* – теләктән.

*Хадименә* – хезмәтчесенә, б и р е д ә: «язучысына, авторына» мәгънәсендә.

*Тәдбирләре* – чаралары.

4. Мәккәле Морад әфәнденең гарәби телле «Тәлфик»ы[13], Мәрхүм Гайнетдин Әхмәровның рисаләләре[14], Хәсәнгата казыйның мәшһүр тарихы[15] да шул җөмләдәндер.

Болардан иң мөһиме, әлбәттә, Хәсәнгата әфәнденекедер. Ул үзенең мөкаддимәсендә шул әсәр юлында бик күп еллар гомер сарыф кылганын сөйли. Әлбәттә, шулайдыр. Мәшһүр Бокль, дөньяда башка нәрсәләр барын онытыр дәрәҗәдә гел шуңа бирелеп кенә эшләдеке хәлдә, 21 ел гомерен сарыф итеп, үзенең «Англия мәдәнияте тарихы»н[16] да тик бер генә җөзьэ бирә алган иде.

Хәзергә Хәсәнгата әфәнденең бер җөзьэ чыкты. Милли тарихның бөтен торышы программа итеп алган беренче әсәремез булганлыгы өчендер, аны бик алкышлап каршы алдылар.

Кайберәүләр аның теленә бәхәс итә. Ләкин бу фәнни игътираз түгел. Теленең авырлыгы мәктәпкә керә алмавына, аз үтүенә сәбәп булырга мөмкин, ләкин фәнни әһәмияткә зарар бирә алмый. Хәсәнгата әфәнденең надир хезмәтенә тәшәккердән соң, аның әсәреннән байтак мөһим мәнбәгълардан мәхрүм булганлык күренеп тормакта идекен әйтми узып булмый. Төрек вә татар хакында бер русларда гына да шулчаклы материал бар ки, ул әсәрләрнең тик фиһристен генә язып чыгарга да берничә фельетон кирәк булыр иде. Боларның күбе сатылмыйлар да ук, тик дарелфөнүн-фәлән китапханәләрендә генә саклана. Мөәррих өчен, әлбәттә, бу материалга якын торырга кирәк. Хәсәнгата исә читтәрәк иде. Дәхи аның тоткан әсасы хакында игътираз бар. Ул төрекләрне төрле кабиләгә аера да һәрберен

---

*Мөкаддимәсендә* – керешендә.
*Игътираз түгел* – фикеренең дөреслеген инкяр итми.
*Аз үтүенә* – аз сатылуына, әкрен таралуына.
*Надир* – сирәк очрый торган.
*Мәнбәгълардан* – чыганаклардан.
*Фиһристен* – исемлеген.
*Фельетон* – биредә «мәкалә» мәгънәсендә.
*Мөәррих* – тарихчы галим.
*Әсасы* – нигезе, принцибы,
*Игътираз* – каршы килү, килешмәү.

үз уңаенча тикшерә башлый. Хәлбуки бөек тюркологлар һәм бу мәсьәләнең авторитетларының тәхкыйкатенә караганда, төрекләрдә борын андый мөстәкыйль кабилә булмаган, уйгур димәк, скиф, фәлән димәк, болар коры сүзләр генә, күчеп йөрүче исемнәр генә булган.

5. Һади Атласиның «Себер тарихы»[17]. Себердә «Сибирия» гәзитәсе[18] баш күтәрде. Казанда шуның белән бер көннәрдә «Себер тарихы» чыкты.

Имам Халиди әфәнденең «Тәварихы хәмсәи шәркыйә»сен[19] дә онытырга ярамый.

6. «Шура» журналында басыла килгән ханнар тәрҗемәи әхвале[20] белән, «Төрек юрды»ндагы мәкаләләр[21] дә төрек вә татар тарихы хакында мөһим бер хезмәтне үтиләр. Хосусан Йосыф Акчура әфәнденең ул журналда басылып килмәктә улган «Чыңгыз хан»ы[22] – һәр татар, һәр төрек мәшһүр тәгъбирне бөти итеп тагарга тиеш булган кыйммәтле нәрсәләрдер. Йосыф әфәнденең бу мөһим әсәре, әлбәттә, китап шәкелендә чыкса кирәк[23]. Акчура каләменнән түгелгән энҗеләр бервакытта да ятып калырга тиеш түгел.

<…>

## V

Мәкаләмне Зәки Вәлиди әфәнденең яңа гына чыккан «Татар вә төрек тарихы» мөнәсәбәте белән яза башлаган идем. Бераз урап булса да, инде аңа кайтыйк.

Тагы бер мәртәбә өмид өзмәскә мөмкин: яшь тарихчыбызның әсәре үзенең һәр бите, һәр бабы белән күп хезмәт, белеп һәм яратып кертелгән хезмәтне аңдырып тора. Әсәр бөек тюркологның, надир авторитетларның илһамы белән, надир һәм кыйммәтле, вә ышанычлы мәнбәгъләрдән алып эшләнгән. Китапның кәгазе яхшы, басмасы матур. «Милләт»нең мәйданга

*Тәхкыйкатенә* – тикшеренүләренә.

*Хосусан* – бигрәк тә, аеруча.

*Шәкелендә* – формасында.

*Аңдырып* – аңлатып, күрсәтеп.

*Надир* – сирәк.

чыгарган матбугаты арасында тәхсин итәрлек дәрәҗәдә эшләнгән бер әсәр булды.

Зәки әфәнде төрек тарихын икегә бүлә: истикъляль дәвере, мәхкүмиять дәвере. Беренче дәвер – бишектән алып Казан ханлыгы егылгангача. Икенчесе – аннан соңгы заман. Әсәрнең хәзергә шул беренче дәвергә гаид бер генә җөзьә чыккан.

Бик хаклы уларак, борынгы төрек язуларыннан, иске тарихи хәрефләребездән [...]* харита да кушылган. Бездә тарихи харитадан бер бармактай нәрсә дә юк иде. Аны кертеп бик яхшы иткәннәр. Һәм харитага алынган җир дә бик муаффәкыять белән сайланган. Ул төрек-татар тарихының иң якты сәхифәсен, борынгы шәүкәтенең иң бөек дәверен күрсәтеп тора. Иштә, әсәрнең тышкы күренеше, бөтен торышы шундый тәэсир бирә.

Зәки Вәлиди әфәнденең тарихын бик ваклап, бик тәфсилләп тикшереп чыгу арзуым иде. Ләкин булмады; бик гомуми булган бер-ике сүз белән кичәргә мәҗбүрмен.

1) Бу әсәр, – төрек вә татарның туган көненнән башлап, безем истикъбаль дәверләремезне гомуми, ләкин кыска рәвештә сөйләп чыккан бердәнбер татарча китаптыр. Гомуми агымга ияреп, монда да ханнар һәм сарай интригалары байтак урын алган исә дә, төрек халкының иманы, әхлагы, җан тормышы, имтиязлары, әдәбияты, мәдәнияте, төрле дәвердәге хәятлары хакында да күп кенә сүзләр бар. Ләкин җитәрлек дип булмый.

---

*Тәхсин итәрлек* – мактап искә алырлык.

*Истикъляль дәвере* – бәйсезлек дәвере.

*Мәхкүмиять дәвере* – икенче бер дәүләтнең хөкеме (хакимияте) астындагы дәвер.

*Гаид* – караган, бәйле.

* Бу урында текстта бер юл киселгән.

*Харита* – карта (географик һ.б)

*Муаффәкыять* белән – уңышлы.

*Шәүкәтенең* – көченең, куәтенең.

*Арзуым* – теләгем, омтылышым.

*Истикъбаль* – киләчәк.

*Имтиязлары* – өстенлекләре.

Тирән диңгез хәлендә булган бу олуг мәсьәлә киләчәк мөәррихләремез өчен бик вә бик зур хезмәт калдырган.

2) Зәки әфәнденең теле мактаулы түгел. Иншасы да начарга якын. Бу җәһәттән ул бик күп эшләргә, каләмен, ифадәсен ачык вә табигый хәлгә төшерер өчен байтак иҗтиһад сарыф итәргә тиешле.

Тарихи китапларда асыл кыйммәт мөндәриҗатта исә дә, теле дә аңа бер зиннәттер. Шуңа күрә бу якны да игътибарга алмалы.

3) Аннан да мөһиме: телендә генә түгел, тәртибендә, әсәргә җан бирүдә дә мөәллифнең байтак йомшаклыгы бар. Ул хисапсыз күп материалны җыя, ләкин шуны табигый тәртипкә салып, җилемләп, тәмам җанландырып бирә алмый.

Күңел теле ки, бу дәрәҗәдә мул мөндәриҗат, шундый булып тезелсен иде, укучы, үзенең күз алдында китап барын онытып, вакыйгалар җанланып үткәне кебек бер хәл тойсын, төрек кавеменең тарих агымы аның хәтерендә һич мәшәкатьсез үк ачык булып калсын иде.

4) Бу әсәрдәге төрек вә татар тарихы хакында тирән тәхкыйкат вә назик тәхкыйкат, әлбәттә, эзләп булмый. Ул буңа керешми дә. Аның бар әмәле – төрле заманда, дөньяның төрле тарафларында җитешеп, безем тарихымыз юлында хезмәт кылган олуг галимнәрнең төрле җирдә, әллә нинди тарау һәм таркау бер хәлдә булган хезмәтләреннән файдаланып, шуларда булган материалны бер җиргә җыю, тәртипкә кую вә шуны татар укучысына тәкъдим итүдер. Һәм мөәллиф бу юлда вакытын да аямаган, хезмәтен дә кызганмаган. Китапның һәр бите күрсәтә ки, ул төрек вә татар тарихына азмы-күпме интисабы

---

*Ифадәсен* – аңлатып бирүен, аңлаешлы итүен.

*Иҗтиһад* – тырышлык.

*Мөндәриҗатта* – эчтәлектә.

*Мөәллифнең* – китап язучының.

*Тирән тәхкыйкат вә назик тәхкыйкат* – борыннан ук килгәнлеген һәм тулылыгын, дөреслеген раслый торган нечкәләп өйрәнелгән хакыйкатьләрне.

булган галимнәрдән берен дә коткармаган. Төрек, гарәп, фарсы әсәре өстенә, кытай мөәррихләреннән да файдаланган, инглизләр дә калмаган. Һәр җирдә игътимад илә каралган франсәле Леон Каһуннар[24] да мөһим урын алган. Олуг энциклопедияләр, тарихи журналлар да мөсаһәлә ителмәгән. Бу мәсьәләгә даир могтәбәр рус галимнәренең кыймматдар таснифәтеннән хави булган сансыз җилдле дарелфөнүн нәшрияты да бик җентекләп тикшерелгән. Шуларның барыннан килеп чыккан «Төрек вә татар тарихы».

Бу әсәр халкымызга тарихи мәгълүмат биргән өстенә тарихчыларымызны бик күп мөнбәгълар, надир әсәрләр белән дә таныштыра. Һәрхәлдә, дикъкать итәрлек, игътибарга алырлык булып, әһле тарафында җитди рәвештә тикшерелергә чыннан мөстәхикътыр. Милли тарихны фәнни бер мәсьәлә итеп кузгалтуның вакыты бик җиткән иде.

## РУС, ТӨРЕК ВӘ ТАТАР ТАРИХЫННАН

*(Романовлар ханәданының[10] 300 еллык шәүкәте мөнәсәбәте белән Киев шәһәреннән)*

<…>

Адәм туа, үсә, егетләнә, яши һәм картая.

---

*Интисабы булган* – мөнәсәбәте, бәйләнеше булган.

*Коткармаган* – биредә: «игътибарыннан читтә калдырмаган» мәгънәсендә.

*Мөәррихләреннән* – биредә: «тарихчыларының хезмәтләреннән» мәгънәсендә.

*Игътимад илә* – таянып, ышаныч белән.

*Мөсаһәлә ителмәгән* – игътибарсыз калмаган.

*Даир* – бәйләнешле, караган.

*Кыймматдар таснифәтеннән хави булган* – кадерле бүлекләрен эченә алган.

*Сансыз җилдле дарелфөнүн нәшрияты* – күп томлы университет басмалары.

*Мөстәхикътыр* – лаеклыдыр, хаклыдыр.

*Ханәданының* – династиясенең.

Милләтләр дә шуның кебек үк дәверләр кичерәләр. Һичбер милләт мәңге яшәми. Тарих бервакыт дөньяны кулларында уйнатып та соңра телләрдә исеме генә калган милләтләр белән тулы. Ләкин, ләкин төрек, татар халкының гомере, яшәеше, язмышның аңа мөнәсәбәтендә артык тиз үзгәрүчән булуы искиткеч бер хәлдәдер.

Бату тарафыннан хәрабәгә әйләндерелгән карт Киев[1] бүген үзенең гомерен үз мәдәнияте белән гөрләп яши… Шул ук даһи тарафыннан үзенә пайтәхет итеп төзелгән Сарайның бүген, Хода хакы өчен, урынында, ичмаса, бер ташы да калмаган…[2]

Бу тиз үзгәрү бер Бату эшләрендә, бер Киевта, бер Сарайда гына түгел, бу – бөтен төрек вә татарга гам булган бер фаҗигадер.

Бу хакта төрекләр белән рус арасында җир белән күк арасыдай аерма бар. Рус һичбер вакыт дөньяның астыны өсткә китерерлек куәт күрсәтмәде. Ул һәммә эшендә авыр, акрын кузгала, ләкин туганыннан бирле һаман үсә, зурая, ныгый…

Әмма төрек тарихы баштанаяк бер-бер артлы тезелгән куәтле ташкыннардан, мөдһиш туфаннардан, вулканнардан гыйбарәт.

Тарихта бәни адәмнең башыннан кичкән иң куркыныч яки иң мөһим вә иң мөмтаз вә мөстәсна вакыйгалар төрек вә татар куәтеннән туа килде. Ләкин боларның һичбере бер-беренә сәбәп вә нәтиҗә рәвешендә ялганмадылар… Һәммәсе аерым, өзек, диңгез дулкыннары рәвешендә нигезсезләр иде…

Һәммәсе, күктә яшьнәп, адәмнәрнең котын очырып, тиз үк юк булган яшен шикелле, кыска гомерле булдылар. Бәлки, монда яшәгәнгәдер, Киев, Бату хан, аның артыннан бүген урынында бер ташы да калмаган Сарай исемә килә; соңра иске пайтәхетләрдән Каракорым[3] Шәһри Болгар[4] күз алдыннан үтә дә, күңелдән

---

*Гам* – уртак.

*Мөдһиш* – куркыныч.

*Бәни адәмнең* – адәм баласының.

*Мөмтаз вә мөстәсна* – кайсыдыр ягы белән башкалардан өстенрәк булган, аерылып торган.

ихтыярсыз «Илаһым, ник соң татар вә төрек углының бәйрәмнәре бу дәрәҗәдә кыска була икән?» дигән сөальләр кичә.

Хакыйкатән, шашылачак мәсьәлә. Шулчаклы куәтләр. Шу дәрәҗәдә каһарманлыклар… Ә ни дәрәҗәдә аз гомерләр. Әле күптәнме госманлы төреге Европага дәһшәт бирә иде[5]. Әле күптәнме Анатулы гаскәре Вена капкасында иде...[6] Шуннан күпме генә вакыт үтте дә, кичәге көтүчеләре бүген актык төрек тәхетен сөрмәк әмәл кабихенә төштеләр[7].

Бу бер госманлыларда гына түгел, бөтен тарихыбызда шулай. Күргән куәтләрнең яшен рәвешендә ялтырап та тиздән югалуы, бөтен төрек вә татар тарихы буена һәр җирдә, һәр адымда үзенең хөкемене йөртеп килгән бер хәлдер.

Шул хәл белән бәйләнгән дәхи берничә сыйфат безне рус халкының тәмам киресенә куя. Болар безнең милли хәятымызның язмышында ничаклы авыр нәтиҗәләр тудырса, русның хәзерге шәүкәтенә шул дәрәҗәдә ярдәм иттеләр, итәләр һәм итәчәкләр.

Хәят һәвәсенең куәтле булуы, бер яктан, зур файдалы вә кыйммәтле бер хасыйләт улмак илә бәрабәр, милли намусны үз мәнфәгате юлында корбан иттәрерлек мәртәбә җитсә, кавимият өчен бу иң бөек афәтләрнең берен тәшкил итәдер.

Татар бәйрәмнәренең кыскалыгында, безнең тарихи бәхетсезлегемездә шул югарыгы сыйфат бик зур роль уйнап китте. Моңа тарихымызның һәр адымында очрашабыз.

Тарихе рус өчен руслык шу дәрәҗәдә мөкаддәс ки, дөньяның һичбер мәнфәгате өчен ул аны корбан итмәячәк. Ул – аның табигый зарурияятләреннән бере; ул аны хәтереннән чыгара алмый һәм аның юлында һәрнәрсәсен фида кылырга, һәрбер газабын күтәрергә әзер. Мәскәү, Киев хәяты, Бату, Наполеон,

---

*Төрек тәхетен сөрмәк әмәл кабихенә төштеләр* – Төркия дәүләтен юкка чыгару теләге белән яман эшкә керештеләр.

*Хәят һәвәсенең* – яшәү теләгенең.

*Кавимият* – милләтчелек, патриотизм.

*Мөкаддәс* – изге, хөрмәтле.

*Зарурияятләреннән* – үтә кирәкле, мөһим булган халәттән.

*Фида кылырга* – корбан итәргә.

Сигизмунд көннәре моңа җанлы шаһид була алырлар[8]. Гомумән, тарих русның руслык намусы исеменә каршы киттеген, дошман ягына чыгып, руслыкка каршы кылыч күтәргәнен белми.

Әмма татар алай булмады. Аның «үзем»е, аның хәяттагы бер мәнфәгате һәрвакыт һәр җирдә татарлык намусы дигән тойгыны җиңә килде. Татар шаһзадәләренең, юк кына интригалар тәэсире белән хилаф якка чыгып, үз милләттәшенә каршы кылыч күтәрүе[9] һәрвакыт рус гаскәре эчендә татарга каршы күкрәк киереп сугышучы татар угылларының булуы, дәхи хәятлары өчен рус дөньясын татар фамилиясе илә тутыручы бәк вә морзаларымызның[10] хисапсыз күп икәнлеге кемгә мәгълүм түгелдер? Гәрәй ханның рус хәтере өчен Сарай хөкүмәтен астын өскә китерүен[11], Касыйм татарларының әүвәлге хәрәкәтләре[12]. Һәрвакыт татар бәхетсезлеге өстенә тәхет кора килгән Шаһгалинең кылганнары[13] кемнең күз алдында түгел?

Без үз кулымыз белән газиз Сөембикәне Мәскәүгә рәһенгә бирдек[14]. Иң гаҗәбе – аның милли намусы шуңа түзде, иң намуслылардан санадыгымыз шул бөек йөрәк тә милли намус юлында хәятка фида итеп нәмунә бирә белмәде. Хәят һәвәсе аны Мәскәүгә китеп булса да яшәү, әлбәттә, «яшәү – үзе яшәү» дигән бер вак эшне күтәртте.

Рус халкы шундый бер эшне кылганчы мең мәртәбә җан бирер иде. Ул эшнең булуы кайда, хәтта рус рухын белгән адәмнәргә газиз царица*ларын басурманга бирү… дигән сүз үк ничектер бөтенләй рус теленә ятмый, якын килми…

Сөекле царицаны басурманга бирү бу мөмкинме?! Һич юк! Әмма без Сөембикәне бирдек, ул үзе дә, милли намус белән хәят арасында каюсын сайлау хакы бирелгәндә, соңгысын өскә тотачагын күрсәтте.

---

*Хилаф якка* – каршы якка.

*Рәһенгә* – тотык итеп.

*Нәмунә* – үрнәк.

* Бу сүз кириллицада басылган.

Милли намусның башка бер мәнфәгать вә максат алдында җиңелүе дип тәгъбир итдегем бу хосусият – безем табигатемезнең, безем психологиямезнең кавимият ноктасыннан карагандa иң кара, иң зарарлы бер сыйфатыдыр. Тарихи эшләремездә күптәннән бу хосусият үзенең тәэсирен йөртә килде. Гомумән, без[дә] сатлыкҗаннарга байлык зур…

Шәхсиятнең тарихта нинди роль уйнавы кебек, күп чәйнәлеп тә, һаман өзелә алмаган иске мәсьәләгә кереп китәргә кирәк тапмыйм, бу аның урыны да түгел. Ләкин тарихта бик еш очраша килгән рус белән төрек-татар кавеменең язмышларында шул мәсьәләне искә төшерәчәк хосусиятләр бар. Бу һәм русның бәхетенә хезмәт итә килгән куәтләрнең, бигрәк тә татар бәйрәмнәренең кыскалыгына сәбәп булган хәлләрнең береннән, бәлки, беренчеләреннәндер. Русия, рус дәүләте дә, рус шәүкәте дә – үзенең хәзерге бөек мәртәбәсен алуда аерым шәхесләрдән бигрәк, рус халкының рухына, халыкның руслык куәтенә бурычлыдыр. Әмма безем бөтен тарихыбыз, бигрәк тә тарихыбызның шәүкәтле минутлары, гомумән, беренче куәтнең аерым шәхсиятләремездә була килгәнен күрсәтәләр. Безнең тарихыбызда халык куәте, халык рухы дигән мәфһүм үк юк. Халыкның материал булып хезмәт итүен инкяр сукырлык булыр. Ләкин халык үз тарихын үзе башлап йөртмәде. Безнең һәммә дәүләт инкыйлабларымызда баш кузгатучы гына түгел, язмышны йә ул, йә бу якка боручылар, халык рухы түгел, бәлки шәхесләр.

Чыга Атилла[15]… Дулкынлана халык… Ясала гаскәр… Менә сезгә кешелек тарихында яңа дәверләр… Зур инкыйлаблар… Менә кузгала Чыңгыз[16], ниһаясез куәте белән ул чи материалдан бер халык ясый да дәүләт кора, дөньяны биетә, бөек императорлык тудыра… Менә Батулар[17]… Менә Тимерлан[18]… Мамайлар[19]…

---

*Тәгъбир итдегем бу хосусият* – алда әйтеп үткән бу үзенчәлек.

*Шәхсиятнең* – шәхсилекнең.

*Мәфһүм* – төшенчә.

*Инкяр* – кире кагу, танымау.

*Инкыйлабларымызда* – түнтәрелешләребездә.

Яңа заманга киленсә, менә Төркия хәлләре, анда бер Мидхәт паша[20] ялгыз башына бөтен бер мәмләкәткә мәшрутиять тудыра… Ләкин яңлыш атлаган бер адым эшне харап итеп, куәт явыз кулга эләгә дә мәшрутиять үзенең атасы белән бергә гүргә керә… Шуннан мәмләкәт утыз еллар богавында ыңгыраша.

Татар дөньясында шундый бер минут булса, утыз көн эчендә утыз җирдә утыз адәм үзен хан игълан кылыр да, утыз мәртәбә сугышып, кан вә үлем белән дөньяны тутырган булыр. Безнең тарихыбыз дөньяның артык мөстәсна даһилардан булган шәхсиятләргә бай. Шулар, әлбәттә, әхвәлнең, заманның мөсагадәсе белән тарихта куәтле ташкынлы, бөек туфаннар... Мөһим инкыйлаблар… Зур дәүләтләр вөҗүдкә китерделәр… Ләкин һәммәсе кыска гомерле булды. Һәммә бәйрәмнәр күз ачып күз йомганчы үтеп китте.

Угыз ханнар[21], Атиллалар, Чыңгыз, Бату, Тимер, Мамайлар, Госманнар[22], Мидхәтләр… Һәрбере яңа мөшкиллек белән дөньяга килде… Халык язмышы шундый куәтләр уңгаеннан, ахры… Шуңа күрә сәяси бәхәсләр, туктаусыз дулкынланып, алмашынып, гел җил тәэсиренә калды… Алтын Урдада бер көн ничә хан алмаштырган тәхетләр, Казанда аз бер заманда халык яратмаган Шаһгалинең өч мәртәбә ханлыкка менүләре...[23] Бүгенге төрекнең һәр ел ун мәртәбә кабинет алмаштырулары...[24] Болар – бар да төрек-татар агымнарының халык тормышы, халык рухы төбеннән кайнап чыкмавын, бәлки диңгез өстендәге күбек кебек иттифакый җилләрнең куәте илә хасыйлә килгәнен сөйләп тормакта булган шаһидләрдер.

Һәм безнең трагедияләремезнең бере, бәлки, беренчесе шулар да… Безем бәйрәмнәремезнең кыскалыгы, без бүген

---

*Мәшрутиять* – конституцион монархия.
*Мөстәсна* – башкалардан аерылып торган.
*Мөсагадәсе* – мөмкинлек бирүе.
*Вөҗүдә* – барлыкка.
*Мөшкиллек* – авырлык, кыенлык.
*Иттифакый* – очраклы.
*Хасыйлә килгәнен* – хасил булуын, барлыкка килүен.

дөньяга дәһшәт бирәчәк куәтләр, шәһәрләр белән уйнап та, иртәгә үз пайтәхетләремезнең җимерелә башлавы, бераз заман үтмичә, алар урынында бер данә таш та калмаслык мәртәбәдә юкка чыккан Каракорым, Сарай, Шәһре Болгар хәлләре вөҗүдкә килүе, шул трагедиядән мөтәәссир идекендә шөбһә юктыр.

Төрек вә татар эшне эш булсын өчен түгел, бәлки үзенең куәте күренсен өчен эшли. Без һәммәбез «Булса, мин дигәнчә булсын, булмый икән кадалып китсен» дияргә хәзермез. Тарихе рус белән татарның эгоизмын үлчәгәндә, безнеке исә искиткеч мәртәбәдә артык булачак.

Безнең туктаусыз дулкыннан гыйбарәт булган иске тарихымызда бер-береннән куәтле вә мөмтаз булган бөек даһиларымызның куәте, шәхси кәмаләтләре балкыса, рус тарихы баштанаяк халык җанының хәрәкәте, халык күңеленең үзе башлап, руслык вә христианлык өчен кайгырдыгы күренәдер. Рус тарихында аның бөек шәхесләре эшләмәде, һәрнәрсәдә халыкның үз куәте, үз теләге белән йөрде дисәк, хакыйкатьтән ерак киткән булырбыз. Юк, шәхсиятләрнең тәэсиреннән башка тарих булырга мөмкин түгел. Ләкин тарихи вакыйгаларга сәбәп булган куәт, халыкның үз йөрәгендә торып, шуның тәэсире белән, бөек шәхесләр мәйданга атылуы белән, мөнади даһилар чыгып та, шулар үзләре халык ясау, халыкка кузгалыш бирү арасында зур аерма бар.

Төрек-татар тарихы – соңгы эздән, рус исә беренчедән акты. Бу хәл рус дәүләтенең беренче нигез ташлары хакындагы әкиятләренә чаклы тәэсир иткән.

Алар үзара бер падишаһ эзли. Безем татарда шундый бер хәл булса, арадан бере чыгар да, кан вә ут дәрьялары ачып, үзенә тәхет корыр яки уртада бетмәс-төкәнмәс анархия башланыр иде. Безем татар табигатендә бондый эш ике мөхальнең бередер.

---

*Мөтәәссир идекендә* – йогынтысы, тәэсире булуында.

*Мөмтаз* – өстенрәк.

*Кәмаләтләре* – өстенлекләре, булдыклылыклары.

*Мөнади* – чакыручы, өндәүче.

*Мөхальнең* – мөмкин булмаган, абсурд эшнең.

Бервакыт рус халкы үзенең нәселдән нәселгә агып килгән хөкемдарлыктан туя, ризасызлана. Тәхет буш. Аңа падишаһ кирәк. Уртада без Рюрих нәселеннән мөстәхикъ дигән әллә ничаклы карт кенәзләр бар. Ләкин халык алардан хәер көтми, шуңа күрә үзе ышанган берсенә – Годуновка ялына башлый[25]. Ул кабул итми… Тәмам утыз кат ялваралар, ниһаять, халык дигән эш вөҗүдкә килә.

Әмма авыр, акрын рус халкы, андый шәхес уйларына бик тиз бирелә алмый. Дөрест, аның садә вә йомшаклыгыннан файдаланучылар булгалый иде. Ләкин ул вакытлы була, халык айный да тагы үзенең Русиясе, руслыгы хөрмәтенә ни-нәрсә файдалы булса, шул эзгә төшә иде.

Гомумән, рус руслыгына нык ышана; халык көче аңарда авыр көннәрдән, күп газаплардан соңында үзен күрсәтә ала… Еракка бармыйча, тик Наполеон һөҗүменә каршы Русиянең тоткан хәрәкәтен генә хәтергә алу бу халыкның зурлары, каһарманнары түгел, бәлки шул чабаталы гавамы ничаклы эш кыла алачагын ачык күрсәтәдер[26].

Милләт рухы вә милләт табигатенең көзгесе булган әдәбиятка күз салсак, рус кавемендә халык, халык куәте дигән мәфһүмнең ни дәрәҗәдә тирән тамыр җәйгәнлеген, халыкчылык боларның канына сеңгәнлеген ачык күрәчәкмез. Башка һичбер милләттә булмаган дәрәҗәдә бай икәнлеге әһле тарафыннан тасдыйк кылынган рус халык әдәбияты, шуның иң караңгы җирләрендә телдән-телгә җырланып, сөйләнеп килгән җыр вә әкиятләре, гомумән, шул руслык, христианлык юлында кайгы-хәсрәт көйләреннән яки милли каһарманнар хакындагы кыйсса вә дастаннардан гыйбарәт ки, бу кара гавамның үзе дә

---

*Мөстәхикъ* – хаклы, лаеклы.

*Вөҗүдкә килә* – барлыкка килә.

*Мәфһүмнең* – төшенчәнең.

*Әһле тарафыннан тасдыйк кылынган* – халкы тарафыннан расланган.

*Гавамның* – халыкның.

руслык наменә ни дәрәҗәдә якынлык тойганына шәһадәт бирмәктәдер.

Әдәбияты нәфисәгә киленсә, аңардан да баштанаяк руслык, рус рухы, рус өчен кайгыру, рус куәтенә таяну һәм эшне халыкның үзеннән көтү аңкып тора…

Дөньяда сәнгатьлелеге вә нәфасәте илә руснықын әллә кая калдырган әдәбиятлар күп улдыгы хәлдә халыкка якынлыгы, тик халык өчен яшәү, халык йөрәгеннән туып, аның авыр хәятына бер нур, бер җиңеллек бирүне үзенә вазифа итеп алган булуы белән рус әдәбиятының бөтен дөньяда мөмтаз вә мөстәсна урын тотканлыгы мәйдандадыр.

Рус әдәбиятыннан үз кайгысына бер җиңеллек көтә. Шуңа күрә дә хәзер башка халыкларда бик киң урын тоткан «сәнгать өчен сәнгать» мәсләген рус моңарчы аңлый алмады, әле дә аңламый һәм аңламас та, чөнки ул аңа табигате белән үк сәлях түгел.

Аның һәр әдибе иң элек үзен халыкның угылы итеп хис кыла. «Язу» дигән сүздән рус хәятының авыр елларына «шифа эзләү» дигән мәгънәне аңлый… Икенче төрле әйткәндә, тарих агымында булган кебек, әдәбиятында да, сәнгатендә дә рус һәрнәрсәдән элек рус була, рус халкының рухы, куәте монда да һәммә нәрсәдән өстен йөри. Шуның газабы өчен кайгырыла. Тагы килеп шуңа ук таяна, шуңардан зур эш көтә… Рус әдәбиятында мөһим урын тоткан мәшһүр халыкчыларны безем төрек-татар төшендә дә күргәне улмадыгы кебек, моңарчы бөтен төрек вә татар дөньясында халык куәтенә бер мәгънә биргән, шуңа ышану вә таяну мөмкинлеген хис кылган бер әдип вә бер адәмне без күрә дә, ишетә дә алмадык…

---

*Наменә* – исеменә.

*Тойганына шәһадәт бирмәктәдер* – тойганын күрсәтеп тора.

*Әдәбияты нәфисәгә* – матур әдәбиятка.

*Нәфасәте* – гүзәллеге.

*Мөмтаз вә мөстәсна* – башкаларга караганда өстенрәк булуы һәм башкалардан аерым.

*Сәлях түгел* – яраклы түгел.

Русның иң югары сәнгатькяре, бөтен дөньяда мөһим урын тоткан әдип вә мөтәфәккирләре исә шул чабаталы рус мужигын галәмнең өстенә мендерәләр, шул кара халыкта гыйлемнән, мәдәнияттән вә башка нәрсәдән артык куәт вә ышаныч күрәләр иде. Достоевскийның бу хактагы мәшһүр мәсьәләсе, аның һәммә хәзинә халыкта, халык табигатендә дигән нәзариясе[27], халык дигәнне аңларга өйрәнмәгән безем кеби бер кавемгә бик гыйбрәтле дәрес була белер. Глеб Успенскийлар[28], соңгы Горькийлар[29] бер якта калсын да, Толстойның бөтен гомере буенча шул халыкка ышануы, шул чабаталы мужик йөрәгеннән хәзинә эзләве, дөньяның бөтен философлары заманның ничә мең еллык гыйлем вә фәне бирә алмаган хәкаикъны рус гавамының йөрәгеннән, чабаталы мужикның игътикад вә хиссиятеннән алдым дигән мәшһүр игътирафы…[30] Бу инде, белмим, руста халыкчылык, халык рухына мәгънә бирү, аңа ышану вә таяну һәм аңардан зур куәт көтү хакында артык бер сүз әйтергә урын калдырамы икән?..

Рус ниләр күрмәде… Аның күкрәгеннән кемнәрнең туп вә мылтыгы үтмәде, аның йөрәгенә кемнәрнең кылычлары эз салмады… Аны Сигизмунд телгәләде… Аңа Наполеон үзенең авыр коралын кадады… Аны Бату яралады…

Ләкин ул – бәхетле кавем, имеш ки, шул кыйммәтле хосусиятләр белән яратылган табигате белән; яратылган табигате аңа тарихның шу җәһәннәменнән башы исән калып чыгарга ярдәм бирде, ниһаять ул, үзенең истикъляляен дә кайтарып, хәятының бөек тавына атлый, анда җан көтә, үткән шәүкәтләренә бәйрәмнәр ясый башлады… Төрек… Рус… Бу ике халык тарих буена туктаусыз очраша килә.

---

*Мөтәфәккирләре* – фикер ияләре.

*Хәкаикъны* – хакыйкатьне.

*Игътикад вә хиссиятеннән* – инануы һәм сизүеннән, тойгыларыннан.

*Игътирафы* – белдерүе, биредә: «сүзе» мәгънәсендә.

*Истикъляляен* – бәйсезлеген, мөстәкыйльлеген.

*Җан көтә* – яши.

## «ГАНИ БАЙ» КИТАБЫ[1]
*(Тәхрир итүчесе – Борһан Шәрәф[2])*

Мөстәшрикъләр тәгъбиренчә, Волга хәвазасында «яңа туып килә торган» бер милләт бар[3]. Русия харитасында аның тоткан урыны, Русиянең хәят игътидаэсенә аның азмы-күпме күрсәткән тәэсире мәгълүм. Бу җәһәттән ул үзен күрше, ватандаш, хаким вә мәхкүм мәмләкәтләрнең һәммәсене тасдыйк иттергән ...

«Яңа туып килә торган» мәгънәсе белән булса да, ул милләтнең мәгънәвияте бар. Ул хәяты икътисадия вә маддиясендә күрсәткән хәрәкәтене, мәгънәви, гыйльми, рухи хәятында да күрсәтә: аның егерме биш яшендә генә булса да, мәктәбе, әдәбияты, ун яшендә генә булса да, театры, әфкяре гомумия тудырырга бик ныклап хезмәт итә торган матбугаты бар[4].

Ул туган җирендә үсеп чыккан. Мазыйсыз-нисез тәшкил итәргә теләгән, көчләп «милләт» булырга, мәдәни милләтләр арасына катышырга, алар силсиләсенә тезелергә маташкан бер милләт түгел. Аның мазыйсы бар, тарихы бар. Тарихның башка күп милләтләре кебек, ул да үзенең мәүкыйг җәгърафисе,

---

*Тәхрир итүчесе* – язучысы, төзүчесе.

*Мөстәшрикъләр тәгъбиренчә* – шәркыятьчеләр аңлатуынча.

*Волга хәвазасында* – Идел елгасы бассейнында.

*Хәят игътидаэсенә* – яшәешенә дошманлык күрсәтүе, золымлык итүе.

*Хаким вә мәхкүм* – хуҗа һәм [берәүнең] хөкеме астындагы (буйсындырылган).

*Тасдыйк иттергән* – таныткан.

*Мәгънәвияте* – рухи халәте.

*Хәяты икътисадия вә маддиясендә* – икътисади һәм мадди тормышында.

*Әфкяре гомумия* – җәмәгатьчелек фикере.

*Мазыйсыз-нисез тәшкил итәргә* – үткәннәрне исәпкә алмыйча гына оешырга, формалашырга.

*Силсиләсенә* – чылбырына.

*Мазыйсы* – үткәне (тарихы).

*Мәүкыйг җәгърафисе* – географик урыны.

мохите, тәшкилят димагыясе яратылып тудырылган тормыш белән коруне уляны яшәде, коруне вөстаны кичерде.

Искәндәр кәбир[5] гарәп милләтләрен, гарби кәвемнәрне шәрык милләтләренә, шәркый кавемнәргә алып барып аралаштырган, аларны бер-беренә мәдәният бирештергән, кан аралаштырткан кебек бу милләтнең Атиллалары[6], Чыңгызлары[7], Батыйлары[8] да, шәркый кавемнәрне, гарби кавемнәргә аралаштырган, аларны бер-береренә таныштырган, аларны бер-берләренә кан аралаштырткан...

Атиллалар, Батыйлар, Рейн, Дунә елгаларны кичеп, кулларын күзләренә салып, җәнүб вә гаребкә таба, озакларга карадылар: җәнүб вә гареб диңгезләренә килеп җиткәнлекләрен күрделәр, татарлыкның мәүкыйг җәгърафи вә истиляи әразый ноктаи нәзарыннан гая, амаленә ирешкәнлегенә канәгать хасыйл иттеләр.

Заманнар алмашынды. Гареб вә җәнүбкә килеп, башка кавемнәр белән уралып алынган, алар белән кода-кодагый булган төрек-татар балаларына аттан төшәргә, йорт корышырга, җирне сукалап тырмаларга, авыл булып утырырга, алыш-биреш итәргә, каләм-кәгазь тотарга «абыз»ның алдына тезләнеп, сабак укырга, мәсҗедкә барып, бер Тәңрегә юнәлергә вакыт җитте...

Ат өстеннән төшеп, «абыз»ның алдына тезләнү!..

Ә!.. Менә бу бер кавемнең бер милләтнең хәятында бик зур бер алмашыну!..

---

*Тәшкилят димагыясе яратылып* – үзаңы барлыкка килеп.

*Коруне уляны* – Борынгы гасырларны.

*Коруне вөстаны* – Урта гасырларны.

*Гарби кавемнәрне* – Көнбатыш халыкларын.

*Җәнүб* – көньяк.

*Озакларга* – еракларга.

*Истиляи әразый ноктаи нәзарыннан гая, амаленә ирешкәнлегенә* – җирләрне басып алу карашыннан теләкләренә, куелган максатларына ирешкәнлегенә.

*Абыз* – белемле, б и р е д ә: «укытучы, мөгаллим» мәгънәсендә.

Бу алмашыну дәверен уйлаганда, минем күз алдым караңгылана… төкләрем үрнәреп китә!..

Хәзерлексез, мискин татар хәят мәйданында бу юл инде бөтенләй икенче төрле ярышка чыга; ул бу юлы җир өстендә торырга теләп-теләмәү, аның моңа сәляхияте булып-булмау мәсьәләсендә сынала.

Кылыч тотып кәкрәйгән, каткан бармакларга каләм-кәгазь тотып язу бик үк җиңел булмаячагы кебек, табигатьнең киң болыннарында ат ашату, катык ашап киерелеп яткан татарга сука тотып җир актару да күңелле булмаячак. Иге-чиге булмаган сахраларда киң сулыш алып яшәргә өйрәнгән, Алтайның итәкләрендә хәйләсез гомер кичерергә алышкан татарга[9] шаушулы шәһәрдә яшәп, хәйләле кәсеп белән маташу күңел тарландыручы, баш әйләндерүче бер хәят булачагы мәгълүм.

Хәзер инде күршеләрнең муенына корык салып, тартып, аттан төшереп булмый, алар белән узышырга гакыл вә аң белән эш йөртеп, чиктән тыш фагыйлиять сарыф итәргә, күп кысынкылыкларга түзәргә туры килә…

Урманда ботактан ботакка очып кунып, иркендә сайрап йөри торган бер кошны читлеккә ябып куйганда, бичара кошның хәле ничек булса, бәдәви хәлдән мәдәни хәлгә күчү дә татар өчен шулай иде.

Бу – татар өчен мәдәни тормышта беренче баскыч.

Бу дәвердә, бик кечкенә бер мәхәллә мәсҗеде салып, аның янына шулай ук кечкенә мәктәп торгызган һиммәтле, диянәтле,

---

*Үрнәреп китә* – үрә тора.

*Сәляхияте* – сәләте, осталыгы.

*Корык* – озынча элмәкле бау бәйләнгән озын колга (көтүдәге берәр хайванны тотып алу өчен файдаланыла, элекке заманнарда сугышта да кулланылган).

*Фагыйлиять сарыф итәргә* – көч куярга, эшчәнлек күрсәтергә.

*Бәдәви хәлдән* – күчмә тормыштан.

*Һиммәтле* – энергияле, тырыш, сәләтле.

*Диянәтле* – дин тотучы, диндар.

химаятле татар – ул дәвернең Гани бае, мәктәптә укытучы абыз ул дәвернең Гаспринские[10] иде...

Ул дәвернең безгә исеме мәгълүм булмаган Гани байлары, Гаспринскийлары – бу милләтнең бик олуг каһарманнарыдыр. Татарның сыналу дәверендә алар җаннары, тәннәре белән күп хезмәт иттеләр. Милләтнең бер хәлдән икенче хәлгә күчүендә күп кысынкылыклар чиктеләр, кыенлыклар күрделәр…

«Язмыш шулай икән, күрәсең!..» дип, татар баласы заманның үзгәрешләренә риза булды. Тәкәммелнең фагыйлиятьне сөкүнәте, соңлау кагыйдәсенә бинаән, коруне улядан бирле сарыф ителгән фагыйлиятьне сөкүнәт тәгъкыйб итәчәк иде.

Татар баласы берничә гасырлар бер җирдә әйләнеп торды; ул истирахәт итте; куәт җыйды; хале мәдәниятендә тәгаззер дәверен кичерде, аны заман шуңа мәҗбүр итте.

Мелла мәсҗедтә Алланың берлегенә, пәйгамбәрнең хаклыгына иман китерергә өнди бирде. Абыз да, чыбыгын кулына тотып, ни җитте шулай сабак укыта бирде. Кәлимәи шәһадәт

---

*Химаятле* – башкаларның зарар китерүеннән саклаучы.

*Абыз* – мәгърифәтле, укымышлы (олылау, хөрмәтләүне белдереп әйтелә торган эпитет).

*Тәкәммелнең фагыйлиятьне сөкүнәте* – үсеш-камилләшүнең эшчәнлекне туктатуы.

*Бинаән* – нигезләнеп.

*Коруне улядан бирле сарыф ителгән фагыйлиятьне* – борынгы заманнардан бирле кулланылып килгән эшчәнлекне.

*Сөкүнәт* – тукталу, торгынлык.

*Тәгъкыйб итәчәк* – кичектереп торачак, тоткарлаячак.

*Истирахәт итте* – ял итте.

*Хале мәдәниятендә тәгаззер* – мәдәнияте торышында (үсешендә) көче җитмәвен (мөмкин булмавын) тану.

*Кәлимәи шәһадәт* – «Әшһәдү әнлә иләһә иллә Аллаһ, вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә расүлүһү», ягъни «Шаһитлык бирәм: Аллаһтан башка илаһ юк, Мөхәммәд – аның колы һәм илчеседер» дип әйтеп иман китерү, шуның белән үзеңнең мөселман өммәте икәнлегеңне тану.

өйрәтте; әбҗәд белдерде; иҗеккә башлатты, аны бетереште, Коръән укытты, мөселман җитештерде…

Харита галәмендә булган үзгәрешләрдән – халыкларның мәдәниятқә таба булган юлны кыскартырга тырышуларыннан аз вакыт сарыф итеп, күп файда алырга теләүләреннән максатка тизрәк барып җитүнең юлларын эзләүләреннән, абызның җәбере юк, ул кулына чыбык тоткан, укыта; дөньяга әһәмият бирми, мөселман җитештерергә тырыша…

II

Заманның алмашынуы, милләтләрнең алга атлау вә җәелүләре, күршеләрнең мәдәният баскычларын менүдә безгә үрнәк булулары, берни бер җирдә әйләнеп тормыйча, сызыкның бер җиреннән бозып чыгып, туры юл алырга мәҗбүр итүләре аркасында без икенче дәвергә күчәргә, ул дәверне башларга булдык.

Теге, беренче дәвер, безнең өчен никадәр кыен булса, бу дәвер дә шулай ук кыен булачак иде. Чөнки төрек-татар баласының, теге, җиһан гизгәндәге сафлык, космополитлыгы, үзенең төсен югалта төшкән, аңа башка буяу сөрткәннәр иде: абызның хәзер мәгълүматы (!) күбәйгән, башы чуалган иде. Ул: «Мин үзем алган юл белән бара бирәм!.. Чөнки…» – дидер иде. Менә хәзер татарның татарлыгын тазартырга андый-мондый чүп-чардан әрчеп, татарлык басуына яңа орлыклар чәчәргә замана каһарманнары кирәк булды, заман моны телидер иде.

Заманның теләге булды:

Бакчасарайда чыккан «кигәвен»нең* безелдәве[11], Волга хәвазасында йокларга һич ирек бирмәде… Аның безелдәве арасында «Мәктәп, мәктәп, мәктәп!..» дигән сүзләр ишетеләдер иде. Бу мәктәп, мәктәп!.. коры сүзне фәгалиятькә чыгару

---

*Әбҗәд белдерде* – хәреф өйрәтте.

*Харита галәмендә* – географик картада.

*Әрчеп* – чистартып.

* Ильминский тәгъбире иде бугай *(Г. Ибраһимов искәр).*

*Фәгалиятькә чыгару* – эшкә ашыру.

өчен, Ходайның бер сөекле бәндәсе Казалыда сәрмая җыеп ята иде[12].

Инде мәсьәлә тәсадефнең. Бу ике милләт хезмәтчесен бер-бере белән күрештерү дә, танышдыру да, аңлаштыру да туктап торадыр иде. Заман аңа да ярдәм итте: бу ике фидакяр Сәмәркандта очраштылар[13]. Икесе дә «гыйльми» кеше булганга, дәррәү бер мәктәп тәэсис итеп, тулы җәдидәне татбикан куйдылар.

<…>

## ИҖТИМАГЫЙ, ӘДӘБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ТАРИХЫН ТИКШЕРҮДӘ МАРКСИЗМ ЫСУЛЫ

<…>

Курсави, Мәрҗани, Каюм Насыйри, Акменла, Акъегетзадәләр татарның әдәби-фикри хәрәкәте тарихындагы икенче дәвернең – Борынгы Шәрыкны җимереп, яңару, европалашуның беренче баскычы, беренче адым атлавы иде. Орлыктан сабак, яфрак чыгып үскән кебек, тамчылар белән башланган чишмәләр, зураеп, елгага әйләнгән кебек, ул икенче дәвер хәрәкәте дә бер ноктада тукталып калмады: баскыч-баскыч күтәрелде, үсте, киңәйде, барлыгы бер кыйблага – Европа мәдәниятен, гыйлемен алуга карап юнәлүдә дәвам итте.

Курсави – Мәрҗаниләр белән дини исляхат хәрәкәтен Ризалар, Габәшиләр, Рәшидләр, Баязидлар, Бубилар, Мусалар, Зыялар, Әхмәтҗан Мостафалар[1] күп хезмәт, күп гайрәт белән үстерделәр, тирәнәйттеләр.

Мәрҗани тарафыннан нигез салынган милли тарихны Габәшиләр, Ризалар, Атласов Һадиләр[2], имам Халидиләр[3], Зәки Вәлиди[4], Һади Мөнировлар[5], Газизләр[6], Батталлар[7]

---

*Сәрмая* – акча.

*Тәсадефнең* – очрашуның.

*Тәэсис итеп* – төзеп, оештырып.

*Татбикан* – шуңа яраштырып, туры китереп.

*Исляхат* – яңарыш, үзгәреш.

һаман-һаман яңа материаллар, яңа ысуллар белән, ләкин шул ук рухта, шул бер үк кыйблага карап эшләүдә, үстерүдә дәвам иттеләр.

Каюм Насыйри тарафыннан башланган хезмәтләрдән гыйльми, фәнни мәгълүматны, тәрҗемә эшләрен хисапсыз күп каләмнәр алып китте; аның «Лөгать-словарь»ларын – мәрхүм Солтан Рахманколый[8], календарьларын Шәрәф Шәһидуллин[9] дәвам иттерделәр.

Шул ук Каюм Насыйриның «Әнмүзәҗ»ендә нигез ташлары салынган тел, имля, сарыф, нәхү, бәлягать кагыйдәләрен тикшерүне Һади Максуди[10], Г. Ибраһимов, Шакирҗан Таһири[11], Гыймад Нугайбәк[12], Корбангалиев, мөгаллим Сәйфи, Г. Сәгъди, Г. Шәрәф[13], Җ. Вәлиди[14], Нигъмәт Хәкимовлар[15], Г. Алпаровлар яңа хезмәтләр белән киңәйттеләр, үстерделәр.

Шул ук Насыйри башлаган халык әдәбиятын җыю хезмәтенә Хуҗа Бәдигыйләр варис булды – аны эшләп баралар.

Акменла, Акъегетзадәләр тарафыннан салынган беренче әдәби-шигъри сукмаклар да зур юлга әйләнә, моннан, кәрван-кәрван булып, яңа саф көчләр тезеләләр.

1) Нәсердә – «Әсма», «Сәлимә»ләр[16], Садри Максудиның «Мәгыйшәтләре»[17], Фатих Кәрими, драматург Галиәсгар Камаллар[18], «Тутам» мөхәррире Г. -Чыгътайлар[67], Г. Исхаковлар, Закир Һади[20], Ярулла Вәли[21], Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирханнар, Г. Газиз, Г. Рәхим[22], Г. Рәфикъләр[23], Ш. Камаллар;

2) мәнзумнәр бабында: Гафури, Тукай, Думави, Укмасый, Бәшири, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Сүнчәләйләр, – менә шул ике гөруһ хезмәтчеләр, Акмулла – Акъегетзадә тарафыннан башланган чишмәне зур елгага әйләндереп, шул агымда хезмәт кылучылар.

## IX

1905 ел революциясе бу хәрәкәтне көчәйтә, аның алдындагы киртәләрне, өстен каплаган ташларны алып ыргыта. Моның белән икенче дәвер, беренче баскычны үтеп, зур куәт ала.

---

*Мәнзумнәр бабында* – шигырь өлкәсендә.

Ул революция дәвере татар хәрәкәтләре эчендә тагы бер тармак арттыра – мәйданда сәяси хезмәт туа, Думага сайлаулар бездә яңа тип хадимнәр дөньяга китерә. Бу гөруһның башында мирза, алпавыт адвокат Алкиннар, Әхтәмовлар, Сәйдәшләр, Тәфкилевләр, Бигловлар, Акчуралар[24], бераздан соң шәкерт, студенттан Максудовлар Дума тирәсендә әйләнә башлыйлар.

Бу сәяси хәрәкәт аз арада бик нык оешып өлгерә: алар «Мөселман иттифакы» исеме белән бер партия төзиләр. Икенче дәвернең төп үзәкләре – дини реформаторлары, мөгаллимнәре, мөәррихләре, әдипләре, шагыйрьләре, кыскасы, зур күпчелеге бу партиягә әгъза була, моңа ярдәм итә, моның сәяси программасын халык эчендә тарата. Революция җиңелгәч, бу партиянең платформасын Өченче, Дүртенче думалар янындагы мөселман фракцияләре, бюролары гамәлгә куялар. Анда да икенче дәвернең һәммә агымнары боларга ярдәм итә, болар фикеренә кушыла.

Башында Акчуралар, Рәшидләр, Мусалар, Максудилар, Фатих Кәримиләр торган ул «Мөселман иттифакы»[25] партиясенең программасында төп маддәләре ошбулар иде:

1. Хокукы парламент белән чикләнгән монархия, Дума алдында мәсьүл хөкүмәт.

2. Хосусый милек мөкаддәс.

3. Алпавытның җире крәстиянгә алып бирелсә, моның өчен крәстияннән алпавытка «гадел» бәһа белән акча түләтү.

Кыскасы, болар уң кадет белән октябристлар арасындарак бер партия иде.

<…>

Бу икенче дәвердә вакытлы матбугат туды. Татар театры дөньяга килде, мәктәпләр, мәдрәсәләр ислях кылынды. Шәкерт ихтиляллары булды. 1885 еллардан алып бик зур бер җәдит хәрәкәте булып алды. Җәдит – кадим көрәште. Мәктәпне яңача юлга салудан алып, икенче дәвернең бөтен эше, бөтен кешеләре

---

*Хадимнәр* – хезмәтчеләр.

*Ихтиляллары* – кузгалыш, хәрәкәт, баш күтәрүләре.

халык кашында җәдитчә, җәдидә, җәдитлек булып мәшһүр булды. Икенче дәвернең сыйнфый нигезен, матди терәкләрен тикшерсәк, ни күрербез?

Иң элек матди терәк хакында: һичбер хәрәкәт матди көчтән башка яши алмый.

Безнең тарихның бу икенче дәверенең бөтен матди терәге зур, урта татар байларының иганәләре, һиммәтләре, юмартлыклары иде. Тәфсилгә хаҗәт юк.

Риза казыйның «Әхмәт бай»[26], Борһан Шәрәфнең «Гани бай»[27], Батталның «Вәли Яушевлар»[28] дигән китапларын укысагыз, татарның беренче җәмгыяте хәйрияләре, клублары, «Галия»[29], «Мөхәммәдия»[30], «Буби»[31], «Хөсәения»[32] мәдрәсәләре тарихыннан аз гына хәбәрегез булса, «Вакыт»[33], «Ил»[34], «Сүз»[35], «Кояш»[36], «Тормыш»[37], «Алтай»[38], «Корылтай»[39], «Шура»[40] журналларының кемнәр акчасы белән нәшер кылынганнарын хәтерләсәгез, «Иттифак», «Фракция», «Бюро», Милли, Хәрби шуралар, Милли идарәләр, исәбе-саны булмаган җәдит мәктәпләр кем һиммәте белән барганлыгын уйласагыз, мәсьәлә үзеннән-үзе ачылыр.

Икенче дәвер хәрәкәтенең – бөтен әдәби, фикри, сәяси, иҗтимагый хезмәтләренең һәммәсе татар буржуасының матди ярдәме белән барганын күрәчәксез.

<…>

Өченче дәвер исә, үзенең сыйнфый рухына каратып, бөтенләй яңа институтлар, оешмалар тудырды. Февраль дәверендә һәртөрле социаль комитетлар, партия оешмалары, татар эшче клублары, кәсептәшлек оешмалары, Октябрьдән соң мөселман комиссариатлары, шөгъбәләр, гаскәри фиркаләр, хәрби һәйәтләр, бюролар, партия гали мәктәпләре, хәрби-сәяси курслар, хәзер инде күпчелек булган җирдә – аерым автономияле җөмһүриятләр... илх... төзелде.

Мәсьәләгә марксизм рухыннан карый алмаучылар әйтәчәк: болар бит һәммәсе татарның үз җимеше түгел, болар –

---

*Һиммәтләре* – тырышлык, кайгыртучанлыклары.

читтән килгән җилләрнең көчләп керткән нәрсәләре генә, диячәкләр.

Ләкин дөньяга, тарихка чак кына күз салу мондый карашның ахмак, җаһил бер фикер икәнен күрсәтәчәк.

Адәмнәр бер-беренә тәэсир итмәслек дәрәҗәдә аерым вәхши гаиләләр дәвереннән әллә кайчан чыкканнар. Соңгы 3–4 мең ел буенча халыклар, җәмгыятьләр, милләтләр бер-беренә бәйләнып яшиләр. Дини, әдәби, фикри, мәдәни хәрәкәтләр үз эчендә бикләнеп калмый – азмы-күпме читләргә әсәр итә. Гарәпнең исламы, Руманың христианлыгы, Европаның капиталы, революцияләре моңа ачык мисаллар.

Шул нигездән үз тарихыбызга килсәк күрәбез: һичбер дәвер үз эченнән, тик үз тамырыннан гына үсеп чыга алмый, бәлки бәйнәлмиләл хәлләргә багланганлыгы һәркемгә мәгълүм.

1. Беренче кадим дәвердә безгә гомум Көнчыгыш үзенең дине, фикере, әдәбияты белән нык әсәр итте. (Бәйнәлмиләл феодализм калдыгының Көнчыгыш бүлеге тәэсирендә булды.)

2. Икенче дәвердә без турыдан-туры шул заманда Европаның буржуазный мәдәнияте тәэсирендә булдык, һичкемнән яшерми әйтә алабыз ки, хәзерге өченче дәвердә үзенең иҗтимагый, гыйльми, фикри, әдәби хәрәкәтләрендә Европа пролетариаты тәҗрибәләреннән күп сабак ала, татар буржуасы сыйнфый файдасы чех, Колчак артыннан өстерәлгән кебек, татар-башкорт ярлылары да үзләренең икътисади азатлыкларын саклауда рус һәм башка пролетариатның ярдәменә таяна, алар белән кулгакул бара.

Мондый мөнәсәбәт – һәммә милләтләр, һәммә сыйныфлар өчен табигый бер хәл.

<…>

---

*Әсәр итә* – тәэсир итә.

# ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ НИНДИ ЮЛ БЕЛӘН БАРАЧАК?

<…>

Мәсьәлә болай куела:

– Интернационалист пролетариат хәрәкәте, пролетариат революциясе һәм социализм эчендә аерым милли мәдәниятләрнең язмышы ни булачак? Болар үзләренең милли төсләрен югалтачакмы? Яки шул нигездә үскән хәлдә интернациональ максудлар өчен хезмәт кылачакмы?

– Болар эчендә татар милли мәдәнияте нишләр? Башкалар үскән, күтәрелгән хәлдә безнеке сүнеп калмасмы? Татар халкы моны үзе ташлап, башка берәр көчле мәдәнияткә кушылу чарасын күрергә тиешле түгелме? Яки тарихның сукыр агымына буйсынып, ни булса, шул булыр тактикасын тотаргамы?

<…>

Иске патшачылык заманының татар мирзалар типлары һәркемгә мәгълүм: болар рус хөкүмәтенең чиновниклары иделәр. Ихлас күңел белән шуңа хезмәт кылдылар. Үзләренең сыйныфташлары рус дворяннары белән бергә, бер рәвештә тәрбияләнеп, рус мәдәнияте эчендә кайнап, татар халкыннан аерылып яшәделәр. Боларның бөтен көнкүрешләре рус мәдәниятенә, рус теленә баглы иде. Менә шул бытие* татарның бу катлавында, тик рус мәдәнияте аркасында гына яшәргә мөмкин, татар мәдәнияте юк, булса да кыйммәтсез, аны күтәреп, үстерергә тырышып маташу – нәтиҗәсез эш дигән сознание** тудырды. Болар татар телен белмиләр, аны кирәксенмиләр, татарның мәктәбе, әдәбияты, тарихы, тормышы болар өчен чит нәрсәләр иде.

Рус җәмәгатьчелеге, рус зыялысы, рус мәдәнияте эчендә кайнап яшәү сәбәпле, безнең хәзерге татар совет хезмәтчеләренең – чиновникларының бер өлешенә дә шул иске мирзалык чире вакытлыча кайтып йокты. Икенче төрле әйткәндә, бездә хәзер яңа тип мирзалар мәйданга килде.

Болар әйтәләр: татарның теле, әдәбияты русныкына караганда ярлы, татар мәдәнияте рус мәдәниятеннән түбән, татар

* Бу сүз кириллицада язылган.

** Бу сүз кириллицада язылган.

тормышы руснықыннан артта. Боларга үзеңне һәм халыкны баглау аны тарихи үсүдән туктату була. Татар мәдәнияте барыбер күтәрелә, үсә алмас, ул рус мәдәнияте дулкынында эрер, йотылыр, диләр. Кайберәүләре шулай ачык әйтә, икенчеләре, теле белән әйтмәсә дә, бөтен гамәле белән шул юлда бара. Курсларда, мәктәпләрдә татар теленә әһәмият бирмәскә, аны, иске заманның закон божий* дәресләре кебек, бер күңелсез мәҗбүрият кебек кенә карарга азапланучы кайбер татар егетләре – менә шул дулкынның бер мисалыдыр. Бездә хәзер бу яңа мирзалар аерым бер катлау булып киләләр: болар татар әдәбиятын, татар матбугатын укымыйлар, татар телендә язарга белмиләр, моны үзләре өчен кимчелек дип тә карамыйлар. Үзенең бу наданлыгын ул ниндидер эчке бер «мәдәни» мактану белән әйтеп куя. Балаларын, якыннарын, әлбәттә, рус мәктәбенә, рус балалар йортына, рус курсларына бирәләр. Иске заманда татар мәктәбе начар булганга, бертөрле динче, милләтче катлау да балаларын рус мәктәпләренә кертәләр иде, ләкин алар, һич булмаса, үзләре ике мөгаллим китертеп, өйдә ана теле дәресләрен укыталар иде. Әмма безнең хәзерге «мирзалар» моны да эшләмиләр, үзләре, татар гәзитәсенә мәкалә бирергә туры килсә, аны русча яздырып җибәртәләр. Болар әгәр коры уйламаудан, әзерлексезлектән генә килгән бер чир булса, чарасы җиңел булыр иде, ләкин гыйнвар 25 җыелышы боларның гади чир генә түгел икәнен, бәлки аерым бер агым рәвешенә кереп барганын күрсәтте. Ягъни гамәли мирзалык үзенә нәзари нигез эзли башлады.

<…>

Беренче баскыч мәктәпләрдә уку ана телендә булу кирәклеге мәсьәләсе турында хәзер ике сүз ишетелми. [19]24 елның Мәскәү съездында рус телендә булсын дип чыгучылар Донбасска таянырга уйлаганнар иде. Аннан бирле үткән 3–4 ел эчендә Донбасстан, Уралдан, Себердән һәм татар эшчесе күпчелек булган башка һичбер җирдән үз ана телен ташларга диеп күтәрелү күренмәде. Димәк, бу беренче нигез момент хәзер инде өзелгән.

---

* Бу сүз кириллицада язылган.

Өлкәннәр арасында укый-яза белмәүчелекне бетерү эшендә дә бераз аңлашылмаучылык бар иде. Кайбер урыннарда, бигрәк тә рус күпчелеге эчендә калган эшчеләр арасында, кайбер иптәшләр рус телендә генә үткәрергә чамалыйлар иде. Хәзер ул да тынычланды. 1913–1914 елларда, бигрәк тә сугыш чорында, Русиядә рус милләтчелегенең аеруча котырган заманы иде. Бу исереклек социал-демократиянең дә бер катлавын үз эченә алган иде. Менә шул заманда Владимир Ильич Ленин «О национальной гордости великороссов» исемендә бер мәкалә язды[1]. Анда шул сүзләр бар иде:

«Без аңлы великорус пролетарийлары өчен милли горур чит бер нәрсәме? Әлбәттә, түгел. Без үзебезнең телебезне, үзебезнең туган илебезне сөябез. Без башка һәрнәрсәдән артык үз туган илебездәге хезмәт массасы (ягъни андагы халыкның уннан тугыз өлешен), аңлы демократлар һәм социалистлар дәрәҗәсенә күтәрү өчен эшлибез».

<…>

Без пролетариат мәдәнияте төзибез. Монда һич шик юк. Ләкин үзенең мөндәриҗәсе буенча социализм нигезендә булган пролетариат мәдәнияте, социализм төзелешенә катнашкан төрле халыкларның тормышларында, телләрендә булган башкалыкларга карап, үзенең тышкы калыбында, шәкелендә бик төрлечә була: мөндәриҗәсе белән пролетариатча, форма буенча милли – менә социализм бара торган гомумадәм мәдәнияте шулай булачак. Пролетариат мәдәнияте милли мәдәниятне бетерми (юкка чыгармый), бәлки аңа мөндәриҗә бирә». Шулай ук, киресенчә, милли мәдәният пролетариат мәдәниятен бетерми (юкка чыгармый), бәлки аңар форма бирә.

<…>

Бу формула турында озак тукталып торырга хаҗәт юк дип беләм. Моның мәгънәсе, аңлаешы һәм форма буенча милли булыр дигән сүздән морат нәрсә икәнлеге, әлбәттә, һәркемгә ачык: халыклар үзләренең телләре, гореф-гадәтләре, тормышлары, тарихи язмышлары буенча бер-берләреннән тышкы калыпларда байтак аерылалар. Шуңа карап, аларның һәрберенең мәдәнияте, мәдәни хәрәкәте дә тышкы төстә үзенә башка аерым

рәвештә гәүдәләнәләр. Мәсәлән, мәктәп, сәнгать, гыйлем, әдәбият – болар һәммәсе милләтнең үз телендә булырлар. Үз телендә киңәеп, тирәнәеп үсәрләр; үз зәвыгына, үз хаҗәтләренә каратып туарлар, үзенә уңгай, аңлаешлы калыпларга салынырлар, үз тормышы белән сугарылып, үзләренең аерым тарихи моментлары, тудырган мәсьәләләре юлында эшләрләр; менә бу яклар буенча үзбәкнең, русның, казакъның, әрмәннең, татарның, грузинның, башкортның, украиннарның, азәрбайҗан төрекләренең мәдәниятләре бер-береннән бик нык аерылырлар, бу тышкы калыпларда һәр халыкның мәдәнияте үзенең милли нигезендә, үз ана телендә, үз тормышының аерым хасиятләре белән сугарылыр, аерым рәвешләнер; ләкин эчке идеологиядә, төп нигез принципларда, алдагы максудларда бу төрле телдә, төрле төстә, төрле калыпта булган бу күптөрле милли мәдәниятләр һәммәсе берләшәләр: пролетариат революциясе аркылы коммунизмга бару, моның өчен интернациональ байрак астында, тел аермаларына карамыйча, киң эшче-крәстиян коллективы буларак көрәшү: үз буржуасына һәм бөтендөнья капитализмына каршы сугыш фронты тоткан хәлдә, социализм төзү юлында эшләү, моның өчен бөтен мәдәниятләрне, гыйлемнәрне, сәнгатьләрне материализм нигезенә салып, буыннарны киләчәк гомумадәм максудлары рухында тәрбияләү, мәктәпләргә, техникага, җәмгыятькә, көндәлек гаилә тормышларына, кыскасы, бөтен мәдәни хәрәкәтләргә менә шундый һәммә телдәге хезмәт халыкларының якты, азад киләчәкләре өчен уртак булган мәнфәгатьләре ягыннан карап юлбашчылык кылу – менә аерым мәдәниятләрдә шундый нигез, уртак мөндәриҗәләр булыр.

<…>

Татарлар, бу пролетариат хәрәкәте нигезендә милли мәдәният үстереп, социализмга баручы милли мәдәниятләр кәрванында аерым бер отряд булып дәвам кылырлармы, әллә татар хезмәт халкы мәнфәгате ягыннан караганда, башка берәр мәдәни хәрәкәт эченә кушылып китү файдалырак булачакмы? Кушылса, кемгә? Чувашкамы, французгамы, башкорткамы, руска яки үзбәккәме? Менә бу – бик нык уйланырга һәм бик сак җавап бирелергә тиешле бер мәсьәләдер.

<…>

Француз мәдәнияте зур, бай, югары. Ләкин без икътисади һәм сәяси якларда алардан бөтенләй өзелгәнбез. Шуңа күрә ул мөмкин түгел, диярләр. Чувашлар, башкортлар – якыннар, күршеләр, кардәшләр, безгә көнкүрештә дә бик нык баглылар. Ләкин болардагы мәдәни хәрәкәт һәм икътисади-сәяси куәт татардагыдан зәгыйфь, диярләр.

Русның теле бик бай, әдәби, гыйльми теле бөтенләй эшләнгән һәм матур. Рус әдәбияты дөньяның иң алдынгы әдәбиятларыннан санала. Рус мәдәнияте безгә караганда бик күп, бик күп дәрәҗәдә югары. Соңгы ун ел исә рус әдәбиятына, рус гыйлеменә, рус мәдәниятенә бик көчле рәвештә пролетариат элементы кертеп, аеруча зур, яңа кыйммәтләр арттырды. Бу югары (гали) мәдәният безгә якын булу гына түгел, һәммә яктан безне чолгап алган. Без аның эчендә, диңгездәге бер атау кебек, уралып алганбыз, тарихи яктан караганда, мең еллар буенча бу мәдәнияткә күрше яшәдек, 3–4 йөз ел инде бөтенләй моның уртасында калдык. Бу мәдәният бик күп яктан безгә остаз була килде. Безнең яңаруыбыз, безнең әдәбиятыбыз, безнең гыйлемнәребез, безнең революция хәрәкәтләребез – һәммәсе бу рус мәдәниятенең бик нык тәэсире һәм мөгаллимлеге астында үстеләр. Икътисади, сәяси яктан да без бөтенләй диярлек береккәнбез. Хәзер безнең тормышыбызның һәммә ягында бу югары рус мәдәниятенең элементлары туктаусыз арта баралар. Рус мәдәнияте туктаусыз дулкыннар белән безгә керә, тула бара. Шулай булса?.. Шулай булса, татар өчен, үзенең иске колакчынын утка ягып, бу яңаны кию файдалырак булачагы үзеннән-үзе ачык түгелме?

Татарның саны бик аз. Үзе бик таркау. Мәдәнияте рус мәдәнияте белән чагыштырмас дәрәҗәдә түбән! Татарның әдәбияты, татарның театры, татарның мәктәбе, сәнгате, матбугаты – болар бит һәммәсе, Мәскәүнеке белән үлчәштергәндә, бөтенләй югалып калалар. Татарның хуҗалыгын, икътисадын тикшереп караучылар якын киләчәктә дә бик тиз генә татар мәдәниятенең гөрләп үсеп, тиз генә югары менеп җитүенә өмет ачмыйлар түгелме?

<…>

Ләкин монда шуны тагын хәтердән чыгармаска кирәк.

Милли мәдәният дигәннән, кәләпүш киеп, без өч йөз ел изелгән дип, хәсрәт йыры йырлап йөрүне генә алу хата булачак. Шөбһә юк, милли мәдәниятнең төп элементлары эченә башлыча халыкның үз тормышыннан алып, үз теле нигезендә, үз хаҗәтләренә каратып, үзе тарафыннан иҗат кылынган кыйммәтләр керәчәкләр. Ләкин милли мәдәният чиген моның белән кыскарту бик зарарлы идеализм булыр иде.

Дөньяда һичбер халык башкалар белән алмашудан башка яши алмый. Тик товар алмашу гына түгел, техника, гыйлем, сәнгать, һөнәр, тәҗрибә, гадәт, методлар алышу – мәдәни хәятта беренче рольне уйнаучылардан була.

<…>

Без югарыда, Покровский сүзенчә, тел милли мәдәниятнең иң баш коралы икәнен күрдек. Революциягә кадәр татар теле һәркайдан куылган, хокуксыз бернәрсә иде. Пролетариат диктатурасының каты хөкеме белән ул элекке коллыктан азад кылынды гына түгел, рәсми дәүләт теле булып әверелде. Ләкин коры рәсмият аз иде. Аны чыннан да реаль бер көчкә әйләндерү лазем иде. Бу хакта башта күп шөбһә булды. Имансызлар, татар телен гамәлгә кую әнә шул яңлыш язылган вывескалардан үтмәс, диделәр. Бу хактагы беренче декрет (1921 ел, 25 июнь) бик курка-курка гына беренче адымны атлаган иде. Байтаклар һаман да моны кәгазьдә калыр дип уйладылар. «Тат» дигән көлке дә чыгарганнар иде. Ләкин революция үзенең принциплары белән шаярырга теләмәгәнен күрсәтте. 1925 елда инде, кичерелгән гадәттән тыш авыр ачлык фаҗигасенә карамастан, җөмһүриятнең биш елы тулганда түбәнге хәлне күрдек.

Татар авылларындагы советларда татар телендә кәнсәләрия эше түбәндәгечә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1922 | 1923 | 1924 | 1925 |
| 20% | 50% | 80% | 85% |

Волбашкармалар аппаратының миллиләшүе:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1921 | 1922 | 1924 | 1925 |
| 30,4% | 40,4% | 51,4% | 52% |

Бу татарлашу югары киткән саен кими, җөмһүриятнең үзәк наркоматларында әле хәзер дә канәгатьләнерлек дәрәҗәдә түгел. Ләкин бернәрсә ачык: алда торган зур киртәләргә, хәзерлексезлекләргә карамастан, пролетариат революциясе үзенең программасын үткәрүдә туктаусызлык белән бара. Милли мәдәниятнең бер тармагы – администрацияне миллиләштерү моменты туктаусыз үсә бара.

Без югары бер вакыйга күрдек: 1924 елның февраль аенда Мәскәүдә булган татар мәгариф эшчеләре съездында бер төркем иптәшләр башлангыч татар мәктәпләрендә дәресләрнең ана телендә түгел, бәлки эшче районнарында рус телендә булуы кирәклеген алга сөрделәр. Без бик каты көрәш аркасында ул принципны җимерә алдык. Менә бу вакыйга җөмһүрияттә нык урынлашып барган татар телен, һич булмаса, читтә рус теле белән алмаштыру өчен, бер тартышып караулары иде – монда руслашу программасы үзенә бер почмак алмакчы иде – булдыра алмады. Шуннан соң һичкемнең һичкайда татар мәктәбендә уку теленең ана теле булуына каршы сүз әйткәне ишетелмәде.

<…>

Әле монда зур җитешмәгәнлекләр бар. Әле идеалдан ераклар, ләкин бернәрсә факт – милли мәдәният революция аркасында урта мәктәпләрне бөтенләй үз элементы белән тутырып бара, көннән-көн үсә, тирәнәядер. Киләчәктә мәсьәлә тагы югарырак куелачак.

<…>

Безнең күз алдыбызда Казанның ике югары мәктәбендә (ВПИ белән ТКУ[2]) татар теле, татар әдәбияты, татар дәресләре урын алдылар. Бу әлегә беренче адым. Ләкин инде моннан үтеп, Казанның 125 ел яшәгән карт университетына татар теле керергә хәзерләнеп бара. Якын киләчәктә моны да күрәчәкбез.

<…>

Без югарыда мәдәниятнең баш коралы тел икәнен күргән идек. Бичара татар теле үзен саклауда һәм үстерүдә дә зур мәшәкатьләр, газаплар кичерде. Иске замандагы мирзалар һәм муллалар карашы турында тукталмыйм; миссионерларның

бу телгә һәм татар язуына ни дәрәҗәдә ачу белән карап, бетерү өчен чаралар эзләгәненә кайтып тормыйм. Патшачылык хөкүмәтенең мәшһүр руслаштыру сәясәте аркасында татар теленең нинди кысрыклыкларга төшүен сөйләргә дә керешә алмыйм.

Менә болар һәммәсе татар теленә киртә булдылар. Бердән, аның таралуына, икенчедән, үзенең үсүенә, эшләнүенә юл куймадылар. Югарыда без Октябрь революциясе соңында татар теленең рәсми хокуклы дәүләт теле булганын күрдек. Гамәлгә керүен дә тикшердек. Әгәр без телнең, бу коралның үзенең эшләнүенә килсәк, бу бездә тик Насыйри бабайдан гына башлана. Әмма революциядән соң бу эшләнү бик зур адымнар белән алга атлап, татар мәдәниятенең баш коралы камилләшү юлына төште.

Ләкин руслашу моменты да үзен күрсәтеп үтте. Әмма аңа каршы татар әдәби активы үзенең дөрес принципларын куеп, татар телен дөрес юлда саклап калды. Бу юлдагы ачык нәзари көрәш шул ук 1924 елның Мәскәүдәге татар-башкорт мәгарифчеләр съездына бәйләнадыр. Монда әдәби тел һәм атамалар мәсьәләсе куелган иде. Өч агым көрәште. Берәүләр иске гарәпне саклау юлында булдылар, берәүләр гарәпне бөтенләй чыгарып бетереп, аның урынына рус сүзләренә капканы бөтенләй киң ачып куярга тәкъдим кылдылар. Күпчелек боларның берсен дә кабул итмәде. Башлап шул съезд киңәшендә, аннан соң 1924 елның сентябрь 16 да Казан киңәшендә тикшерелеп сызылган юл соңра Гыйльми үзәк тарафыннан (1925 ел, ноябрь) рәсми кулланма тезислар булып чыгарылдылар. Монда татар теленең гарәпләшүме, руслашумы яки татарлашумы кебек агымнардан каюсын тотачагы, ягъни милли мәдәният мәсьәләсендәге принциплардан ниндиен алга куячагы ачык күрелде. Бу кулланма тезисның төп моментлары болар:

1) татар әдәби теленең иң төп материалы үзебезнең ана телебездән алынырга тиешле татарча сүзләр була торып, болар урынына башка телдән һич сүз алынмас;

2) гарәп сүзләреннән, рус сүзләреннән татар телен тазартырга кирәк;

(Кулланмада күрсәтелгән билгеле шартлар, билгеле чикләр буенча гына бу гарәп, рус сүзләрен кулланырга мөмкин булыр.)

3) татардан сүз тапмаса, мәдәни милләтләрдә уртак йөргән бәйнәлмиләл сүзләр һәм атамалар безнең матбугатыбызда кулланылырлар, ләкин болар татар калебенә, татар теле төзелешенә салынырлар.

Күрәсез: татар теле үзенең төзелешендә беренче нигез кылып, үз ана [теле] элементларын ала. Икенче нигез – бәйнәлмиләл сүзләр (революция, трактор, интернационал, пролетариат, математика һәм башкалар). Менә монда да татар теле үзенең руслашу ягында бармавын, иске гарәпчелек нигезендә калырга да теләмәвен күрсәтте. Менә ничә ел инде шул югарыгы нигезләрдә тел үсеп, эшләнеп, баеп килә. Руслашу тенденциясе бөтенләй җиңелде. Шул татарлашу нигезендә хәзер безнең әлифбаларыбыз, уку китапларыбыз, тел сабаклары, имлялар, сарыф-нәхү – татар грамматикалары, әдәбият кануннары һәм әдәбият тарихлары тәмам эшләнеп чыгып юлга салынды. Хәзер инде татар теленең тулы сүзлеге эшләтелмәктәдер.

Хәзер әнә шул нигез буенча атамалар эшләнә, шуның буенча халык өчен гыйльми, сәяси әсәрләр таратыла. Хәзер шул аз вакыт эчендә дә татар теле бик нык күренер дәрәҗәдә баеды. Татар телендә бу соңгы 3–4 ел эчендә чыккан китаплар, дәреслекләр, гыйльми әсәрләр үзләренең мөндәриҗәләре буенча да, эшләнүләре буенча да элеккеләрдән бик күп алдалар. Хәзер без инде электә исеме дә булмаган сәяси әсәрләр өстенә урта мәктәпләрдә дәреслек булырлык бик күп гыйльми китаплар басып чыгардык. Мәйдандагы биология, физика, химия, математика, һәндәсә, җәбри, өчпочмаклылар, гигиена, Русия тарихы, революция тарихы, татар әдәбияты тарихы, ботаника, зоология һәм башка күп китапларыбыз да хәзер татар мәдәниятенең бу тармагында да үсү, күтәрелү, тирәнәю барганын күрсәтәләр.

<…>

## «РӘШИДЛӘР, РИЗАЛАР, БАЯЗИДЛАР, ИБРАҺИМ МИРЗАЛАР, ГАБӘШИЛӘР, БЕР ДӘРӘҖӘГӘ КАДӘРЛЕ БУБИЛАР – МЕНӘ ШУЛ КҮБӘЕП УЯНА БАШЛАУЧЫЛАРЫННАНДЫР»

*(МИЛЛӘТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ)*

### ШӘРЫКНЫҢ БӨЕК РЕВОЛЮЦИОНЕРЫ МУЛЛАНУР ИПТӘШ ВАХИТОВ

<…>

Мулланур иптәшнең кабер туфрагы суынып җитмәс борын, ул коммунист-большевик идеме, түгелме, интернационалистмы яки панисламистмы иде дип зур гауга күтәрделәр. Ул үтерелмәгән, ул чехлар белән киткән дигән кебек кабахәт ялганнар таратудан оялмадылар.

Шул гауга, шул тавыш әле һаман да бөтенләй бетеп җитмәгән. Татар-башкорт хәятының караңгы почмакларына кереп оялаган кайбер кызганыч бәндәләр әле дә, пычрак сазда сызгырган җыланнар кебек, курка-курка гына булса да, шул кара зәһәрле уйлары белән пышылдап-шыелдап чыккалыйлар.

Ләкин бу безгә, Мулланурны яхшы белгән революционерларга, һәм көлке, һәм мәгънәсез, һәм җан әрнеткеч бер ваклык, пычраклыктыр.

<…>

Мулланур Вахитов рәсми коммунист булгандырмы-юкмы? Ул интернационализмны төрле җирдә төрлечә яшәп, төрле телдә сөйләшә торган халыкларның аерым хосусиятләрен игътибарга алмаучы, ләкин гамәлдә барын рус тәэсиренә калдырып, башка милләт мәзлумнәренең аңнары, хокуклары үсүенә

манигъ булучы хыялыйлар кебек аңлаганмы яки тормышның, тарихның агуын үзенчә төшенеп, мөселман пролетариатының азатлыкка ирешүендә үзенә башкарак бер юл тотарга тиешлеге фикерендә, аерым тәгъбиренчә, панисламист булганмы? Болар – әһәмиятләре икенче, өченче дәрәҗәдәге мәсьәләләр.

<…>

Мәсьәләгә шул ноктадан караганга, кесәсендә коммунистлык карточкасы булып-булмавын мин бөтенләй нәүбәттән алып ташларга кирәк дим. Шыр ялангач интернационалист идеме, әллә, тактика мәсьәләсендә халыкларның тарихи, җәгърафи, нәсәби хосусиятләрен игътибарга алу фикерендә булып, мөселманнар арасында социализм юлы бераз башкачарак булырга тиешле дип таба, үзенчә һәм дошманнарыча әйткәндә, ул социалист-панисламист идеме мәсьәләсен саф бер гыйльми мәсьәлә, тактика мәсьәләсе итеп карарга тиешлебез.

<…>

Бу мәсьәлә бөтен көенчә гамәлдә күренгәне дә юк иде. Миллият хакындагы фикерләр, ысуллар, ляихәләр һәммәсе диярлек капитализм вакытында, һич булмаса, беркадәр милли азатлык тәэмин итү әмәле белән туганнар иде.

Бөек Октябрь революциясе буны безнең алдымызга бөтен дәһшәте белән китереп бастырды.

Без аңарчы да буның белән күп газап чиккән идек. Фикеремез, идеалымыз башка милләт пролетариаты белән бергә бару ягын көчли. Рус иптәшләр дә шуңа димли. Бергә барсак, безнең пролетариат, крәстиян, үзенең тарихи хатасы буенча, «милли» буржуалар кочагына ташлана. Уфада, Уралда Октябрь революциясенә чаклы без буның ачысын күреп үткәргән идек. Башта, бергә барганымыз хәлдә, тәҗрибә күрсәтүенчә, партия оешмаларын да, сайлау списокаларымызны да аерым чыгарырга мәҗбүр идек.

Мин уйлыйм, Русиянең һәммә җирендә руска башка һәммә милләт социалистлары бу трагедияне үз башларыннан кичер-

---

*Манигъ булучы* – киртә булучы.

гәннәрдер. Бу, – чыннан да, трагедия. Бунының исеме мәхкүм милләтләр пролетариаты эчендә сыйнфый көрәшкә милли азатлык хәрәкәтен кушу мәсьәләсе булырга тиешледер.

Бу – мәсьәләнең тактика ягы.

Тактика – вакытлы эш. Киләчәктә без аның үзгәрүенә, пролетариат, кайсы милләттән булса да, бер-берен яхшы аңлап, бергә эш кылырлык хәлгә җитүенә ышанамыз.

* * *

Ләкин мәсьәлә бунының белән бетми әле.

Социализм коелып-ясалып, хәзер көенчә күктән төшмәячәк.

Ул – җир җимеше. Тарихның, хәзерге һәм үткән мәдәниятләрнең аңа зур тәэсире булачак.

Менә бу – ерак киләчәккә карый алучылар алдына күп мәсьәләләр китереп куя.

Болардан берсе – социализм нигезендә төзеләчәк мәдәниятнең ни рәвешле булуы. Ул хәзерге Европа мәдәниятенең гомуми милеккә корылганы гына булырмы? Әллә аңа сүнгән мәдәниятләр дә үзләренең яхшы якларын китереп кушарлармы?

<…>

Менә шушы ике мәсьәләдә Вахитовның юлы интернационализмны үз халкыңның хосусиятләрен дә игътибарга алмау дип аңлаган социалистлардан аерыла иде.

Ул революцияне иҗтимагый дип аңлаган; коры аңлау гына түгел, үзенең сүзе, язуы, гамәле белән эшчеләрне, крәстияннәрне шул юлда тәрбия кылган; кыйбла итеп бөтен милләтләрнең дустлык, туганлык нигезендә берләшүләрен тоткан хәлдә, мөселман пролетариатының хәзерге дәверендә аерым оешмалары булуын лазем таба.

<…>

Вахитов безнең халыкның хосусиятләре дигән мәсьәләдә төп фактор – төп җамига иттереп башлыча исламнан туган хәлләрне ала яки, башка нәрсәдән туса да, исламныкы иттереп карый; дини, игътикади ягыннан түгел, бәлки бер дин, бер

---

*Җамига иттереп* – җыю, туплаучы чы иттереп.

*Игътикади* – ышану.

игътикад астында яшәүдән бөтен җир йөзе мөселманнарының үзләренең аерым, һәммәсе арасында уртак хосусиятләр таба, шулар буенча һәммәсенә бер тактика – бер юл белән бару файдалы дип уйлый иде. Шуның өчен ул үзенең фикере белән бөтен дөнья мөселманына карый, сүзендә, язуында, гамәлендә гарәби, һинди, мисыри, төрки барын да бербөтеннең әгъзалары итеп саный, барына эшләргә, хезмәтен һәммәсенә тидерергә, Кызыл байрагы астына барын җыярга тырыша иде. Безнең оешма, әйтик, барлык татар-башкорт сул социалист революционерлары тактика мәсьәләсендә эчендә эшләнгән халыкның хосусиятләре, төп аерым ихтыяҗлары игътибарга алыну лазем дип белсә дә, без бу хосусиятләрнең нигезен диндә түгел, бәлки милләттә, икенче төрле әйтсәк, татарлык, башкортлык, сартлык, казакълыкта күрә, шуңа таянып, тактика тота идек. Вахитов иптәш исә бөтен дөнья мөселман ярлыларын бергә җыярга, аерым бер юл белән интернационалга, социализмга илтү өчен, барына бер тактика хакында уйлый иде.

<…>

Ләкин Вахитовның «панисламистлыгы» бөтен дөнья мөселманының эшчесендә, крәстиянендә гомуми уртак хосусиятләр күреп, шулар буенча аерым тактика тотуында гына түгел, ул, югарыда әйткәнемчә, социализм нәтиҗәсендә төзеләчәк гомуми мәдәнияттә борынгы гарәп мәдәниятенең зур тәэсире булачагына ышана[1]; ул, гарәп мәдәниятенең үз тәгъбиренчә, Гарәбстанның алтынлы ком сахраларыннан мөкаддәс Ганг елгаларынача җәелгән борынгы ислам мәдәниятенең гашыйкларыннан иде. Хыялы белән шуны әллә нинди бөек, матур, тирән хикмәтле бер мәдәният итеп күрә, шуның бөтенләйгә югалуын башына сыйдыра алмый, киләчәктә үзенең бөтен нуры, хикмәте, матурлыгы белән инсаният дөньясын яктыртачак дип иман китерә иде.

## III

Мулланур Вахитов минем хыялыма болытланып, күк күкрәп торган вакытта ялтырап үткән яшен кебек булып сурәтләнеп калды.

1905 елда безнең халык эчендә гомуми революция мәйданында аның исеме ишетелмәде. Чөнки ул вакыт мәктәптә укучы булган. Революция дулкыны басылып, эш башына Столыпин килеп утыргач[2], бишенче-алтынчы елларда сулдан-сул, кызылдан-кызыл булып йөргән «таңчылар», «уралчылар»ымыз, Кызыл байракка хыянәт итеп, буржуазиягә сатылдылар. Кичәге социалист-революционер Гаяз Исхаков, Туктаров, Шакир Мөхәммәдъяров, Сәгыйть Рәмиевләр, социал-демократ Гомәр Терегулов, Ибниямин Әхтәмовлар[3], Столыпинның ачулы йөзен күрү белән, социализмнан ваз кичтеләр, эшче белән крәстиянгә арка биреп, байлар чанасына утырдылар. <…>

Шуның нәтиҗәсендә безнең арада, оешып, социализм юлында эшләү бетте.

Социализм юлыннан кайтмаган революционерлар өчен бердәнбер чара гомуми рус оешмаларына кушылу, шулар белән бергә астыртын хезмәттә булу гына калды.

Бөтен җаны, йөрәге белән революционер, социалист Вахитов өчен, әлбәттә, бердәнбер эш мәйданы да шул булган. Ул шунда идән астына төшеп, гомуми дөньяга исеме чыга алмаган.

Мин аны беренче мәртәбә Бөтенрусия мөселманнарының икенче корылтаенда Казанда очраттым[4].

Корылтайда татар буржуазия һәм аның ялчылары белән зур сугыш барды. Безнең зур ук фракциямез булып, җиргә социализация, федерация, тупраклы мохтарият (Идел-Урал буенда бер җөмһүрият) кебек мәсьәләләрне үткәрү безнең программада иде. Мулланур ул вакыт, гомуми социал-демократлар рухынча барып, бу өч маддәнең һичберсендә безгә кушыла алмады. Съездның бөтен сул канаты – эшчесе, крәстияне, солдаты безнең белән булса да, ул бераз каршырак китте. Ләкин бунда аны саташтырган нәрсә – партияләренең гомуми мәҗбүри программасы, аның җиргә социализациягә дә, федерация һәм тупраклы мохтарияткә (аерым милли җөмһүриятләргә) дә каршы булуы иде дип уйлыйм. Чөнки соңыннан ул боларның һәммәсен, бигрәк тә соңгысын кабул итеп, һәр җирдә шуның өчен янып көрәшә торган булды.

Мулланур белән икенче очрашуым Петербургта мәшһүр Смольный институтында булды[5]. Бунда хатирә язмыйм. Мулланурны аңлатуга ярдәм булыр дип, тик бер кисәген әйтеп үтәргә мәҗбүрмен.

<…>

Учредилка куылгач, мөселман вәкилләренең киңәш мәҗлесләре булды. Беренче мәсьәлә «инде ни эшләргә?» хакында иде. Мин бер фикерне тәкрар иттем: Учредилкадан ваз кичәргә, Советның Мәркәз башкарма комитетына, аннан соң шул көннәрдә булачак Бөтенрусия советларының өченче съездына керергә. Ул арада Сталин, Пестковскийлар белән сөйләшеп, Мәркәз мөселман комиссариаты төзү, «Ярлы халык»ны бетереп, зур, җитди бер гәзитә кую хакында ризалык-фикер алынган, тик шуны гамәлгә куеп җибәрәсе бар иде. Мөселман фракциясенә мин моны рәсми рәвештә аңлаттым. Учредилкадан ваз кичеп, съездга, Советка керү, иң якын гамәли эш итеп мөселман фракциясе исеменнән Мөселман комиссариаты төзү дип тәкъдим керттем. Бу хакта өч көн талаш-көрәш булды.

Мөселман фракциясенең буңа риза булмаячагы мәгълүм булгач, Мулланур белән Шәриф Манатовның[6] киләчәк хәбәре ирешкәнгә, комиссариатны төзеп җибәрү эшен алар килгәнче кичектерергә дигән тәкъдим белән Сталинны күрергә дип, Смольный институтка кереп барсам, Шәриф белән Мулланурга очрадым.

<…>

Мулланур Вахитов «Бөтенрусия мөселман эшләре комиссариаты» дип төзү фикерен яклый. Башкорт вәкиле исә, башкорт исеме кермәсә, мин китәм, ди. Киләчәктә ни булыр, ләкин хәзергә, бергә эшләүне күрсәтү өчен, һич булмаса, «Татар-башкорт» дип атарга күнмәкче.

Вахитов иптәш тә, бу ляихә үтсә, мин эшләмим, минем игътикадыма каршы була, ди.

Эшнең бозылу ихтималын күреп, мин компромисс тәкъдим иттем.

«Бөтенрусия мөселманы»да түгел, чөнки аңа безнең хокукымыз юк. Без Идел-Уралдан сайланган. Шул җир халкы безне

белә, ышана. Шулай ук «Татар-башкорт та түгел», бәлки «Эчке Русия һәм Сибирия мөселман эшләре комиссариаты» дип аталырга, ляихәмез шуның буенча төзелергә тиешле. Буңа һәр ике як риза булды.

Табигый, Мулланурны комиссариатның рәисе итеп сайладык. Бу хакта арамызда ике сүз булмады. Декретта да шулай чыкты. Монда минем өчен мөһим нокта – Вахитов иптәшнең «Бөтенрусия мөселманы...» дип алуы, шул үтмәгәч, бөтен эшне ташлар мәртәбәгә җитүедер.

Бу аның тактика мәсьәләсен ачачак нокталардан бере иде.

## IV

Безнең дөньямыз хамелеоннар белән, җил кайдан иссә, шул уңгайга ава торган кызганыч бәндәләр белән тулы. Шул арада Мулланур Вахитов кебек нык иманлы, үзе ышанган юлда һичнәрсәгә, һичбер манигъка карамастан барырга тырышучы, үз идеалы юлында бөтен көче белән көрәшүче егетләрне күрү – җанга рәхәт, күңелгә ышаныч бирә торган хәлләрдәндер.

Мулланурның тик ел ярымлык хәяты, хезмәте минем күз алдымда булды. Шуның бик күп булса дүрт-биш аен бергә үткәрдем. Ләкин шул аз вакыт аның табигатен, кемлеген бөтенләй ачып бирде.

Мулланур һәрнәрсәдән элек революционер иде. Иске тормышны бөтен куәте илә җимереп, шул юлда ялкынлап бара торган, җимерү белән генә тукталмыйча, аның урынына яңа якты тормыш төзүгә омтыла торган, шул юлда мәгълүм идеал иясе булган революционер иде. Ул, шөбһәсез, талантлы организатор иде. Башта Мөселман социалистлар комитетында, аннан соң Мөселман комиссариатларында, Татар-башкорт җөмһүриятендә ул үзенең бу талантын сукырлар да күрерлек дәрәҗәдә ачып бирде.

Аның хатиблыгы, ачык, ялкынлы, тирән мәгънәле, шагыйранә сөйләүче оратор икәнлеге хакында язып торырга хаҗәт бармы?!

---

*Хатиблыгы* – яхшы оратор икәнлеге.

Пролетариат хадимнәренең зур бер трагедиясе бар: алар, фәкыйрь халык эченнән чыгып, тамак туйдыру өчен бик яшьли эшкә керешеп, укудан мәхрүм калырга мәҗбүр булалар.

Мулланур Вахитов бу хакта да аерым урын тота иде.

Миңа Русия мөселманнарының һәммә хадимнәре белән диярлек очрашырга, утырырга тугры килде. Ләкин икътисади, иҗтимагый гыйлемнәрдә Мулланур Вахитов дәрәҗәсендә үз кешесе булган һичкемне мин күрә алмадым.

<…>

Иҗтимагый революция аның кашында сәяси, икътисади көрәш кенә түгел, гыйльми, әдәби, мәдәни хәзинәләр өчен дә көрәш, шуларны кулда итүгә омтылу иде. Шулар белән бергә, Мулланурда тормышның тамыр тибүен сизү бар, үткен, җитез аңлап алып, шуңа бөтен җаны белән бирелеп, тиз арада бөтен дөньяга каршы көрәш башлау хосусияте бар иде. Петербурга барган вакытта, комиссариат төзү дигән фикер аңарда, шөбһәсез, юк иде. Башта, әйткәч тә, ул бик артык әһәмият бирмәде. Бераз сөйләшеп, мәсьәләнең кая барганын сизеп алу белән, ул шул фикер утында яна, шуның өчен дөнья куптарып эшли башлый һәм эшли, аякка бастыра.

Шулай ук Татар-башкорт җөмһүрияте дә.

Федерация, тупраклы мохтарият хакында Русия мөселманы эчендә байтактан көрәш барды. Безнең пролетариат та буны тели иде. Вахитов бу көрәшләрдән читтәрәк, әйтик, бераз каршы, бераз шөбһә белән карый иде. Петербургта чакта да аның башында бу фикергә артык әһәмият бирү сизелмәде. Казанда мәгълүм март вакыйгаләры булды. Болак җөмһүриятен төзеп, халыкның башын әйләндерә башладылар. Без хөкүмәт белән Мәскәүгә күчкәч, бу хактагы хәбәрләр тагы көчәйде.

Безнең башта күптән йөреп, аның өчен күптән көрәшеп килгән кешеләр комиссариатта буны яңадан кузгаттык. Кулдагы материал буенча сызыкны сыздык. Вахитов карышмас кебек күренде. Ләкин монда берәр яңлышу юкмы икән дигән кебек, бер шөбһә белән, аз әһәмият белән карый иде.

---

*Хадимнәренең* – хезмәтчеләренең.

Уйлаган саен, сөйләшкән саен, ул мәсьәләгә керде, Сталиннан да кичерелде. Берничә көн үтмәде, Мулланур иптәш Вахитов үзенең табигатендә булган бөтен ялкыны, уты белән бу җөмһүриятне яклаучы, аның өчен бөтен көче белән көрәшүче булып китте.

Шул дәрәҗәгә җитте ки, ул буңа каршы баручыларның күңел сафлыгында шөбһә итә торган булды.

Ләкин пролетариат мәнфәгатенә, социализм нигезләренә каршы булган эшләрнең һичбере белән һичкем, теләсә ничек кенә сөйләсә дә, аны ризалата, ялкынландыра алмаячак иде.

Ул үзенең бөтен эшләренең, бөтен уйлавының төбенә нигез ташы итеп социализм әсасен салып куйган. Рухы, йөрәге шуның белән тәрбияләнгән; шул дәрәҗәдә ки, ул башкача уйлый да, үлчи дә алмый иде.

Дөньяның һәммә эшләренә, гыйльми, фәлсәфи мәсьәләләрнең һәммәсенә, һәммә оешмаларга ул тик шул ноктадан, шул күз белән карый, тик шул иман хәзинәсеннән ут ала, ялкын ала иде.

Вахитов иптәшнең Февраль революциясенә чаклы безнең киң җәмагать хезмәте дөньясына чыкмавында, исеме, эше күренмәвендә иң башлыча сәбәп, – шөбһәсез, аның шул һәммә нәрсәгә социализм ноктасыннан каравы, һәммә оешманы, һәммә хезмәтне тик шул ноктадан үлчәве, тик шуның буенча тәкъдир кылуы, һәммә уйларына, һәммә эшләренә нигез ташы итеп иҗтимагый революцияне алуыдыр.

* * *

Галим, хатиб, организатор, революционер булуы өстенә, аның чын мәгънәсе белән власть-хакимият кешесе икәнен дә әйтми үтәргә мөмкин түгел. Ул властьне гадәттән тыш ярата, шуны куя белә, үзен власть итеп тота ала. Большевизм байрагы астына яшеренгән кайбер шовинист яки сатлык татар-башкорт, әрмән, яһүд җыланнарының: «ул – панисламист» дип, «фәлән» дип, яфрак астыннан шыелдавына карамастан, мәркәз власть тирәсендә сүзен җиңел үткәрерлек игътибары бар иде.

<…>

Вахитов татар-башкортның яки Русия мөселманнарының гына түгел, бөтен ислам Шәркының бөек революционеры иде. Исән чагында Шәрыкта, революция мәсьәләсенә тиешенчә әһәмият бирелмәде. Ул тик үзенең бетмәс-төкәнмәс революционерлык куәте белән Шәрыкка әһәмият бирдерергә, Шәрыкта революция ялкыны уятырга тырыша иде; безнең арамыздагы һәммә эшләрен Шәрыкта булачак бөек революция янгынын хәзерләү, шуңа юл ачу дип карый иде.

Революциямезнең хәзерге агышы исә Вахитовның бөтенләй яңлыш юлда булмаганлыгын күрсәтте.

## ТАРИХИ КЫҢГЫРАУ ӨЗЕЛДЕ
*(Рәшид бабай үлде)*

### I

Татарның уйгану күгендә беренче йолдызлары сүнәләр. Мәдәни, әдәби хәрәкәтне башлаган беренче буын кешеләре берәм-берәм арадан югалалар.

Уфаның карт социал-демократ большевик Җиһанша абзый Таһиров үлде. Ибраһим мирза Терегулов[1] үлде. Дәрдемәнд[2] үлде. Габдулла Буби[3] үлде. Инде соңгы хәбәрләр уйгану дәверенең иң нык уятучы тарихи кыңгыравыкларның көчлеләреннән Рәшид казыйның да вафатын белдерделәр[4].

Ул бик кызыклы карт иде. Шуның белән бергә, аның исеме, хезмәте татарның мәдәни тарихында, шөбһәсез, гомерлек урын алачак кешедер.

<…>

XIX йөзнең соңгы яртысында, бигрәк тә актыккы чирегендә, Европада финансовый капитал тулып аша, шуның нәтиҗәсендә Гареб империализмы Шәрыкның тән тамырларындагы йөрәк каннарының актык тамчыларын суыра башлый. Шәрык бөтенләй бүленеп бетә, икътисади кысу чиктән аша. Шуның аркасында Нил, Босфор, Ганг, Евфрат Диҗлә[5] буйларында, бу каты газапка чыдаша алмый, бер кузгалу дәвере керә. Йә бетәргә, йә дошманның үз коралы белән коралланырга – Европа мәдә-

ниятен алырга кирәк, дигән бер матди мәнфәгать адәмнәрнең миләрен хәрәкәткә китерә. Бу хәрәкәтнең эчендә, алдында, һәммәгә күренеп кузгалучыларның алдагыларыннан мәшһүрләре Җамал Әфганилар[6], Мөхәммәд Габдеһләр[7], Мидхәт паша[8], Гаспринский[9] кебек затлар иде.

Безнең Волга, Урал буе да бу дәвердә рус, Европа капиталының һөҗүме астына төшеп, иске тормышы какшап, җимерелеп бара иде.

Мәрҗани, Курсавилар менә шул матди җимерелүнең алдагы бәрелүе белән уянган миләрнең мәгълүмрәге, көчлерәге иде[10].

XIX йөзнең соңгы унларында бу матди гамәл көчәя, шуның аркасында бунардан кузгалучы миләрнең, йөрәкләрнең саны да арта...

Рәшидләр, Ризалар, Баязитлар, Ибраһим Мирзалар, Габәшиләр[11], бер дәрәҗәгә кадәрле Бубилар – менә шул күбәеп уяна башлаучыларыннандыр.

Рәшид – менә шул дәвернең баласы, шул матди нигез белән хәрәкәткә килгән миләрнең берседер.

<…>

Бу беренче буын кешеләре динчеләр, исламчылар иде. Рәшид казый буны каләм белән генә түгел, гамәл белән дә күрсәтте. Бөтен гомерен әле Себердә, әле Уфада, Казанда, Питерда, Каһирәдә, Җәзаирдә, Истанбулда, Калькуттада, Багдадта йөреп, «Бетәбез, уяныгыз!» дип кычкырып үткәрде[12].

Аның каршында «мөселманнар бер милләт» булган кебек, «кяфер дә –милләт вахидә» диде[13].

Ул менә шул ике «милләт»не сугыштыра, Европа «христиан»нарына, бигрәк тә Англия миссионерларына, «ислам»ны изгән өчен, мәңгелек дошманлык саклый иде.

Аның тарафыннан язылган рәддияләр бервакыт татар мәдрәсә галәмендә җилем басма белән таратылып, ялкын белән укылды, моны бүлеп сакланды...

<…>

---

*Рәддияләр* – кире кагу, юкка чыгарулар.

Әсәрләрендәге икенче бер гомуми рух – дин исеменнән мәдәнияткә каршы баручыларны тәнкыйтьтер. Бу да шул гомуми ислам шәркы кузгалышының әфгани гаребтә шуларның татарча да яңгыравы гына иде. Мусалар, Зыялар, Бубилар моны дәвам иттерделәр[14].

Картның әсәрләрендә өченче бер нокта «динсез, милләтсез» малайларга һөҗүм иде. Бишенче ел хакында Фуад – Гаяз компаниясе[15], «социалист» булган булып, уңга да, сулга да һәр чат башында урамча, малайларча дин сүгеп, милләт сүгеп йөри башлагач, Рәшид казый байтак еллар «таң»чы малайларны сүкте. Сез хулиганнар, сез шарлатаннар, ди иде.

IV

Рәшиднең беренче әсәре «Чулпан йолдызы» бөтенләй Романовлар хөкүмәтен, аның агенты мөфтине сүгү рухында барганга, Русиядә басыла алмады. Төркиядә нәшер кылынып, Русиягә яшерен таралды...[16]

Моннан егерме еллар элек бабайның Русиядә «Миръат – көзге»ләре чыга башлый[17].

1905 елларгача Рәшиднең бу әсәрләре яшьләр өчен, яңа фикерлеләр «Инҗил – Коръән» иде. Ике җәдид очраша:

– Рәшид әфәнденең сигезенче «Миръат»ы чыккан икән. Кайдан кулга төшерәсе иде? – дип сөйләшүләр бер мода кебек иде.

«Миръат» барлыгы егерме ике китап чыкты. Баштагы 17 сендә үзенчә революционерлар искене җимерергә, яңаны төзергә чакыралар. Соңгылары бик чамадан тыш алга китүчеләрне бераз авызлыклау, тыю рухында чыктылар.

Бабайның «Өлфәт» гәзитәсе[18] әүвәлге бу елында шундый зур авторитетлы булды ки, һичбер татар гәзитәсе алай булганы юк.

Кайбер мәдрәсәгә, бу гәзитә буларак, икешәр йөз нөсхә алына, чөнки һәрбер яңа фикерле егет аны кат-кат укый гына түгел, бөти ясап, төпләп куя. Ләкин бу озакка бармады. Карт, искене җимереп, яңага өстерәүдән туктала. Агымны туктатырга, бик артык алга китмәскә, реакциягә чыга.

Шуның белән үзенең бер дәверен бетерә. Яшьләр каршында югала.

V

Бабаның мөһим әсәрләреннән берсе – «Автономия яки мохтарият» дигән бер кечкенә рисаләседер[19]. Бу китапта Рәшид әфәнде Төркестан, Казакъстан, Азәрбайҗан өлкәләренә һәм татарларга автономия алу мәсьәләсен кузгата.

1906–1907 елларда чыккан бу кечкенә китап ул заманда татар милләтчеләре тарафыннан көлке белән каршы алынды.

«Вакыт»та Фатих Кәрими бу хакта мәкалә язды:

– Безгә, – ди, – нинди дә булса автономия-мохтарият мәсьәләсен кузгату ахмаклык булачак... Үзебез сорау түгел, көчләп бирсәләр алыргамы-юкмы? Чөнки бездә мәдәни көч юк. Менә мәсьәлә кайда, – диде.

Аннан соң 1917 ел Уфада «Ирек» гәзитәсендә картның Швейцариядәге кайдандыр язылган бер мәктүбе табылды. Ул анда федерация, автономияне яклый иде.

VI

Октябрьдән соң безнең ахмак милләтчеләребез «чех, Колчак» дип, татар- башкорт егетләрен аттырып йөрделәр. Әле хәзер дә ул әбүҗәһилләрнең калдыклары Париж банкирларының бусагасында рус монархлары койрыгына тагылып йөриләр. Ул вакыт Рәшид баба исә Русиягә кайтты да Европа финансовый капиталына каршы Шәрыкны кузгатуда революциядән файдалану чараларын эзләп йөрде, бичара!!!

Без беләбез: карт коммунизм кешесе түгел, шулай ук Антантаны җимерүдән артыкка бара алмый ул. Ләкин буржуазиягә үзен сатмаган бер ихласи дәрвиш булганга, аның Шәрыкны коткару юлында тырышуы онытылмаячактыр.

<…>

Ул – бер кыңгыравык!!! Туктамый шалтырата торган бер кыңгыравык иде!.. Каты йоклаган кешеләрне уятуда мондый бер кыңгыравыкларның роле бу дәвердә зур була... Болар: «Уяныгыз», – дип, азан кычкырып йөриләр.

Картның хәзерге язуларын яки элеккеге әсәрләрен хәзер алып уку һичкемгә гыйльми-фикри азык була алмас. Шуның белән бергә, ул тынмас йөрәкле баба Шәрыкның, бигрәк тә татарның, әдәби, мәдәни хәрәкәте тарихында мәгълүм кадерле бер урын алачак, буны ачык аңлатучы бер мисал лазем.

«Бәдәвам», «Тәкый гаҗәб», «Бүз егет», «Кызыл алма» китаплары[20] кайчандыр үз дәверләрендә һәркем өчен, чыннан да, кирәкле, файдалы, кадерле әсәрләр иде.

«Фәзаилеш-шөһүр» белән «Мөһиммәте мөслимин» дә шөбһәсез үз заманнарында һәркемгә кыйммәтле җан азыгы булдылар[21].

Бу әсәрләрне «чүп» дип кагып ташлау – ахмаклык. Шулай ук мәгълүм бер дәвердә «Шәкерт белән студент», «Мәгыйшәт», «Өч хатын», «Сәлимә», «Мулла бабай», «Тормышмы бу?» кебек әдәби әсәрләр дә үз заманнарында фикер-мәгънә үсүгә, ачылырга ярдәм иттеләр[22]. Ләкин яңа, яшь буын кешеләреннән инде бу үткән теге дәвернең әсәрләреннән бер гыйльми-фикри файда күрим дип, кем боларны ачып карар?..

«Бәдәвам»ны укучы карчыклар бетмәгән кебек, бәлки «Тормышмы бу?»дан мәгънә эзләүче карт хәлфәләр әле дә анда-монда бардыр...

Ләкин шулай булса да, ул «Бәдәвам»нар, «Кызыл алма»лар, «Шәкерт абый»лар, «Мулла бабай»лар, «Мәгыйшәт»ләр тарихи бер дәвернең тарихи җимешләре булып сакланалар... Хрестоматияләргә кертелеп, балага, шәкерткә өйрәтеләләр. Шулай үткән эшләрне таныштыралар. Менә шуның кебек Рәшид бабай мәгълүм бер тарихи дәвернең, үткән баскычның бер көрәшчесе – кадимнән җәдидкә чыгуда алга өстерәүче уларак урын алачак.

<…>

# КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ВАФАТЫНА ЕГЕРМЕ ЕЛ ТУЛА

<…>

Каюм Насыйри кем? Безнең тарихта урыны кайда? Кайсы баскычта? Аның хезмәтләренең әһәмияте тик тарихи гынамы, тик кыйммәтле архив материалы гынамы, яки ул калдырган мирас эчендә хәзерге көндә дә гамәли бер файдага яраячак нәрсәләр бармы?

XIX йөзнең яртысында, бигрәк тә ахыргы чигендә рус-Европа капиталының дулкыны тәэсире белән безнең Идел-Урал буйларында борынгы Шәрык тормышы җимерелә, җиңелә башлый. Яшәү өчен, яңа техника алдында һәлак булмасын өчен, безнең татар халкында бер яңару мәҗбүрияте туа. Борынгы Шәрык ысулларын ташлап, Европаның техникасы, гыйлеме, фикере белән кораллану кирәклеге сизелә, шул юлда бер кузгалу баш күтәрә.

Менә шул иҗтимагый-тарихи, матди-мәҗбүри кузгалыш ул заманның сизгеррәк миләрен, сизгеррәк йөрәкләрен хәрәкәткә китерә – бездә уйгану көннәре башлана.

Каюм Насыйри – менә безнең тарихның шул көннәрендә, шул тарихи баскычта уйганган миләрнең берсе, беренчесе һәм иң мөһим бер бабта шул уйгану-яңару эмәлләренә хезмәт итүчеләрнең зурыдыр.

## III

Ул заманда уйганып, эшкә, яңа тормыш өчен көрәшкә башлаучыларның төрлесе төрле мәсьәләдән тотынды.

Дин мөтәхассыйслары Коръән, хәдис, ислам тарихы юлы белән шул ноктадан хәрәкәт иттеләр; болардагы уйгану динне яңача, азат, саф хәленчә аңлау рәвешендә булды. Мәшһүрләре – Курсави, Мәрҗани[1].

---

*Бабта* – биредә: тармакта, өлкәдә.

*Мөтәхассыйслары* – белгечләре, галимнәре.

*Хәдис* – пәйгамбәрләрнең әйткән сүзләре.

Шигъри таланты булганнар бу уйгану әмәлләрен үзләренең ачы кайгылы, искегә тәнкыйть белән тулы җырлар аркылы гәүдәләндерделәр. (1895 елда үтерелгән Акменла[2] – боларның мәшһүредер.)

Муса Акъегетзадә, Заһир Бигиев[3] кебек әдәби көчләре булганнары хикәяләр, романнар аркылы бу хәрәкәткә таба юл салдылар. (Болар – әдәбияты нәфисәнең беренче сандугачларыдыр.) Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов[4] шикелле хадимнәр бу хәрәкәттә тарихны корал кылдылар, тарихны тергезү юлы белән эш башладылар, тарих китаплары яздылар.

Менә болар һәммәсе – бер замандарак яшәгән һәм шул кадим Шәрык торгынлыгына каршы көрәш башлаган революционерлардыр.

Шул ук заманнарда икенче бер куәт бөтенләй башка бер бабта, ләкин үз заманындагы уянучылар белән бер үк кәгъбәгә таба юнәлгән икенче бер хезмәт башлады. Бу баб, бу мәсьәлә, бу хезмәт, татар теле, татарның имлясы, сарыфы, нәхүе, татарның халык әдәбияты, татарның лөгатьләре кебек, гаммәнең яңа тормышка баруында иң көчле, иң мөһим бер коралны эшләп юлга салудан гыйбарәт иде.

Каюм Насыйриның тарихи урыны менә шул уйгану көннәре эчендә кадим Шәрыкка каршы көрәш белән, яңа әмәлләргә таба бару өчен мәйданга чыккан ул заманның (тәгъбир яраса) революционерлары арасындадыр.

<…>

Каюм Насыйри бөтен әсәрләрендә, шул җөмләдән календарьларында да, татар теле хакында күптөрле тикшерүләр яза. Бу хакта аерым рәвештә тукталган әсәре «Әнмүзәҗ»[5] исемендәдер.

Баба[6] бу әсәрен татарның фонетикасын, хәрефләрен тикшерү белән башлый. Моннан утыз еллар элек чыккан бу әсәр имля бабында үз телебездә беренче тикшерү булып, шул заман-

---

*Кәгъбәгә* – биредә: табынган юнәлешкә, идеягә.

*Гаммәнең* – массаның, гади халыкның.

да ук татар имлясын тәнкыйть кыла да, үз тарафыннан төзәтү ляихәсе тәкъдим итәдер.

<…>

Бу көнге кебек хәтеремдә: 1910 елларда, «Татар сарыфы», «Татар нәхүе», «Татар имлясы»[7] язган заманнарымда, минем алдымда Өмидбаевларның, Һ. Максуди, Х. Кәбүтәри, Нугайбәк кебек үз телебездәге сарыф-нәхүләр[8], Остроумов, Г. Задә, Наливкин кебек чит мөстәшрикъләрнең хезмәтләре[9] булганы хәлдә, боларның һичбере татар теленең сарыфы-нәхүе хасиятләрен эзләп табуда Насыйриныкы чаклы ярдәм итә алмадылар.

Әле хәзерге көндә дә, ул әсәрләрне яңадан төзәткән саен, татар телен, сарыф-нәхү, бәлягать ягыннан тикшерә башлаган саен, без һаман Каюм Насыйридан котыла алмыйбыз, аңардан һаман файда итәбез.

<…>

Бездә уйгану көннәрендә һичберәү ачыктан-ачык «татар» дип мәйданга чыга алмады, һичкем «татар халкын тарих мәйданына туып килгән аерым бөтен бер коллектив, бер җәмгыять» дип карарга батырлык итмәде. Дөрест, Мәрҗани үзенең «Мөстәфад»ында «татар» дип атый, тарихны шуңа карата «татар түгелбез» диючеләрдән көлә:

– Ахмак, син, татар булмыйча, кем соң? Әллә син чуваш яки чирмешме? – дип әйтеп китә.

Ләкин Мәрҗани үзенең бу нигезен гамәлләрендә кискен бер маддә итеп алып бармый. Ул замандагы башка хадимнәребез, шулай ук аннан соң килүчеләрнең дә күбе һәртөрле «панлык, иттихадчылык» байраклары белән газапландылар.

Менә бу мәсьәләдә Каюм Насыйри бөтенләй ялгыз тора. Ул безне ачыктан-ачык «татар» дип, телебезне «татар теле» дип атый. (Бу хакта минем «Шура»да 1910 елның 8 нче номерында «Без – татармыз» дигән мәкаләгә бак[10].) Атап кына калмый. Татар җәмәгатен башка җирдәге мөселманнардан, башка

---

*Ляихәсе* – проекты.

*Маддә* – пункт.

җирдәге төрек кабиләләреннән аерым, үзенә башка бер мәдәният, бер әдәбият тудыручы коллектив, бер җәмәгать дип карый да, халык әдәбиятын җыюда булсын, имля, сарыф-нәхү, бәлягать, лөгать язуда булсын, төрле «пан»лык хыялларын бер якка ташлап, татарны тикшерә. (Монда «татар» сүзенә: Казан татары, Касыйм татары, нугай, Алатыр, башкорт, типтәр, мишәр һәм төмән – барлыгы сигез кабилә керә. Чөнки соңгы ике йөз елда болар әдәби, мәдәни, сәяси, икътисади хәлләр буенча бергә оешканнар.) <…>

# ИСКӘРМӘЛӘРҺӘМ АҢЛАТМАЛАР

**Татар теле һәм татарча язу хакында бер-ике сүз**. «Йолдыз» газетасының 1910 ел, 30 март (521 нче) санында «Габди» имзасы белән басылган.

[1] *«Хатыннар эше» дигән бер әкиятнең...* – «Хатыннар эше» исемле әлеге әсәр, асылда, ике пәрдәле комедиядән гыйбарәт. Ул «Театру мәҗмугасы» дигән сериядә 10 нчы китап булып нәшер ителгән (Казан, 1910 ел, Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе нәшрияты, И.Н. Харитонов матбагасы, 48 бит). Г. Ибраһимов «бер әкият» дип комедиянең эчтәлеге сай, әһәмиятсез булуга ишарә итә.

[2] *Апанай* – журналист һәм музыкант Вәли Апанаев (1889–1922) (басманың тышлык, форзац һәм титул битләрендә «В. Апанай» дип язылган).

[3] *«Татарчалаштыручысы», «татарчага әйләндерүче» кеби ямьсез сүзләр урынына...* – Биредә Г. Ибраһимов тарафыннан әдәби телнең лексик, стилистик чараларын ничек баету, сайлап алу критерийларына кагылышлы мәсьәлә күтәрелә. Чыннан да, кыскалык, матурлык, ыспайлык ягыннан әлеге тәгъбирләр Г. Ибраһимов тәкъдим иткән «мөтәрҗим»гә караганда калыша кебек (артык *-сы* өстәлү дә әйтелешне авырайта). Ләкин әдәби тел ресурсларында әлеге сүзләрнең дә үз мәгънәви даирәсе бар. Эш шунда ки, ул пьесаның сюжеты чит телдән алынган, ләкин, гадәттәгечә, «тәрҗемә ителмәгән», ә бәлки татар тормышына якынайтып эшкәртелгән (хәтта персонаж исемнәре дә һәммәсе татарча). Шуңа күрә бу очракта «мөтәрҗим» сүзе әлеге китапка карата туры килеп җитми.

[4] «*Мөтәрҗим» сүзе, асылда, гарәпчә булса да, ул инде... татарлашкан...* – Иске татар әдәби телендә *мөтәрҗим* – язма профессиональ-иҗади тәрҗемә итүче, ә *телмач, тылмач, тәрҗеман* сүзләре *телдән тәрҗемә итүче* мәгънәсендә йөргән һәм урнашкан була. Яңа әдәби телдә *мөтәрҗим* сүзе актив кулланыштан чыгып пассивлаша бара, аның урынына *тәрҗемәче* сүзе ясалып, югарыдагы мәгънәләрдә кабул ителә. Шулай итеп, Г. Ибраһимовның «мөтәрҗим» хакындагы фикере билгеле бер чорга карата гына хаклы.

[5] *...Мәҗбүрият булмаган урыннарда тәкәллефан чит лөгатьне кертмәү...* – Әдәби телдә чит сүзләр куллануның Г. Ибраһимов тарафыннан тәкъдим ителгән мәгънәви, терминологик һәм стилистик шартлары, билгеләре хәзерге көндә дә кулланырга яраклы.

[6] *Гаяз әфәнде* – Татар әдәбиятының классик язучысы, драматург, публицист һәм сәясәт эшлеклесе, татар милли азатлык хәрәкәте лидеры

Гаяз Гыйләҗетдин улы Исхаков (Гаяз Исхакый) (1878–1954) күздә тотыла.

[7] *«Шура» мөҗәлләдәсе...* – «Шура» журналы. Алтын приискалары хуҗалары миллионер һәм наширләр: Шакир Рәмиев һәм аның энесе Закир Рәмиев (шагыйрь Дәрдемәнд) тарафыннан Риза Фәхреддинов мөхәррирлегендә Оренбургта 1908–1917 еллар арасында чыккан гыйльми-әдәби вә иҗтимагый-сәяси, күп төрле рубрикаларга бүленгән гаҗәп бай эчтәлекле журнал.

**Әдәбият *(еллык хисап урынында).*** «Йолдыз» газетасының 1912 елгы 15 гыйнвар (780 нче) һәм 18 гыйнвар (783 нче) санында «Габди» имзасы белән басылган (еллык матбугат күзәтүе). Мәкаләнең азагында «ахыры бар» диелсә дә очрамады.

[1] *«Идел»... гарәп хәрефен... ташлап, аның урынына латинны алырга тиеш, диде.* – Сәгыйть Рәмиевнең «Идел»нең 1911 елгы 3 нче (июнь) санында («Мөхәммәдшакир вә Мөхәммәдзакир Рәмиевләр тарафыннан иҗад вә тәрсим улынган аеры-аеры хәрефләргә бер нәзар») һәм 5 июльдә («Безгә тәкъдил вә исляхе хәреф кенә кирәкме? Әллә бөтенләй тәбдил үк кирәкме?») басылган мәкаләләре күздә тотыла. Анда автор (С. Рәмиев) гарәп алфавитына нигезләнгән татар язуын һәм имлясын тәнкыйть итә, латин алфавитына нигезләнгән татар язуы үрнәкләрен күрсәтә.

[2] *...борадәран Рәмиевләр...* – Шакир (Мөхәммәтшакир) һәм Закир (Мөхәммәтзакир) Рәмиевләр, Уралдагы алтын приискалары хуҗалары, миллионерлар; Оренбург шәһәрендәге матбага хуҗалары, «Вакыт» газетасы һәм «Шура» журналының наширләре буларак мәшһүр кешеләр. Бертуганнардан Закир Мөхәммәтсадыйк улы Рәмиев (1859–1921) исә күбрәк әдәбият-поэзия һәм матбугат эшләре белән шөгыльләнгән, матбугатта «Дәрдемәнд» псевдонимы белән танылган.

[3] *...«Айры хәрефләр» атлы яңа хәрефләр чыгардылар...* – Бертуган Рәмиевләр «Хатте тәбагъәт, яхуд Айры хәрефләр» («Басма язу, яки Айры хәрефләр») исемле проект тәкъдим итүләре белән татар язма культурасы тарихында үзләренә лаеклы урын тоталар. Әлеге проект 1911 елда Оренбургта аерым китап булып басылып чыга.

[4] *...гәзитәләрдә берничә мәкалә илә генә калуы...* – Рәмиевләрнең «Хатте тәбагъәт...»е турында фикер алышулар җитәрлек була. Мәсәлән: Ә. Биктимеровның «Айры хәрефләр хакында бер-ике сүз» исемле рецензиясе (Шура, 1911, 16 нчы сан, 493–494 б.), «Матбага хәрефләремез хакында» (шунда ук, 12 нче сан, 494–497 б.), С. Рәмиев рецензиясе (Идел, 1911, 3 июнь) һ.б. Дөрес, бу проектның, Г. Ибраһимов әйтмешли, зур «тавыш куптара алмавы» да гаҗәп түгел. Чөнки ул традицион татар

язуыннан, гарәп хәрефеннән «бик ерак китмәк илә» шактый ераклашкан, аерылган булып чыга һәм практик кулланылышка кабул ителү мөмкинлеген, сәләтен-куәтен бер дә күрсәтми.

[5] *...Габделмәннан Рахманколый әфәнде... хәрефләрне бер шәкелгә калдыру хакында бераз маташып баккан икән.* – Габделмәннан Әхмәтҗан улы Рахманкулов (1858–1908). 1876–1890 елларда Мамадыш өязе Олы Шыңар авылы мәдрәсәсендә мөгаллим. 1890–1908 елларда Казанда «Борадәран Кәримовлар» типографиясендә конторщик, идарәче була. Җиңеләйтелгән татар хәрефләре проектының авторы. Бу турыда Г. Алпаров «Хәреф вә имлямыз» китабының керешендә бирелгән искәрмәдә болай ди: «Бу китапны язып бетереп басылырга биргәннән соң, моннан 4–5 еллар элек, «Матбагаи Кәримиянең мөдире мәрхүм Габделмәннан Рахманкулов дигән бер затның хәрефләремезне азайтырга тырышып йөргәне, шул чакта ук шул матбагада баш хәрефләрдән генә булган шрифтлар эшләгәне хакында мәгълүмат алдым. Ләкин ул чакта аңарга игътибар итүче булмаганга күрә, шул көе ятып калган, быел, ул мәсьәлә тагын күтәрелгәч, «Борадәран Кәримовлар» матбагасының идарәсе шул хәрефләрне яңадан эшләтеп чыгарган икән. Бу китап шул хәрефләр белән басылды. Г.А.» (Алпаров Г. Хәреф вә имлямыз. Казан, 1912; Алпаров Г. Х. Сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2008. 24 б.)

[6] *«Шура»да ике мөгаллим...* – Гыйбад Алпаров белән Вәсим Солтанов һәм аларның «Матбага хәрефләремез» (Шура, 1911, 12 нче сан) дигән мәкаләсе күздә тотыла.

[7] *...«Йолдыз» тарафыннан тәкъдим ителгән «Хатте касыйр»ны да зикер итмәле.* – Сүз «Йолдыз» газетасының нашире һәм баш мөхәррире Һ. Максуди проекты турында бара.

**Фәнни истыйляхлар *(Г. Батталның "Нәзарияте әдәбия"се мөнәсәбәте белән).*** «Аң» журналының 1913 елгы 24 нче (18 декабрь) санында (439–442 б.) «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган.

[1] *«Тәрҗеман»ның күп иснадларына карамыйча...* – Биредә Г. Ибраһимов 1883 елдан бирле И. Гаспринский наширлегендә Кырымда чыга башлаган «Тәрҗемән» газетасына бәя бирә. 1910 елларда татар матбугатында үзен «татарлык» тарафдары итеп күрсәткән Г. Ибраһимов «Тәрҗеман»ның «гомумтөрки тел» идеяләрен яклавын искә төшерә.

[2] *Гыймад Нугайбәк әфәнде* – Гыймад (Гыймадеддин) Шәрифҗан улы Нугайбәк (1881–1943); XX гасыр башында ул «Башлангыч» (Казан, 1911), «Төрлек» (Казан, 1911), «Үрнәкләр» (Казан, 1911) исемле китапларында күпчелек терминнарның татарча эквивалентын тәкъдим итә.

[3] *«Урал» гәзитәсе* – 1907 елда (4 гыйнвардан 27 апрельгә кадәр, барлыгы 31 сан) Оренбургта чыгарылган татарча беренче социал-демократик

рухтагы газета. Төп оештыручы һәм редакторы – Хөсәен Ямашев (1882–1912).

[4] *Хәнәфи әфәнде* – Казан университеты студенты Мөхәмметхәнәфи Кайбышев. Аның «Аң» журналында басылган язмаларының күбесе «М. Хәнәфи» исеме белән чыккан.

[5] *Пифагор* (гарәпчә: *Фисагорис;* грекча: *Тифагорис*) – б. э. к. VI гасырда яшәгән борынгы грек математигы, натурфилософ.

[6] *Буның хакимияте исә башка һәрнәрсәдән артык булырга тиеш.* – Монда Г. Ибрагимов әдәби тел һәм атамалар мәсьәләсендә гомумхалык теле өстенлек итәргә тиеш дигән фикерне куәтли. Шул ук вакытта Г. Ибраһимов төрле телләрдән алынмаларны файдалануын да инкяр итми.

[7] *Гобәйдулла Фәйзи әфәнде...* – «Г. Фәйзи» псевдонимы белән язган Гобәйдулла Буби (1871–1922). Монда аның «Җәгърафияи гомуми» исемле дәреслек китабы турында сүз бара. Автор үз китабында гарәби истыйляхларны бик мул куллана.

[8] *Харис Фәйзи әфәнденең «Ысуле җәгърафия»сендә...* – Педагог, нашир, журналист Харис Зариф улы Фәйзуллин-Чистапулиның (1871–1933) «Тәгълиме җәгърафия» исемле дәреслек китабы 1910 һәм 1911 елларда Казанда «Милләт» матбагасында нәшер ителгән.

[9] *Шөнаси әфәнде...* – Сүз педагог Габдулла Сабир улы Шөнаси (Ибраһимов) (1885–1938) турында бара. Ул татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен биология, физика, химия дәреслекләре төзеп бастырган. Аның бу төрекчәдән компиляция, ярым тәрҗемә дәреслекләре гарәп-фарсы һәм төрек атамалары белән тулы. Г. Шөнаси әзерләгән «Мохтәсары кимия» дәреслегенең беренче кисәге Казанда «Юл көтепханәсе»ндә 1910 елда, икенче кисәге исә 1912 елда Оренбургта «Вакыт» матбагасында басыла. Беренче кисәкнең кереш өлешендә түбәндәге аңлатма урнаштырылган: «Франциядә мөгаллимнәр җыелышы илә игъдад (хәзерләү) дәрәҗәсендә фән укыла торган мәктәпләр өчен тәртип ителгән «Кимия» китабы әсас тотылып тәрҗемә вә тәэлиф улынды (төзелде)».

[10] *Г. Мостафа әфәнденең «Һәндәсә»се ...* – Биредә педагог, татарча геометрия дәреслекләре авторы Г.М. Мостафинның рус теленнән тәрҗемә итеп басылган «Һәндәсә» (Казан: «Мәгариф» көтепханәсе, Ермолаев матбагасы, 1907. 83 б.) дигән дәреслек китабы турында сүз бара.

[11] «*Хөсәения»* – 1889 елда Оренбургта мәшһүр миллионер, сәүдәгәр, абыйлы-энеле Әхмәт (1837–1906) һәм Гани (1839–1902) Хөсәеновлар тарафыннан ачылган мәдрәсә. Яңа метод белән укытыла торган алдынгы мәдрәсәләрнең берсе итеп хисаплана. «Хөсәения»дә укулар башлыча түләүсез һәм интернат тибында оештырылган була: уку кирәк-яраклары,

ашау-эчү, кием-салым бөтенесе дә әлеге байлар хисабыннан. Шәкертләре арасында татар халкының күренекле шәхесләре: С. Рәмиев, Г. Алпаров, И. Кудашев-Ашказарский, М. Фәйзи, Ш. Усманов, М. Җәлил, А. Таһиров һ.б. бар.

[12] *«Касыймия»* – икенче төрле Күлбуе мәдрәсәсе, XVIII йөз ахырында Исхак Юнысов акчасына төзелгән. Башта Апанай мәчетендә, 1877 елдан Кабан күле буенда корылган махсус бинага урнаша. Бу мәдрәсәдә татар халкының күренекле шәхесләре З. Бигиев, М. Бигиев, Г. Баруди, Г. Исхакый һ.б. белем ала.

[13] «*Мөхәммәдия»* – 1882 елда Казанда күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Баруди (Галиев Галимҗан Мөхәммәдҗан улы, 1857–1921) нигез салган һәм җитәкчелек иткән мәдрәсә. Анда татар халкының күренекле шәхесләре укып чыга: Ф. Әмирхан, Г. Камал, М. Гафури, С. Сәйдәшев, К. Тинчурин һ.б.

[14] *Габбас Ибраһимов нәшер иткән «Хисап» китабы* – Нурәхмәт Вәлишов һәм Гыймадәтелислам Хәбировның «Хисап: кәсрегәчә бүленүе тиеш булган әгъдаде бәсита вә әгъдаде мөрәккәбәләрнең кавагыйде, мәсьәлә вә гадәти мисаллар илә» («Хисап: вакланмагача бүленүе тиеш булган гади саннарның һәм кушма саннарның кагыйдәләре») китабы. 1 нче җөзьэ. Казан: Нашире Габбас Ибраһимов, 1910 (татар телендә). Икенче басмасы Казанда Габбас Ибраһимов наширлегендә, И.Н. Харитонов типографиясендә 1915 елда дөнья күрә. Дәреслекнең икенче кисәге: Вәлишов Н., Хәбиров Г. «Хисап: кәсрегә (вакланмага) кадәр бүленүе тиеш булган саннар һәм үлчәүләр». 2 нче җөзьэ. Казан: И.Н. Харитонов типогр., 1910. 1915 елда китапның өченче басмасы чыга. Дәреслек китабының өченче кисәге: Вәлишов Н., Хәбиров Г. «Хисап: кәсре вә әгъшари (унарлы вакланмалар)» 3 нче җөзьэ. Казан: И.Н. Харитонов типогр., 1910 китаплары турында сүз бара.

[15] Өзекнең хәзерге телгә тәрҗемәсе: «Күп разрядлы (оялы) – берлек белән нульдән гыйбарәт саннарга бүлү өчен, бүленә торган санның уң ягыннан бүлүченең нульләре кадәр разряд [өтер белән] аерып алына да, бусы – вакланма, ә сул якта калганы бөтен була».

[16] *Ник... һәркем аңларлык мәртәбә туп-туры «билбау» димибез? Ник «Бәхре кәбир»? «Олы диңгез» генә түгел?* – Биредә китерелгән мисалларда Г. Ибраһимов төрле фәннәрдә кулланылган гарәп терминнарын татар телендәге эквивалентлары белән алмаштыру мөмкинлеге турында яза. Галим китергән мисалларның кайберләре терминология өлкәсендә ана телендәге эквивалентларның табу юлының бәхәсле нәтиҗәләргә китерү мөмкинлеген раслыйлар. Аеруча бу география фәнендә Җир шарының билгеле бер климат зонасын аңлаткан «пояс» сүзенә кагыла. Г. Ибраһимовның

риторик соравына караганда («Без ник үз телемезгә һәркем аңларлык мәртәбә туп-туры «билбау» димибез?), галим «билбау» сүзен географик термин итеп куллануны мәслихәт күрә, ләкин татар телендә «билбау» сүзен күчерелмә мәгънәдә (фәнни метафора буларак) куллану кабул ителмәде.

[17] *...Гарәбстан сүзләре белән тулыдыр.* – Югарыда анализланган һәм башка дәреслек китапларының теле һәм атамалары хәтта XIX гасырда университет типографиясендә чыккан кайбер дәреслекләргә караганда да гарәпчелек-төрекчелек белән ныграк сугарылган булуы мәгълүм. Эш шунда ки, җәдид мәктәп-мәдрәсәләре арта бару белән бергә, госманлы тәэсире дә кинәт көчәеп китә. Чөнки укытучы кадрлар әзерләү мәсьәләсе хәл ителмәгәнлектән, булачак мөгаллимнәр чит илдә (Төркия һәм Мисырда) укырга, шундагы фәнне, шундагы гыйлем телен, методикасын, дәреслекләрен алып кайтырга мәҗбүр булалар. Шактый дәреслекләр Казан, Уфа, Оренбургта нәшер ителүгә дә карамастан, алар бары тик тәрҗемә яисә компиляция генә булып чыгалар, 326 җитди, оригиналь дәреслекләр язарга әзерлекле педагоглар, бигрәк тә әдәби тел, фәнни стиль белән язу куәсе булган авторлар бик аз була, булганы да тел-әдәбият һәм тарих өлкәсендә иҗат итәләр, ә төгәл фәннәргә караган дәреслекләр «татарча» дип әйтүдән ерак торалар.

Хәлбуки матбугат һәм матур әдәбият стилендә исә бу вакыт иске татар теле дә, Гаспринскийның «гомумтөрек лисаны» да үзләренең позициясен югалталар, кызу темп белән яңа татар әдәби теленә әверелү процессы бара. Аңа диссонанс булып торган фән телен, дәреслекләр телен Г. Ибраһимов менә шуның өчен каты тәнкыйть астына ала һәм ничек булырга тиешлеген теоретик нигезләп күрсәтә.

[18] *...үз ана телләрен кулланырга... тырышып яталар.* – Бу чорда төрек телендә терминология эшләү, аны халык теленә якынайту берничә ысул белән алып барыла: 1) искергән гарәп-фарсы атамаларын алмаштыру; 2) халык сөйләшләреннән яраклы сүзләр эзләп табу, җыю, шуларны терминлаштыру; 3) Европа телләреннән (француз, инглиз, итальян) һәм бигрәк тә төрки телләрдән сүзләр, атамалар кабул итү; 4) иске төрки сүзләрне терминологик мәгънәләрдә «яңарту»; 5) сүз ясалышы ысулларын, чараларын актив эшкә җигеп, яңа атамалар (неологизмнар) ясау.

[19] *...бу мәсьәләләрне һичбер уйламыйча... гарәбизм сазына баталар?* – Монда Г. Ибраһимов, әзер сүз табу, тәрҗемә итү, ясау, беркадәр үзгәртеп алу һ. б. мөмкинлекләрне, чараларны эзләмичә, бары чит телдәге терминнарны (ана теленә һичбер җайлаштырмыйча) шул көе кабул итеп алу практикасын тәнкыйтьли.

[20] *Госманлылардан гыйбрәт алырга кирәк.* – Ягъни «аларның ачы тәҗрибәсеннән, алар ясаган хаталарны кабатламау» мәгънәсендә.

**«Альбом» мөнәсәбәте беләнбер-ике сүз**. 1915 елда «Аң» журналы бастырып чыгарган «Альбом (сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)»нда сүз башы, аңлатма итеп урнаштырылган. «1914, декабрь, Казан» дип куелган. Хезмәтнең дөньяга чыгу вакыты түбәндәге белдерүмөрәҗәгатьтән күренә: «“Аң” журналының 1914 елгы мөштәриләренә[1] биреләчәк һәдиядән[2] «Альбом», бәгъзе бер манигъларга[3] очрау сәбәпле, гыйнвар аенда таратылырга вәгъдә ителсә дә өлгермәде. «Альбом» бу көннәрдә матбагада басылып бетәчәк вә 10 марттан калмый мөштәриләргә күндереләчәктер. Кичегүе өчен алдан ук мөштәриләрдән гафу үтенеләдер. «Аң» идарәсе». («Аң», 1915, № 4, 28 февраль).

[1] *Чайковский* – Пётр Ильич Чайковский (1840–1893) – рус композиторы, педагог, дирижер, музыка тәнкыйтьчесе.

[2] *...полякның Шопеннары...* – Фредерик Франсуа Шопен (1810–1849) – поляк композиторы, пианист-виртуоз, педагог.

[3] *...солдатка киткән шәкертләрме, яшен суккан кызмы, суга баткан Гайшәме...* – Монда шул исемнәрдәге татар халык бәетләре искә алына.

[4] *Рәссам Маковский белән музыкант Чайковский тик руста гына туарга, рус халкының рухына гына чыгарга...* – Рус реалист рәссамнары арасында берничә Маковский фамилиясе бар. Бу урында Г. Ибраһимовның кайсы Маковский турында сүз алып баруы аңлашылмый. Владимир Егорович Маковский (1840–1920), аның улы Александр Владимирович Маковский (1869–1924), В.Е. Маковскийның бертуганнары Константин Маковский (1839–1915) һәм Николай Маковский (1841–1886) – рус реалист рәсем сәнгате үсешенә зур өлеш керткән шәхесләр. П.И. Чайковскийның да музыкаль әсәрләре дөньякүләм яңгыраш алган. Г. Ибраһимов искә алганча, Маковский һәм Чайковский иҗатларында рус халкының рухында гына туарга мөмкин булган хисләр, аның милли психологиясе ачылырга мөмкин.

[5] *...Шопенны ... Польшаның йөрәге генә тудырырга мөмкин...* – Монда поляк композиторы Фредерик Франсуа Шопен турында сүз бара. Ул үзенең музыкаль әсәрләрендә шулай ук милли изү астында яшәгән поляк халкының милли хисләрен, психологиясен чагылдыра. Г. Ибраһимов шуны истә тота.

---

*Мөштәриләренә* – сатып, яздырып алучыларына.

*Һәдиядән* – бүләктән.

*Манигъларга* – каршылыкларга.

**Телләре башка булса да, күңелләре бер** ***(матбугатта казакъ яшьләре тарафыннан кузгатылган тел мәсьәләсе мөнәсәбәте белән).*** «Аң» журналының 1916 елгы 31 март (5 нче) санында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган. Г. Ибраһимовның «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» (Казан, Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты, 1924; икенче басмасы –1927) дигән җыентыгына «Аерым телләр» исеме белән кертелгән.

[1] *...җитмеш-сиксән миллион чамасы төрек җаны хисаплыйлар.* – Г. Ибраһимов бу урында җир йөзендә яшәгән төрки халыкларның җан исәбен күздә тота.

[2] *Ибраһим Кунанбай* – Абай (Ибраһим Конанбаев) (1845–1904) – казакъ шагыйре, мәгърифәтче.

[3] *Сералин* – Мөхәммәт Сералин (1872–1929) – казакъ язучысы, журналист.

[4] *Дулатов* – Мырҗакып Дулатов (1885–1935) – казакъ шагыйре, язучы. Казакъ азатлык хәрәкәте һәм «Алаш Урда» хөкүмәте җитәкчеләренең берсе.

[5] *«Казакъстан»* – 1911 елның мартыннан 1913 ел башына кадәр Уральскида казакъ телендә чыккан газета.

[6] *«Казакъ»* – 1913 елның февраленнән 1918 ел башына кадәр Әхмәт Байторсынов мөхәррирлегендә Оренбургта казакъ телендә басылган газета.

[7] *«Айкап»лар* – 1908–1913 елларда Троицк шәһәрендә Мөхәммәт Сералин мөхәррирлегендә айга ике тапкыр казакъ телендә басылган газета.

**Әдәбият дәресләре.** Нашире – «Сабах» ширкәте. Казан, типография «Өмид», 1916. Икенчесе һәм өченче басмалары 1918, 1919 елларда Казанда «Сабах» ширкәтендә дөнья күргән. Икенче һәм өченче басмалар «Әдәбият кануннары» исеме белән нәшер ителгән. Басмалар арасында аерма юк диярлек. Әдипнең беренче басмага язган «Мөкаддимә урынына» мәкаләсенең язылу вакыты һәм урыны «1916, апрель, Уфа» дип күрсәтелеп, шул ук кереш мәкалә башка басмаларда да басылган.

[1] *Төрекләр дә Гареб мәдәниятенә аяк баса башлагач, Шинасилар туа...* – Ибраһим Шинаси (1826–1871) – госманлы төрек язучысы, тәрҗемәче, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Төрек драматургиясенә һәм яңа төрек әдәбиятына нигез салучы. Ул Парижда укый, шунда политэкономия, икътисад мәсьәләләре буенча белем ала, француз теле һәм әдәбиятын өйрәнә. 1859 елда Ж. Расин, А. Ламартин һәм Ж. Лафонтен әсәрләрен төрекчәгә тәрҗемә итеп бастыра. Гомумән, Шинаси француз әдәбиятын һәм мәдәниятен пропагандалауга күп көч куя.

[2] *Мисыр, Бабил мәдәниятләренең тугрыдан-тугры хәзерге мәдәнияткә бәйләнышы юк.* – Дөнья мәдәниятләре тарихында борынгы мәдәни

цивилизацияләр үрнәге буларак Мисыр һәм Бабил (Вавилон) мәдәниятенең кешелек җәмгыяте үсешендә әһәмияте зур.

[3] *... Һинд-Кытай мәдәнияте гомум адәм балаларын эченә алырлык...* – Дөнья мәдәниятенең нигезе Көнчыгыштан, ягъни кешелек тарихында борынгы дәүләтләр һәм мәдәни цивилизациянең башы саналган һинд һәм кытай мәдәниятенә барып тоташа. Соңрак Финикия, Вавилония, Мисыр дәүләтләренә күчә. Камилләшкән мәдәният сыйфатында Европаның бөек мәдәният үзәкләре саналган Грек һәм Рим империяләренә кабул ителә. Алар тәэсирендә гарәпләр мәдәнияте һәм ислам идеологиясе зур үсеш-үзгәреш чоры кичерә. Шул рәвешле, Гарәп империясендәге сәяси һәм икътисади, мәдәни кризис дәверендә Европа гарәп мәдәниятенә тартыла, нәтиҗәдә бүгенге Европа мәдәниятенең нигезе салына. Г. Ибраһимов бу урында, мәсьәләнең бер ягын гына искә алып, мәдәниятләр тарихын азрак чикли кебек.

[4] *Һомер* – Гомер (б. э. к. VII гасырда яшәгән) – борынгы грек легендар шагыйре, «Илиада» һәм «Одиссея» эпик поэмасының авторы.

[5] *Софокл* – Софокл (б. э. к. 496/495–406 еллар) – борынгы грек драматургы, трагик.

**Татар телен ничек укытырга?** ***(Телемезнең методикасы хакында бер тәҗрибә.)*** Биредә 1915 елның 20–27 июлендә Уфада узган мөгаллимнәр җыелышы турында сүз бара. Әлеге җыелышта катнашучыларның игътибар үзәгенә мәктәпләр өчен дәреслекләр һәм укыту методикасы мәсьәләләре куелган. Г. Ибраһимовның мәктәптә ана теле дәресләрен укыту методикасына багышланган китабы 1916 елда – автор Уфада «Галия» мәдрәсәсендә эшләгән чорда язылган булса кирәк (беренче басмага сүз башыннан соң «1916, Уфа» дип, дата һәм урыны төгәл күрсәтелгән). Әмма үз вакытында нәшер ителә алмыйча, бары тик 1918 һәм 1919 елларда гына Казанда «Сабах» көтепханәсендә ике тапкыр басылып чыккан.

**Яңа әдәби татар теленең беренче баскычларында.** «Каюм Насыйри мәҗмугасы»нда (Казан, 1922) «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән, аннан соң Г. Ибраһимовның «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» (Казан, 1924, 1927) җыентыгында басылган.

[1] *Бакыргани, Ясәви, Рабгузый, Нәваинең дә әсәрләре кайтты.*– Сөләйман Бакыргани (1186 елда вафат) – төрки телдә язган Урта Азия суфи шагыйре. «Китабе Хәким ата» («Хәким ата китабы»), «Ахырзаман китабы», «Хәзрәти Мәрьям китабы» (1887) исемле әсәрләр авторы. Ясәви Әхмәд (1105–1166 ) – төрки телдә язган суфи шагыйрь. «Диване хикмәт» («Хикмәтләр тупланмасы») исемле шигырьләр җыентыгы белән мәшһүр. Рабгузый Насретдин бине Борһанетдин (XIII гасырның икенче яртысы – XIV гасырның беренче яртысы) – язучы. Ярым уйгур-чыгтай,

ярым угыз-кыпчак төркисендә «Кыйсасел-әнбия» («Пәйгамбәрләр турында кыйссалар», 1310–1311) исемле пәйгамбәрләр тормышыннан язган хикәяләр җыентыгы авторы. Нәваи (Низаметдин Мир Алишер, 1441–1501) – Урта Азиянең төрки-үзбәк шагыйре, фикер иясе, дәүләт эшлеклесе. Төрки һәм фарсы телләрендә язган.

[2] *«Мөхәммәдияләр» бездә үз җәүһәре кебек урын алды.* – Урта гасыр төрек шагыйре Чәләби Мөхәммәд Язычы углы (1451 елда вафат булган) тарафыннан язылган әлеге көйле әсәр татарлар арасында киң таралыш тапкан. 1845 елдан башлап Казанда күп тапкырлар басылып чыккан. Ике өлештән торган: беренчесендә – Мөхәммәд пәйгамбәр тормышы, икенчесендә гадәти дини тәгълимат үрнәкләре рухында ахырзаман көне, ахирәттәге тормыш һ.б. сурәтләнгән китап кадими мәдрәсәләрдә дәреслек итеп файдаланылган.

[3] *Фәезханов Хөсәен* – Хөсәен Фәезханов (1828–1866), тарихчы-галим, көнчыгыш телләре белгече.

[4] *Муса Акъегетзадә* – Муса Мөхәммәджан улы Акҗегетов (1864–1923), татар язучысы, мөгаллим.

[5] *«Тәрҗеман»* – 1883 елның апреленнән 1918 елга кадәр Бакчасарай шәһәрендә (Кырым) төрки-татар телендә нәшер ителгән беренче газета. Нигезләүчесе, нашире һәм мөхәррире – Исмәгыйль Гаспринский (1851–1914).

[6] *Садри Максудовның «Мәгыйшәт» дигән озын хикәясе* – Садретдин Низаметдин улы Максудиның (1878–1957) «Мәгыйшәт» исемле романы 1898 елда Казанда басылып чыга.

[7] *Г. Исхаковның «Тәгаллемдә сәгадәт, яки Гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» дигән иң беренче хикәясе...* – Мөхәммәтгаяз Гыйләҗетдин улы Исхаковның (1878–1954) 1899 елда басылган беренче хикәясе.

[8] *Фатих Кәрими кебек кайбер мөхәррирләр («Аурупая сәяхәт», «Кырымә сәяхәт»)...* – Сүз Ф. Кәриминең 1902 елда Санкт-Петербургта басылган «Аурупа сәяхәтнамәсе» һәм 1904 елда Оренбургта басылган «Кырымга сәяхәт» китаплары хакында бара.

[9] *Тукай кебек шагыйрьләр («Мөхәммәдия дәвере»)...* – Мәдрәсәләрдә дәреслек буларак кулланылган, Мөхәммәд Чәләбинең XVII гасырда Идел буенда киң таралыш алган дини эчтәлекле «Мөхәммәдия» китабы XX гасыр башына кадәр татар шагыйрьләре иҗатына зур тәэсир ясаган. Габдулла Тукай да әлеге китап белән илһамланып иҗат мәйданына килгәнлектән, Галимҗан Ибраһимов, Җамал Вәлиди, Габдрахман Сәгъди, Фуад Кёпрүлүзадә кебек күренекле әдәбият белгечләре аның башлангыч иҗат чорын «Мөхәммәдия дәвере» дип атыйлар. Бу турыда Г. Ибраһимов «Татар шагыйрьләре» (1913) исемле мәкаләсендә болай ди: «Тукаевның беренче адымнары, гомумән беренче дәвере, нинди агым тәэсирендә бул-

ганлыгын белү өчен, һичбер мәшәкать сарыф итәргә мәҗбүр булынмый. Ул дәвердә язганнарында бик аз гына «Тәрҗеман» да бар, бик аз гына госманлы әдәбияты да күренә, ләкин иң көчлесе – «Мөхәммәдия»дер».

[10] *Риза хәзрәт, Хәсән Гали, Гаспринскийлар тарафыннан зур бер гыйсъян ясалды.* – Биредә Г. Ибраһимов 1910–1912 елларда «Шура» журналы битләрендә «Без татармы, төрекме?» дигән бәхәстә катнашучыларны искә ала. «Төрки» атамасын яклап, «Шура»ның 1910 елгы 23 нче санында «Берәү»нең «Татар түгел, төркичә», «Төрек углы»ның «Без татар имәсмез» исемле мәкаләләре басыла. «Татар» дигән исемне яклап, 1911 елның 2 гыйнвар санында «Без кем?» дигән имзасыз мәкалә, 1911 елгы 4 нче санында «Татар углы»ның «“Без кем?” мәсьәләсе» исемле мәкаләләре дөнья күрә. «Татарчылар»ның башында торган Г. Ибраһимов монда искә алынган Р. Фәхрддинов, Х. Гали, И. Гаспринскийларның карашларын тәнкыйтьли.

[11] *Боларның гаугасы аркасында шөбһәгә төшкән бәндәләр «Төрки сарыфлары», «Төрки нәхүләре» яздылар (Фәйзи, Кәбүтәри, Һади Максуди, Әхмәдҗан Мостафа, Г. Тәуфикъ әсәрләре).* – Педагог Гобәйдулла Мөхәммәтфәйзи улы Нигъмәтуллинның (1866–1938) «Кавагыйде төркия» (1898), «Кыйраәте төрки» (1899), тел белгече, мөгаллим Кәбүтәри Хәсәннең «Кыскача татарча сарыф» (1913), педагог, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе Әхмәтһади Низаметдин улы Максудовның (1868–1941) «Төрки сарыфы» («Татар теле морфологиясе») (1910), «Төрки имля кагыйдәләре» («Татар теленең орфография кагыйдәләре») (1910), «Төрки нәхүе» («Татар теле синтаксисы») (1910), җәмәгать эшлеклесе, педагог һәм имлячы Әхмәтҗан Мөхәммәдрәхим улы Мостафинның (1860–1938) «Төрки сарыфы» (Казан, 1905), «Төрки нәхүе» (Казан, 1914) китаплары күздә тотыла.

**Без – татармыз**. «Шура» журналының 1911 елгы 8 нче (апрель) санында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басыла. Мәкалә «Шура»да оештырылган «тел ярышы» бәхәсендә катнашучыларга җавап рәвешендә языла.

[1] *Вакыты илә сыйрыф тарихи бер мәсьәлә улмак сыйфаты илә, «без татармы, дәгелме?» мәсьәләсе кузгатылган иде. ... Бәгъзе гәзитәләргә бу бик зур мәүзугъ булды.* – 1905 елларда ук башланып киткән татар җәмгыятендә халыкның килеп чыгышы һәм үз-үзен атау (этноним) хакында бәхәс 1912 елларда да дәвам итә. Әйтергә кирәк: бу вакытта «татар» атамасы әле бөтен халыкта катгый рәвештә төпләнеп урнашкан булмый. Кайбер катлауларда, әйтик руханиларда, бу мәсьәләгә артык әһәмият бирелми, чөнки алар өчен дини үзбилгеләнү алданрак тора – үзеңне «мөселман» дип атау мөһимрәк санала. Кайбер төбәкләрдә борынгы болгарлар белән бәйле шәҗәрәләр традициясе көчле була, ул гына да түгел, болгарчылык

тәэсире XX гасыр башында әдәби әсәрләрдә дә чагылыш таба. Шулай да үзбилгеләнеш хакында төп көрәш, кискен бәхәсләр төркичеләр белән татарчылар арасында җәелеп китә, һәм ул көрәшнең төп мәйданы булган вакытлы матбугатта, бигрәк тә «Шура» журналы битләрендә, «Йолдыз» газетасында яктыртыла. Фикер төрлелегенә корылган бәхәс кызу полемика төсен ала. Мәсәлән, «Шура»ның 1910 елгы 23 нче (декабрь) санында бер авторның «Татарча түгел, төркичә» дигән имзасыз мәкаләсе басыла. Ул анда үзенең төркичә язганлыгын әйтеп, «нигә аларны татарча дип атыйсыз? Җир йөзендә «татар» дигән милләт барлыгына мин ышанмыйм. Мин – төрки угылы» дип игълан итә. Журналның 1911 елгы 2 нче (гыйнвар) санында исә «Без кем?» дигән имзасыз икенче бер мәкаләнең авторы, киресенчә, «төрки» атамасы белән килешмичә, «татар» дигән исемне яклап чыга. Аларның бәхәсе алга таба да яшерен имзалар астында дәвам итә. «Шура»ның шул ук елгы 4 нче (февраль) санында «Татар углы»ның «“Без кем?” мәсьәләсе» һәм «Төрек углы»ның «Без татар имәсмез» дигән яңа мәкаләләре урнаштырыла. «Татар углы», милләтне башка төркиләрдән аеру өчен, «татар» дигән исемне калдыру кирәклеген яклый. «Төрек углы» «татар» дигән исемнең тарихи дөрес булмавын һәм моны киләчәктә фәнни исбат итәчәген белдерә.

[2] *Егерменче гасыргача «татар» дип аталып килгән бер кавемне «Инкыйраз» иясе егерме икенче гасырда «болгар» ясап, мөнкариз кылды.* – Биредә Гаяз Исхакыйның 1904 елда дөнья күргән «Ике йөз елдан соң икыйраз» антиутопиясенә ишарә күрәбез. Бу әсәрдә Гаяз Исхакый милләтебезнең тарихын Болгар дәүләтеннән башлап, халыкның исемен дә «болгар» дип атый.

[3] *Бу көнгәчә чыккан сарыф вә нәхүләремез, татар теле өченяздыклары хәлдә, «төрки сарыфы», «төрки нәхүе» дип аталалар.* – Автор мәктәп-мәдрәсәләрдә укыту өчен дәреслек буларак мөгаллим-педагоглар тарафыннан төзелгән грамматика дәреслекләрен: мәсәлән, Әхмәтҗан Мостафаның «Төрки сарыф» (1905), Хәсән Кәбүтәринең «Тәртибе җәдидә мохтәсар сарфы төрки» (1910), Әхмәдһади Максудиның «Сарфы төрки» (1910), «Нәхүе төрки» (1910) һ.б. китапларны күздә тота.

«Татар телен тикшерү юлында (*татар сарыфлары*)» дигән мәкаләсендә (1915) Г. Ибраһимов үзе үк: «Болай атауның мәгънәсе коры исемдә генә булса, илтифат итмәс идек. Ләкин эш алай гына түгел. Безнең халык үзен «татар» дип атарга курка. Бу хәл моннан берничә еллар элек бигрәк көчле иде. Сарыф ияләре дә “Без татармы, түгелме” мәсьәләсендә аптырап калулары сәбәбеннән, әсәрләрен ниндидер томанлы, ике мәгънәле бер исем белән атыйлар», – дип яза.

[4] *Кемдер, бер Ходай бәндәсе, «Төрек углы» имзасы белән: «Миңа “татар” димәгез, мин татар түгел, төрек!» – дип акырды. Шуңа*

*кушылучылар да табылды. Тик касдан чыккан «Татар углы» гына кушылмаска тырышкан булды.* – «Шура»ның 1910 елгы 23 нче (декабрь) санында журнал алып барган «тел ярышы» дискуссиясендә катнашучы берәүнең «Татарча түгел, төрекчә» исемле мәкаләсе басыла. Автор анда үз мәкаләләрен «татарча түгел, төрекчә» язылган, нигә аларны татарча дип атыйсыз? Җир йөзендә «татар» дигән милләт барлыгына мин ышанмыйм. Мин – төрек угылы», – дип бәхәс кыла. Журналның 1911 елгы 2 нче (гыйнвар) санында исә, «Без кем?» дигән имзасыз икенче бер мәкаләнең авторы, киресенчә, «төрек» атамасын кире кагып, «татар» дигән исемне яклап чыга һәм бу турыда бәхәс күтәрүнең кирәксезлегенә басым ясый. «Шура» редакциясе авторлардан исем-фамилияләрен игълан итүләрен үтенә. «Татар угылы»ның «“Без кем?” мәсьәләсе» һәм «Төрек угылы»ның «Без татар имәсмез» дигән яңа мәкаләләре урнаштырыла. «Татар угылы», әүвәлдәгечә, башка төрки халыклардан аеру өчен, «татар» дигән исемне калдыру кирәк дип белдерә, ләкин яшерен имзасын ачудан баш тарта. «Төрек угылы» «татар» дигән исемнең тарихи дөрес булмавын һәм моны киләчәктә фәнни исбат итәчәге турында әйтә дә имзасын ачуны редакция иркенә тапшыра. «Без кем?» бәхәсендә берничә дистә кеше катнашкан, күбесе яшерен имзалар белән язган. Аларның төгәл исемнәре бүгенге көндә дә әле ачылып бетмәгән.

[5] *Тарихның моназарәсе бу бер кәррә бирелгән вә гомумчә танылган исемне алыштыруда... мең кәррә гаҗиздер.* – Биредә Г. Ибрагимов катгый рәвештә башка халыклар тарафыннан бирелгән исемне кабул итәргә өнди. Ләкин ул вакытларда руслар тарафыннан «татар» исеме берничә халыкка бирелгән була, әмма алар революциядән соң бу исемнән баш тарталар, ул халыклар төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә башка исемнәр кабул итәләр. Мисал өчен, «Минусинск татарлары» хакас булып китәләр, «кыргыз-кайсаклар» дип йөртелгән халык хәзер – казакълар, «Кавказ татарлары» дип аталганнары хәзер азәрбайҗаннар буларак билгеле.

[6] *Һәркемгә мәгълүм: руслар, дөресрәк сүзгә нәзарән, диңгез артыннан килгән бер кенәзнең рус нәселенә мәнсүб булучылыгы сәбәпле генә «рус» аталып киттеләр.* – Биредә сүз 862 елда Ильмень күле (хәзерге Новгород тирәләрендә) славяннарның варяглардан (викинглардан) булган «рус» дигән кабиләдән Рюрик исемле бер төркем (дружина) башлыгын (конунгны) үзләре белән идарә итәргә чакырганнары турында бара.

[7] *Без төрек кенә түгел, монголбыз да.* – Биредә «монголбыз да» дигәнне кызу полемика кулланылышы буларак карарга кирәк. Әлбәттә, Г. Ибраһимов Идел-Урал буйларында яшәгән татарларның монгол түгеллеген аңлаган. Әмма «монголмыз да» дип әйтүендә үз татар халкын Чыңгыз ханның бөек дәүләтенең варисы итеп күрергә теләве аңлашыла.

Ф. Кәриминең тарих буенча дәреслек китабына багышланган «Яңа әсәр» дигән мәкаләсендә (Вакыт, 1911, 878 нче сан) Чыңгыз ханны «татар даһисы» дип атавы да шуңа бәйле икәнен ачык күрсәтә.

**«Без кем?» бәхәсе.** «Шура» журналының 1912 елгы 9 нчы (май) санында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән дөнья күрә.

[1] *Байтактан чәйнәлеп килгән «Без кем?» мәсьәләсенең батыры, «Төрек углы», һаман ул моназарәне куерта тора.* – «Шура» журналының 1912 елгы 1–2 нче саннарында «Төрек угылы» имзасы белән «Без төрекмез» дигән зур мәкалә басыла. Автор «татар» атамасына кискен рәвештә каршы чыга, аны халыкка читтән тагылган «миссионерлар кулындагы корал» дип атый. Халыкның төрки кабиләләрдән оешканы турында тарихи дәлилләр китерә.

**Бәйрәм мөбарәк булсын!** «Аң» журналының 1914 елгы 3 нче санында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган.

[1] *Без, татарлар, исламны соң кабул иттек.* – 922 елда Идел болгарлары ислам динен дәүләт дәрәҗәсендә кабул иткән дип санала.

[2] *...хәзрәте Гайсә* – Гайсә пәйгамбәр исламда Мөхәммәд пәйгамбәрдән алда килгән.

**Хәят вә әдәбият (*еллык тәәссорат*).** «Йолдыз» газетасының 1915 елгы 8 һәм 14 гыйнвар (1345 нче, 1349 нчы) саннарында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган. Мәкалә ахырында «бетмәде» дип куелган.

[1] *...бөек ислам реформаторлары – Әфганилар, Габдеһләр дә миллиятне аңлауда...* – Монда XIX йөз ахыры – XX йөз башында мөселман дөньясының күренекле реформаторлары Җамалетдин Әфгани (1839–1897) һәм Мөхәммәт Габдеһ (1849–1905) күздә тотыла.

[2] *Тантави* – Шәех Мөхәммәдгаяз Тантави (1810–1861) – шәркыятьче галим. Мисырда туа. 1839 елдан Россиядә яши һәм эшли. 1847 елдан Санкт-Петербург университеты профессоры итеп сайлана.

[3] *Риза казый* – Риза Фәхреддин.

[4] *Рәшид казый* – Габдерәшит Гомәр улы Ибраһимов (1857–1944) – җәмәгать, сәясәт һәм дин эшлеклесе, публицист.

[5] *Муса Бигиев* – Монда дин галиме, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, публицист Муса Ярулла улы Бигиев (1875–1949) күздә тотыла.

[6] *Зыя әл-Камали* – Зыя Камали (Камалетдинов Пәрвазетдин Җамалетдин улы).

[7] *...Исмәгыйль бәк ... милләттән бөтен төрек кавемен аңлады...* – Бу урында И. Гапринскийның гомумтөрки тел идеясен яклаган хезмәтләре

күздә тотыла. Алар китап булып та һәм «Тәрҗемән» газетасында аерым мәкаләләр рәвешендә дә басылганнар.

[8] *...«Татар булмый, кем соң син, әллә чуваш яки мукшымы?» мәзмунендә фикер әйтә.* – Әлеге эчтәлектәге фикер Шиһабеддин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле хезмәтенең кереш өлешендә урын алган.

[9] *...«Шура»да бу хакда «Төрек угыллары» бик кызып моназарә башлаган...* – Бу урында татар вакытлы матбугатында 1910–1912 елларда татар милләтенең исеменә бәйле бәхәс күздә тотыла. Аерым алганда, әлеге бәхәс-дискуссия гомумтөрки тел идеясен алга сөргән «Шура» журналы битләрендә еш күзәтелә. «Шура»ның 1910 елгы 23 нче (декабрь) санында «Татарча түгел, төрекчә» исемле имзасыз мәкалә басыла. Автор анда үз мәкаләләрен «татарча түгел, төрекчә язылган, нигә аларны татарча дип атыйсыз? Җир йөзендә «татар» дигән милләт барлыгына мин ышанмыйм. Мин – төрек угылы» дип бәхәс кыла. Журналның 1911 елгы 2 нче (гыйнвар) санында исә «Без кем?» дип аталган имзасыз икенче бер мәкаләнең авторы, киресенчә, «төрек» атамасын кире кагып, «татар» дигән исемне яклап чыга һәм бу турыда бәхәс күтәрүнең кирәксезлегенә басым ясый. «Шура» редакциясе авторлардан исем-фамилияләрен игълан итүләрен үтенә. «Татар угылы»ның «“Без кем?” мәсьәләсе» һәм «Төрек углы»-ның «Без татар имәсмез» дигән яңа мәкаләләре урнаштырыла. «Татар угылы» әүвәлгечә башка төрки халыклардан аеру өчен «татар» дигән исемне калдыру кирәк дип белдерә, ләкин яшерен имзасын ачудан баш тарта. «Төрек углы» «татар» дигән исемнең тарихы дөрес булмавын, моны киләчәктә фәнни исбат итәчәген әйтә һәм имзасын ачуны редакция иркенә тапшыра.

[10] *«Шура»да бу хакта анкета сыман бернәрсә булгач... «Без – татармыз» исемендә бер мәкалә...* – Г. Ибраһимовның бу язмасы «Шура» журналының 1911 елгы 8 нче (апрель) санында басылып, «Төрек угылы» имзалы мәкаләләргә җавап йөзеннән язылган.

[11] *Г. Баттал, Җ. Вәлидов әфәнделәр шул елларда язылган мәкаләләрендә инде татарлык, төреклек мәсьәләсе өзелде...* – Бу урында Г. Баттал һәм Җ. Вәлидинең матбугатта басылган фәнни мәкаләләрендә, 1910 еллар башында кызу бәхәсләр уяткан «төреклек һәм татарлык» мәсьәләсенә нокта куеп, татар халкы «татар» исеме белән генә йөртелә алуын дәлилләп күрсәтүләре турында сүз бара. 1914 елда бу проблема кабат калка. Инде проблема гомумтөрки әдәбиятын милли әдәбиятларга бүлүгә бәйле рәвештә туа. Г. Ибраһимов әлеге мәсьәләгә Р. Фәхреддиннең «Әхмәд Мидхәт әфәнде» исемле китабына язган мәкаләсендә кискен җавап бирә.

[12] *...«Әхмәд Мидхәт әфәнде» әсәрендә бу мәсьәләгә яңадан кайтып...* – Р. Фәхреддин «Әхмәд Мидхәт әфәнде» китабында, гомумтөрки

тел һәм әдәбият проблемасын кабат күтәреп, татар әдәбияты, башкорт әдәбияты һ.б.га бүлү гомумтөрки әдәбиятны юкка чыгарачак дигән фикер уздыра. Монда шуңа ишарә.

[13] *...татарлык тарафдарларының Ильминский мәсләгенә хезмәт итүләрен...* – Николай Иванович Ильминский (1822–1891) – шәркыятьче, педагог, миссионер. Н. Ильминский – мөселманнарны, гомумән төрки халыкларны, вак төркемнәргә бүлеп, аларга кириллица кертеп, акрынлап христанлаштыру сәясәтен нигезләүче һәм шул фикерен уздыру өчен шактый көч куйган шәхес.

[14] *...«Г.И.» әфәнде тарафыннан Риза хәзрәтнең «Әхмәд Мидхәт» әсәре хакында...* – Монда Г. Ибраһимовның Р. Фәхреддиннең «Әхмәд Мидхәт әфәнде» исемле китабына язган бәяләмәсе һәм «төрек һәм татар» бәхәсенә карата әйтелгән фикерләре күздә тотыла.

[15] *Җамалетдин Вәлидовның... «Милләт вә миллият» исемле әсәрендә...* – Җ. Вәлидинең «Милләт вә миллият» исемле китабы 1914 елда Оренбургта «Вакыт» матбагасында басыла.

[16] *Хәсән Сабри әфәнде «Тәрҗеман»да һаман бу мәсьәләгә кайтырга ярата.* – Хәсән Сабри Айвазов (1878–1938) – кырымтатар язучысы, әдәбият тәнкыйтьчесе, педагог, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе. 1914 елдан «Тәрҗеман» газетасының мөхәррире. Ул да остазы И. Гаспринскийның «гомумтөрки тел» идеясен дәвам итү ягында була.

[17] *...Сатыш вә Кышгар дамеллалары...* – Бу урында XIX һәм XX йөз башларында татарлар арасында мәгълүм Казан артындагы Сатыш һәм Кышкар авылы мәдрәсәләренең күренекле мөдәррис һәм имамнарына ишарә ясала.

[18] *... «Идел» гәзитәсе шул татар әдәбияты телендә язылды.* – Биредә Г. Ибраһимов Әстерханда 1907–1914 елларда нәшер ителгән «Идел» газетасын күздә тота һәм әлеге газетада басылган әсәрләрнең нугай теленең диалектында түгел, ә татар әдәби телендә язылуына басым ясый.

[19] *Фуад Туктаров* – Фуад Фәсах улы Туктаров (1880–1938) – сәясәт эшлеклесе, публицист.

[20] *Шәһид Әхмәдиев* – Шәһит Гыймадетдин улы Әхмәдиев (1888–1930) дәүләт эшлеклесе, язучы.

[21] *...«Нур» иясе Баязитовлар...* – Бу урында дин галиме һәм җәмәгать эшлеклесе, публицист Гатаулла Баязитов (1847–1911) һәм аның улы дин, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, нашир Мөхәммәтсафа Баязитов (1887–1937 елдан соң) күздә тотыла. Болар – 1905 елда С.-Петербургта беренчеләрдән булып татар телендә «Нур» газетасы нәшер итә башлаган шәхесләр. Газета 1914 елга кадәр басыла.

[22] *Шакир Мостафаев* – Шакир Мостафаев (тәхәллүсләре – Мостафа Ш., Мостафи Ш.) Касыймнан һәм Мәскәүдән яза. Прозаик, шагыйрь,

публицист. Аның «Замана хикәясе, яхуд Фәүзи» исемле әсәре 1908 елда «Әхбар» газетасында басыла. Соңрак 1909 елда бу әсәр китап булып та нәшер ителә. 1913 елда Казанда «Мәңгелек мәхәббәт» исемле китабы дөнья күрә.

[23] *Нәҗип Гасрый* – Нәҗип Гасрый (Мөхәммәтнәҗип Аллабирде улы Мәүләбирдиев) (1886–1937) – әдәбият тәнкыйтьчесе.

[24] *Хәлим Искәндәров* – Хәлим Фәттахислам улы Искәндәров (1888–1958) педагог, журналист, тәнкыйтьче.

[25] *Мәҗид Гафури* – Габделмәҗит Нургали улы Гафуров (1880–1934) – татар-башкорт язучысы, фольклорчы.

[26] *...Ерак шимальдән тарылы Рәшид казый...* – Монда Габдерәшит Ибраһимовның туган җире Себер, ягъни Омск губернасы Тары шәһәреннән булуы искә алына.

[27] *...ерак Себердә чыккан «Сибирия» гәзитәсе...* – «Сибирия» газетасы барлыгы 145 сан булып, 1912 елның 18 мартыннан 1913 елның 31 августына кадәр Томск шәһәрендә басыла.

**Яңа әсәр.** «Вакыт» газетасының 1911 елгы 18 ноябрь (877 нче), 22 ноябрь (878 нче) саннарында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган. Бу мәкалә Ф Кәриминең тарих буенча мәктәп-мәдрәсәләр өчен чыгарылган дәреслек китабына (Кәрими Ф. Мохтәсар тарих гомуми. Оренбург: Х. Хөсәенов, 1911. 343 б.) бәяләмә буларак язылган.

[1] *Олугбәк* – Олугбәк яки Мөхәммәд Тарагай ибн Шаһрух ибн Тимер Олугбәк Гаруган (1394–1449), Урта Азиядә Аксак Тимер төзегән дәүләт хөкемдары, Аксак Тимернең оныгы. Күренекле галим: математик, астроном, шулай ук тарих һәм шигърият белән шөгыльләнгән. Үз вакытында бик мөһим булган обсерватория оештырган.

[2] *Ибн Синаларны* – Ибне Сина, Әбү Гали Хөсәен ибне Габдулла, Әбүгалисина (980–1037), Урта Азиянең бөек энциклопедист галиме, философ, табиб, астроном, шагыйрь һәм музыкант. Күп кенә хезмәтләр, шул исәптән «Тыйб гыйльме кануннары» исемле теоретик һәм клиник медицина энциклопедиясе авторы. Аның китаплары бөтен дөньяда, шул исәптән татар халкы арасында да киң тарала һәм дан-шөһрәт казана.

[3] *Фөзули кеби берничә шагыйрьләрен...* – Фөзули Мөхәммәт бин Сөләйман (1483–1556), мәшһүр төрки шагыйрь, фикер иясе. Төрле чыганакларда төрек, азәрбайҗан, госманлы шагыйре дип йөртелә. Азәрбайҗан шигъриятенең классигы дип санала.

[4] *Атилла* – Аттила (Атилла) (… – 453), Көнчыгыш Европада һуннар дәүләте башлыгы (434 елдан), җиһангир. Аттила җитәкчелегендә һуннар V гасырның 40 нчы елларында Көнчыгыш Рим империясенә (Византиягә) һөҗүмнәр оештыралар.

[5] *Наполеон* – Наполеон I Бонапарт (1769–1821). 1804–1815 елларда Франция императоры. Француз хәрби җитәкчесе һәм дәүләт эшлеклесе.

[6] *Искәндәр кәбиргә...* – Биредә сүз бөек гаскәрбашы, борынгы Македония һәм Греция патшасы Александр Македонский (б. э. к. 356–323 еллар) хакында бара.

[7] *...танылган татар даһисы Чыңгыз хакында...* – Чыңгыз хан (Темучин) (1155 ел тирәсе – 1227). Монгол империясенә нигез салучы, аның беренче Бөек ханы (1206 елдан), җиһангир. Ләкин аны «татар даһисы» дип әйтү тарихи чынбарлык күзлегеннән бик үк дөрес булмас, чөнки Чыңгыз хан үзен беркайчан да татар дип атамаган. Биредә Г. Ибраһимовның, Идел-Урал буйларында яшәгән ханлыклар заманыннан бирле таралган традициягә нигезләнеп, үз татар халкын Чыңгызның бөеклегенә мөнәсәбәтле булуын күрсәтергә теләген күрәбез.

[8] *Мәшһүр Аксак Тимер* – (Әмир Тимер, Тамерлан) – Тимер ибн Тарагай Барлас (1336–1405), җиһангир, Урта Азия дәүләте әмире. 1387 елда Алтын Урда җирләренә яу белән килә. Туктамыш хан гаскәрен тар-мар итеп, күп шәһәрләрне талап, җимереп китә. Татар дастаннарында ул идарә иткән дәвердә Урта Азия дәүләте шактый күп өлкәләрне үзенә буйсындыра (Иран, Харәзем, Хорасан, Пәнҗаб, Кавказ аръягы ханлыклары) һәм иң югары икътисади, мәдәни үсешкә ирешә. Сәмәркандта төзелгән Гүр Әмир мавзолей-төрбәсе дөнья күләмендә танылган сәнгать үрнәге булып тора. Аксак Тимер исеме татар дастаннарында да очрый, мәсәлән, татар халкы арасында киң таралган «Дастане Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» (беренче тапкыр 1819 елда татар галиме Ибраһим Хәлфин тарафыннан басыла). Әлеге дастанның өченче бүлегендә («Кыйссаи Аксак Тимер») Аксак Тимернең тормышы һәм гамәлләре турында бәян ителә. Кыйссаның бер өлешендә Аксак Тимернең Болгар шәһәрен яулап алуы һәм Биләр шәһәре Самәт ханның аңа үз шәһәрен үз теләге белән тапшыру турында сөйләнә.

[9] *...Иван Грозный кем?* – Явыз Иван IV (1530–1584), Мәскәү кенәзлегенең бөек кенәзе (1533 елдан), 1547 елдан – патша. Татар халкы хәтерендә 1552 елда Казанны алганда чиктән тыш вәхшилекләр кылуы белән истә калган.

**Милли тарих.** «Йолдыз» газетасының 1912 елгы 8, 12, 17 апрель (816 нчы, 818 нче, 820 нче) саннарында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган.

[1] *Үзләренә дин табып биргән олуг Владимирлар...* – Биредә сүз Киев кенәзе Владимир I (?–1015) турында бара. Владимир – Святослав кенәзнең кече улы, 980 елдан Киевта бөек кенәз.

[2] *...газиз Ольгалар...* – Киев кенәзе Игорьның хатыны кенәзбикә Ольга (890 тирәсе – 969) турында сүз бара. Ире һәлак булгач, улы Святослав балигъ булганчы, Киевта хакимлек сөрә. Рус аксөякләреннән беренче булып Константинопольгә барып, христиан динен кабул итә.

[3] *...әллә нинди зур куәткә ия булган Муромецлар...* – Рус былиналары каһарманы Илья Муромец турында сүз бара.

[4] *Гали батыр (хәзрәте Гали)* – халык әкиятләренә образ буларак кергән Гали бине Әбү Талиб (599–661) турында сүз бара. Мөхәммәд пәйгәмбәрнен кияве һәм сугышларда аның уң кулы булган сахабәсе. Мөхәммәдтән соң гадел хәлифәләрнең дүртенчесе (656–661).

[5] *Батый* – Чыңгыз ханның оныгы, Җүчинең улы, Бөек Монгол империясенең гаскәр башлыгы, җитәкче, җиһангир, Алтын Урдага нигез салучы Бату хан (1207–1256).

[6] *Мамай* – (?–1380), бәкләр бәге, 1360 елдан Алтын Урданың Көнбатыш олысы идарәчесе.

[7] *Сөембикә* – (1516 тирәсе – 1554 тән соң), нугай Йосыф бәк кызы, балигъ булмаган улы Үтәмеш-гәрәй хан вакытында Казан ханлыгы идарәчесе (1549–1551). Халык хәтерендә Казанны Мәскәү яуларыннан яклаучы буларак сакланып калган.

[8] *Чыңгыз* – Чыңгыз хан (Темучин) (1155 ел тирәсе – 1227). Монгол империясенә нигез салучы, аның беренче Бөек ханы (1206 елдан), бөек полководец, җиһангир.

[9] *Мөхтәрәм Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтенең «Мөстәфадел әхбар»ы.* – Сүз атаклы татар галиме, дин белгече, тарихчы, философ, мәгърифәтче Шиһабеддин Баһаведдин улы Мәрҗанинең (1818–1889) 1880 елда язылган «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр») хезмәте турында бара. Бу китап, тарихи чыганакларга нигезләнеп, 1880 елда язылган. Беренче мәртәбә ул Казанда ике китап итеп бастырыла (1т. – 1885, 1895; 2 т. – 1890 елларда).

[10] *Рәшид казыйның «Чулпан йолдыз»лары.* – Мәшһүр җәмәгать, сәясәт һәм дин эшлеклесе Габдерәшит Гомәр улы Ибраһимовның (1857–1944) 1895 елда Истанбулда басылган «Чулпан йолдызы» хезмәте күздә тотыла. Әлеге китапта Г. Ибраһимов төрек укучыларына Россия татарлары арасында ислам дине таралуы, татар ханлыклары, татарларны көчләп чукындыру турында мәгълүмат бирә. Шулай ук Диния нәзарәтенең һәм аның вәкилләрен патша хөкүмәте хөкеменнән чыкмыйча, татарларның мәнфәгатьләрен кайгыртмауда гаепли. Цензура тарафыннан тыелуына карамастан, китап яшерен рәвештә зыялылар, шәкертләр арасында таралып, зур кызыксыну уята.

[11] *Ризаэддин бине Фәхреддин әфәнденең «Асар»ы.* – Сүз мәгърифәтче, галим, тарихчы, дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе Ризаэддин Фәхреддин улы Фәхреддиновның (1859–1936) 1900–1908 елларда Оренбургта нәшер ителгән дүрт томнан торган «Асар» (гарәпчәдән – «Эзләр») исемле биобиблиографик җыентыгы хакында бара. Анда Идел-Урал төбәгендә яшәгән төрки халыклардан булган 1200 дән артык күренекле шәхесләрнең биографияләре тупланган.

[12] *Ризаэддин әфәнденең «Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре»...* – биредә Ризаэддин Фәхреддиннең 1907 елда Оренбургта «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» матбагасында басылган хезмәте күздә тотыла.

[13] *Мәккәле Морад әфәнденең гарәби телле «Тәлфик»ы...* – Морад Рәмзи (1854/1855–1934), тарихчы, публицист һәм дин галиме. Ул, 1877 елда «Мәрҗания» мәдрәсәсен тәмамлагач, Шәрык илләренә сәяхәт кыла. Мәккә шәһәрендә нәкешбәнди суфыйчылык мәзһәбенә кушылып, шунда яшәп кала. Аның ике китаптан торган «Тәлфикъ әл-әхбар вә тәлкыйх әл-әсар фи вәкаигъ Казан вә Болгар вә мөлүк әт-татар» («Казанда вә Болгарда булган вакыйгалар һәм татар мәликләре (патшалары) турында хәбәрләр») дигән хезмәте 1908 елда Оренбургта басылып чыга, ләкин цензура тыюы нәтиҗәсендә барлык тиражы конфискацияләнә.

[14] *...Гайнетдин Әхмәровның рисаләләре...* – сүз Казан Татар укытучылар мәктәбендә укып чыккан, 1893 елдан Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы булган һәм әлеге җәмгыятьнең «Известия»ләрендә татар этнографиясе («О языке и народности мишарей», 1903; «Свадебные обряды казанских татар», 1907; «Тептяри и их происхождение», 1908) буенча хезмәтләрен бастырган Гайнетдин Нәҗметдин улы Әхмәров (1864–1911) хакында бара. Казанда «Шәрык клубы»н оештыручыларның берсе буларак, Г. Әхмәров анда татар тарихы буенча популяр лекцияләр укый һәм әлеге лекцияләрнең нигезендә фәнни хезмәтләр бастыра: «Болгар тарихы» (1909), «Казан тарихы» (1910).

[15] *...Хәсәнгата казыйның мәшһүр тарихы...* – Биредә сүз дин галиме, Диния нәзарәте казые, тарихчы Хәсәнгата Габәшинең (1863–1936) төрки кәвемнәр тарихына багышланган хөзмәтләре хакында бара: «Мөфассаль тарихе кауме төрки» («Төрек кәвеменең тәфсилле тарихы», 1909), «Төрек кәвемнәре» (1897), «Мохтәсар тарих кауме төрк» («Төрек кавемнәрнең кыскача тарихы», 1907).

[16] *Мәшһүр Бокль, дөньяда башка нәрсәләр барын онытыр дәрәҗәдә гел шуңа бирелеп кенә эшләдеке хәлдә, 21 ел гомерен сарыф итеп, үзенең «Англия мәдәнияте тарихы»н...* – Генри Томас Бокль (1821–1862), инглиз тарихчысы, 1857 елда беренче тапкыр дөнья күргән «Англия цивилизациясе тарихы» китабының авторы.

[17] *Һади Атласиның «Себер тарихы».* – Тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы Һади Мифтахеддин улы Атласов (1876–1938) һәм аның беренче тапкыр 1911 елда Казанда Себер ханлыклары тарихына багышланган хезмәте күздә тотыла.

[18] *«Сибирия» гәзитәсе* – «Сибирия» – сәяси, әдәби, икътисади газета. 1912 елның 18 мартыннан 1913 елның 31 августына кадәр Томск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире – Вәгыйз Нәүрүзов.

[19] *Имам Халиди әфәнденең «Тәварихы хәмсәи шәркыйә»сен...* – Халиди Корбангали (1846–1913), тарихчы, этнограф, дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Басылып чыккан хезмәтләрендә Көнчыгыш Төркестанда яшәүче татарлар, казакълар һәм башка төрки халыкларның тормышкөнкүреше, гореф-гадәтләре, иҗтимагый-дәүләти оешмалары һәм Урта Азиядәге мәгариф эшләре турында бай мәгълүмат бар. 1910 елда дөнья күргән «Тәварихы хәмсәи шәркыя» («Шәрык хәмсәнең тарихы») исемле китабында ул татарларның, төрекмәннәрнең, азәрбайҗаннарның, кыргызларның, үзбәкләрнең һәм башкортларның тарихларын бердәм төрки халык тарихы буларак тасвирлый.

[20] *«Шура» журналында басыла килгән ханнар тәрҗемәи әхвале...* – Биредә Ризаэддин Фәхреддиновның «Шура» журналындагы тарихка караган материаллары турында сүз бара. Журналның 1 нче санында (1908) Идел буе Болгары хөкемдары Алмыш хан турындагы мәкалә басыла. Аннары Алтын Урда ханнары хакында мәкаләләр циклы урнаштырыла (1908, 2–9 нчы саннар), шуннан соң Казан ханнары турындагы материаллар сериясе басыла (1908, 10–16 нчы саннар; 1909, 1–3 нче саннар). Болардан соң Чыңгыз хан империясе, Җүчи, Бату ханнар һәм аларның варислары дәверен сурәтләүгә багышланган һәм Алтын Урданың башлангыч чорын тасвир кылган мәкаләләр бирелгән (1909, 4–9 нчы саннар). Касыйм ханлыгы буенча тикшеренүләр исә 1909 елгы (12–16 нчы) саннарга карый. Идел Болгарстаны тарихына багышланган материалларның төп өлеше инде 1912 елгы (18–20; 22 нче) саннарда урын алган.

[21] *...«Төрек юрды»ндагы мәкаләләр...* – «Төрек юрду» («Төрек йорты»), фәнни-популяр журнал. «Төрек юрду» һәм «Төрек очагы» ширкәтләре органы. 1911–1931 елларда Истанбулда төрек телендә нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррирләреннән берсе – Йосыф Акчура. «Төрек йорты»нда татар халкы тарихына караган хезмәтләр һәм аларны анализлап язылган мәкаләләр дә басыла. Шундыйлардан, мәсәлән, Й. Акчураның «Чыңгыз хан»ын, Әхмәдзәки Вәлидинең «Казан ханлыгының соңгы көннәре»н (Kazan Hanlığının son günleri // Türk yurdu. İstanbul. Sayı 7. S. 575–

580) күрсәтергә мөмкин. Журналга, төрекләрдән тыш, И. Гаспралы, Ф. Кәрими, Җ. Вәлиди һ.б. авторлар да языша.

[22] *...Йосыф Акчура әфәнденең ул журналда басылып килмәкдә улган «Чыңгыз хан»ы...* – Акчура (Акчурин) Йосыф Хәсән улы (1876–1935), күренекле татар галиме, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, тарихчы, публицист. Истанбулда «Төрек юрду» журналын нәшер итүчеләрнең берсе, даими редакторы. Биредә сүз Й. Акчураның «Төрек йорты» журналының 1911 елгы 1–10 нчы саннарында француз тарихчысы Леон Каһун һәм Шәрыкны өйрәнүче рус галиме В. Бартольд хезмәтләренә таянып язылган «Чыңгыз хан» дигән күләмле язмасы турында бара. Китапта кулланган чыганакларга мөнәсәбәтле автор кереш сүзендә болай яза: «Мин фәкать ике чыганакка гына мөрәҗәгать иттем. Чыганакларның икесе дә төрки тарихчылар түгел. Беренчесе – исеме госманлыларга бик таныш булган тарихчы Леон Каһунның «Азия тарихына кереш...» (Париж, 1886). Икенчесе – Петербург университеты профессоры Владимир Бартольдның «Образование империи Чингизхана» (СПб., 1897) әсәре», – ди. Моның сәбәбен: «...Профессор Бартольд – ахыргача, хакыйкатькә тугрылыклы калуны яклаган тарихчылардан», – дип белдерә. (Акчура Й. Сайланма әсәрләр. Казан, 2011. Б. 543–545). Бу хезмәт – татар тарих фәнендә, XVII гасыр башы «Җәмигъ әт-тәварих», «Чыңгызнамә»ләреннән соң махсус Чыңгыз хан темасына багышланган беренче әсәр.

[23] Йосыф әфәнденең бу мөһим әсәре, әлбәттә, китап шәкелендә чыкса кирәк. – Г. Ибраһимов югары бәяләгән бу әсәрнең аерым китап итеп бастырылуы мәгълүм түгел.

[24] *...Леон Каһун...* – Leon Cahun (1841–1900), француз сәяхәтчесе, шәрык белгече, язучы. Сорбонна университетында студентларга Азия тарихы курсын укыган. Аның Төрки халыклар тарихын яктырткан: «*Générale l'Histoire de l'Asie.* («Гомум Азия тарихы», 1896 ), *«Introduction à l'histoire de l'Asie: Turcs et Mongols des origines à 1405»* («Азия тарихына кереш: төрекләр һәм монголлар килеп чыгышыннан 1405 елга кадәр», 1896) исемле һәм башка хезмәтләре төрек милләтчеләренә (шул исәптән Мостафа Кәмал Ататөреккә дә) зур йогынты ясаган.

**Рус, төрек вә татар тарихыннан *(Романовлар ханәданының 300 еллык шәүкәте мөнәсәбәте белән).*** «Йолдыз» газетасының 1913 елгы 3 март (951 нче), 5 март (952 нче), 17 март (957 нче) саннарында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган.

[1] *Бату тарафыннан хәрабәгә әйләндерелгән карт Киев...* – 1240 елда Бату хан җитәкчелегендә монгол гаскәренең Киев шәһәренә һөҗүм итеп, аны басып алуы һәм тар-мар итүе турында сүз бара.

[2] *Шул ук даһи тарафыннан үзенә пайтәхет итеп төзелгән Сарайның бүген, Хода хакы өчен, урынында, ичмаса, бер ташы да калмаган...* – Бу юллар язылган чакта археология әле түбән дәрәҗәдә була. Ләкин инде XIX гасыр азагында Сарайның хәрабәләре Селитренное авылында булырга тиеш дигән гипотеза барлыкка килә. Чын фәнни археологик эзләнүләр бары тик Совет вакытында 1920 елларда башлана, 1960 һәм 1980 елларда уздырыла һәм бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Хәзерге вакытта Сарай шәһәренең урыны төгәл билгеле. Шәһәрнең хәрабәләре (хан сарае, йортлар, һөнәрче остаханәләре, мәчет нигез калдыклары) хәзерге Әстерхан өлкәсенең Селитренное авылы янәшәсендә сакланган.

[3] *...иске пайтәхетләрдән Каракорым...* – Каракорым (монголча Хара-Хорин) – Хәзерге Монголиядә Урхун елгасының югары агымында урнашкан. 1220 елда Чыңгыз хан тарафыннан нигезләнгән. XIII йөздә (1260 елга кадәр) Монгол империясе башкаласы булган.

[4] *Шәһри Болгар...* – X–XIII йөзләрдә Урта Идел һәм Чулман буенда урнашкан Идел буе Болгар дәүләтенең башкаласы. Шәһәр Идел елгасының сулъяк ярында урнашкан, һәм ул чәчәк аткан, мәдәни һәм икътисади яктан да алга киткән зур сәүдә үзәге була. 1236–1237 елларда Батый хан гаскәрләре Болгар дәүләтен яулап ала. Шәһри Болгар яндырыла, тар-мар ителә.

[5] *Әле күптәнме госманлы төреге Европага дәһшәт бирә иде.* – Госманлы империясенең иң көчле вакытлары – XV–XVII гасырлар турында сүз бара. Бу чорда Госманлы дәүләте Балкан ярымутравында тулысынча хөкем сөргән, аның гаскәрләре исә хәзерге Италия, Австрия һ.б. Европа илләренә зур куркыныч янаган.

[6] *Әле күптәнме Анатулы гаскәре Вена капкасында иде...* – Госманлы империясенең Австрия башкаласына һөҗүмнәре турында сүз бара. Госманлы гаскәрләре Вена шәһәренә ике тапкыр һөҗүм итәләр: 1529 елда – солтан Сөләйман Кануни заманында һәм 1683 елда – солтан Мәхмәд IV идарә иткән вакытта. Ләкин ике һөҗүм дә госманлы төрек гаскәрләре өчен уңышсыз тәмамлана.

[7] *Шуннан күпме генә вакыт үтте дә, кичәге көтүчеләре бүген актык төрек тәхетен сөрмәк әмәл кабихенә төштеләр.* – Г. Ибраһимов Киевта булган чакта, 1912 елның октябрь аеннан башлап дәвам иткән Балкан сугышы вакыйгалары күздә тотыла. Бу сугышта Греция, Сербия, Болгария һәм Черногория Госманлы империясенә һөҗүм итеп, байтак уңышларга ирешәләр һәм империянең башкаласы булган Истанбулга кадәр җитәләр. «*Кичәге көтүчеләре»* – сугышта төрекләргә дошман булган болгарлар һәм башка славяннарга карата әйтелгән бу фраза шул чорда «Вакыт» газетасының хәбәрчесе булып Истанбулда эшләгән Фатих Кәрими мәктүбеннән (мәкаләсеннән) «күчкән»: «Икенче тарафдан, ислам вә төреклек

дөньясы башыны килгән фәлякәтләрне[1] күзең берлән якындан күрүб язар ичүн, шул фәлякәтнең тәмам оясына таба бару вә тугрусын яздык исә мөселманларның күңелләрен рәнҗетүргә мәҗбүр булу, ыслау[2] дөньясындагы рух күтәренкелеге, алардагы бер-берсенә ярдәмнәр, утуз гына ел элүк көтүчелек иткән болгарларның хазерендә «өч йөз мильон» мөселманларның мәкам хәлифәтләрен дер селкетүрлек дәрәҗәгә йитүрләре...» (Кәрими Ф. Истанбул мәктүбләре. Оренбург, 1913. Б. 5).

[8] *Мәскәү, Киев хәяты, Бату, Наполеон, Сигизмунд көннәре моңа җанлы шаһид була алырлар.* – Биредә рус дәүләтчелеге өчен дәһшәтле чорлар турында сүз бара: XIII йөздә Бату хан җитәкчелегендәге монгол явы, 1812 елда Франция императоры Наполеон I җитәкчелегендәге гаскәрнең Мәскәүне алуы, 1610–1612 елларда Мәскәүгә Польша короле Сигизмундның гаскәр белән керүе.

[9] *Татар шаһзадәләренең, юк кына интригалар тәэсире белән хилаф якка чыгып, үз милләттәшенә каршы кылыч күтәрүе...* – Мисал өчен, Олы Урда 1502 елны җимерелгәч, аның соңгы ханы Әхмәднең уллары Мәскәү дәүләтенә качалар, һәм анда аларга идарә итәргә шәһәрләр һәм волостьлар бирелә. Шул ук рус гаскәрләре тарафында татарларга каршы сугышкан Шаһгали ханны да (1505–1567) мисал итеп китерергә була.

[10] *...һәрвакыт рус гаскәре эчендә татарга каршы күкрәк киереп сугышучы татар угылларының булуы, дәхи хәятлары өчен рус дөньясын татар фамилиясе илә тутыручы бәк вә морзаларымызның...* – Мисал өчен, 1552 елда Казанга һөҗүм вакытында рус гаскәрендә Касыйм ханлыгыннан гына 3000 татар була. Берничә йөз ел дәвамында – Алтын Урда оешкан заманнардан алып татар ханлыкларының соңгы елларына кадәр – татар гаскәриләренең рус дәүләтенә хезмәткә күчү процессы дәвам итә. Атаклы рус аристократ фамилияләрнең күбесе татардан чыкканлыклары мәгълүм: Юсуповлар, Кутузовлар һәм башкалар. Мәшһүр татар тарихчысы А.Х. Халиков үз вакытында русларда 500 болгар-татар фамилиясен күрсәткән (Халиков А.Х. 500 русских фамилий булгаро-татарского происхождения. Казань, 1992).

[11] *Гәрәй ханның рус хәтере өчен Сарай хөкүмәтен астын өсткә китерүен...* – Биредә сүз Кырым ханы Миңлегәрәй (?–1515) турында бара. Алтын Урданы торгызырга ниятләгән Олы Урда ханнары Әхмәд һәм аның балалары белән озак еллар сугыша. Төркия солтаны белән Мәскәү бөек кенәзе Иван III гаскәрләре ярдәмендә 1502 елда Олы Урданы тар-мар итә, Сарайны яулап ала.

---

[1] *Фәлякәтләрне* – бәла, кайгы, афәтләрне.

[2] *Ыслау* – славян.

[12] *...Касыйм татарларының әүвәлге хәрәкәтләре.* – 1450 елларда Касыйм ханлыгы (Касыйм патшалыгы) Мәскәүнең бөек кенәзе Василий II тарафыннан Казан ханзадәсе Касыймга бүлеп бирелгән биләмә җирлегендә оеша. Кыска вакытта Мәскәүнең Казанга каршы сәясәтенең коралына әйләнә. Касыйм ханлыгы ханнары еш кына Мәскәүнең Казанга каршы оештырылган яу-һөҗүмнәрендә үз гаскәрләре белән катнашалар (1467–1469, 1487, 1552).

[13] *Һәрвакыт татар бәхетсезлеге өстенә тәхет кора килгән Шаһгалинең кылганнары...* – Шаһгали хан (1505–1567); 1516–1519, 1535–1546, 1546–1551, 1552–1567 елларда – Касыйм ханы; 1519–1521, 1546, 1551–1552 елларда Казан ханлыгы белән идарә итә. Мәскәү яклы сәясәт тотуы сәбәпле, казанлылар тарафыннан Казан тәхетеннән куыла. Берничә тапкыр Мәскәү гаскәрләренең Казанга каршы яуларында катнаша (1537, 1540, 1541, 1548, 1552 елларда).

[14] *Без үз кулымыз белән газиз Сөембикәне Мәскәүгә рәһенгә бирдек.* – Биредә сүз 1551 елда Сөембикә ханбикәнең идарәчелектән төшерелүе һәм улы Үтәмешгәрәй белән бергә Мәскәүгә озатылуы турында бара.

[15] *Атилла* – Аттила (Атилла) (…–453), Көнчыгыш Европада һуннар дәүләте башлыгы (434 елдан), җиһангир. Аттила җитәкчелегендә һуннар V гасырның 40 нчы елларында Көнчыгыш Рим империясенә (Византиягә) һөҗүмнәр оештыралар. 451 елда Көнбатыш Рим империясенә каршы сугыш башлыйлар һәм ул дәүләтнең җимерелүенә зур өлеш кертәләр.

[16] *Чыңгыз* – Чыңгыз хан (Темучин) (1155 ел тирәсе – 1227). Монгол империясенә нигез салучы, аның беренче Бөек ханы (1206 елдан), җиһангир.

[17] *Бату* – Чыңгыз ханның оныгы, Җүчинең улы Бату хан (1207–1256) турында сүз бара. Бөек Монгол империясенең гаскәр башлыгы, көнбатыш яуның җитәкчесе, җиһангир, Алтын Урдага нигез салучы.

[18] *Тимерлан* – Аксак Тимер (Тамерлан) (1336 тирәсе – 1405), җиһангир, әмир, Урта Азиядә төрки дәүләт идарәчесе. Аксак Тимер дәүләте биләмәләренә, Мавәраэннәһердән кала, Харәзем, Хорасан, Кавказ таулары арты ил һәм өлкәләре, Иран белән Пәнҗаб мәмләкәтләре керә.

[19] *Мамай* – Мамай (?–1380), бәкләр бәге, 1360 елдан Алтын Урданың Көнбатыш олысының идарәчесе.

[20] *Мидхәт паша* – Әхмәд Шәфикъ Мидхәт паша (1822–1884). Госманлы империясенең танылган дәүләт эшлеклесе. Либераль реформалар тарафдары. Ике тапкыр (1872 һәм 1877 елларда) садр әгъзам (бөек вәзир, хөкүмәт башлыгы) вазифаларын башкара. Аның тырышлыклары белән 1876 елда Габделгазиз I тәхеттән төшерелә. Төркия дәүләте тәхетенә килгән яңа яшь солтан Габделхәмид II Мидхәт паша тәэсире һәм басымы астында мәшрутият (конституция) игълан итәргә мәҗбүр була.

Лəкин соңыннан падишаһ аны эшеннəн ала һəм төрмəгə яба. Шунда Мидхəт пашаны сакчылар үтерə. Габделхəмид II утыз өч ел дəвамында идарə итə. Бу чорны аның дошманнары «золым» дип атыйлар. XX йөз башы татар зыялыларының күпчелеге Габделхəмидкə каршылык күрсəткəн «Яшь төреклəр» ягында була. Шулар исəбендə Г. Тукай, Ф. Кəрими, Й. Акчура һəм, күренгəнчə, Г. Ибраһимов һəм башкалар.

[21] *Угыз ханнар...* – Аерым төрки халыклар (азəрбайҗаннар, төрекмəннəр һ.б.) мифологиясендəге һəм Урта гасырлар эпик əсəрлəрендə (мəсəлəн, «Китаби дəдə Коркуд»та) угызларның борынгы бабалары турында сүз бара.

[22] *Госманнар* – XIV йөз башында Көнбатыш Анатолиядə кечкенə дəүлəтчелек төзегəн төрек ыругы. Аның исеме Эртугрул Гази улы Госмангазидəн (1258–1324) килə. Берничə дистə елдан əлеге дəүлəт Кече Азиядə (Анатолиядə) һəм Көнчыгыш Балканда иң куəтле дəүлəткə əверелə. 1453 елдан Византия башкаласы Константинопольне кулга алган бу дəүлəт дөньяда иң көчле империялəрнең берсенə əйлəнə.

[23] *...Казанда аз бер заманда халык яратмаган Шаһгалинең өч мəртəбə ханлыкка менүлəре...* – Чыгышы белəн Касыймнан булган Шаһгали хан (1505–1567), чынлап та, өч тапкыр Казан ханы була (1519–1521, 1546, 1551–1552).

[24] *Бүгенге төрекнең һəр ел ун мəртəбə кабинет алмаштырулары...* – Биредə сүз Госманлы империясенең XX гасыр башында сəяси хəле, хакимият өчен сəяси партиялəр арасындагы туктаусыз көрəше турында бара. 1908–1909 елларда инкыйлаб нəтиҗəсендə солтан Габделхəмид II не тəхеттəн төшереп, хакимият «Яшь төреклəр» («Иттихад вə тəрəккый» партиясе тарафдарлары) кулына күчə. 1912 елның июлендə хөкүмəт отставкага китəргə мəҗбүр була, һəм яңа Министрлар кабинеты «Яшь төреклəр»гə дошман булган «Иттиляф вə хөррият» партиясе тарафдарларыннан төзелə. Шул ук елның августында иттихадчылар күпчелекне тəшкил иткəн парламент таркатыла. Октябрь аенда яңа либераль хөкүмəтнең премьер-министры итеп Камил паша (1833–1913) билгелəнə. Ə инде 1913 елның 23 (10) гыйнварында Əнвəр бəк (булачак Əнвар паша) җитəкчелегендə «Яшь төреклəр», хəрби көч кулланып, Камил паша хөкүмəтен тулысынча отставкага китəргə мəҗбүр итеп, хакимиятне яңадан үз кулларына алалар.

[25] *Бервакыт рус халкы... үзе ышанган берсенə – Годуновка ялына башлый.* – Биредə сүз Борис Федорович Годунов (1552–1605) турында бара. Грозныйның улы патша Федор Иоаннович үлгəч, Рюриковичлар династиясе өзелə. Федорның хатыны һəм Б. Годуновның сеңлесе Ирина Годунова патшалыктан баш тарткач, патриарх һəм боярлар Борис Годуновтан патша булуын үтенəлəр. Бу вакыйга А.С. Пушкинның «Борис

Годунов» трагедиясендә дә чагыла. Рус шагыйре трагедиянең бер күренешендә боярлар җитәкләгән халыкның, Новодевичий монастырьга барып, Годуновны патша булырга ризалыгын сорауларын күрсәтә.

[26] *Еракка бармыйча, тик Наполеон һөҗүменә каршы Русиянең торткан хәрәкәтен генә хәтергә алу, бу халыкның зурлары, каһарманнары түгел, бәлки шул чабаталы гавамы ничаклы эш кыла алачагын ачык күрсәтәдер.* – Бу фикердә Л.Н. Толстойның «Сугыш һәм солых» романының тәэсире сизелә.

[27] *Достоевскийның бу хактагы мәшһүр мәсьәләсе, аның һәммә хәзинә халыкта, халык табигатендә дигән нәзариясе...* – Рус язучысы һәм фәлсәфәче Федор Михайлович Достоевскийның (1821–1881) карашларында «почвенничество» («туфракчылык») фәлсәфәсенең чагылышы турында сүз бара булса кирәк. Әлеге фәлсәфә Достоевскийның әсәрләрендә һәм мәкаләләрендә күренә. Көнбатыш мәдәниятен идеаллаштырган фикер ияләренә (западникларга) каршы чыгып, Достоевский славянофиллар идеяләренә якын булган «Россиянең иҗтимагый нигезләрен рус халкының рухыннан эзләргә кирәк» дигән фикергә килә. Аның өчен бу туфракта төрле мәсләктә булган төркемнәр (либераллар, демократлар), халык белән берләшеп, яңа формадагы җәмгыятьне барлыкка китерә алачаклар.

[28] *Глеб Успенский* – Глеб Иванович Успенский (1843–1902) – народниклар хәрәкәтенә якын булган рус язучысы.

[29] *соңгы Горькийлар...* – Алексей Максимович Горький (Пешков) (1868–1936) – рус һәм совет язучысы, шагыйрь, прозаик, драматург. Г. Ибраһимовның «соңгы Горькийлар» дип әйтүе Горькийның 1910 елларда язылган әсәрләренә һәм хезмәтләренә ишарә булса кирәк.

[30] *...Толстойның... игътирафы...* – Г. Ибраһимов 1870–1880 елларда Л.Н. Толстой иҗатында һәм карашларында чагылган аерым принципларны күздә тота: цивилизациядән баш тарту, гади халык тормышына якынаю, гади халык тормышы белән яшәү. Әлеге принцип «гадиләштерү (упрощение)» исеме белән билгеле.

**«Гани бай» китабы *(Тәхрир итүчесе – Борһан Шәрәф).*** «Йолдыз» газетасының 1914 елгы 11 май (1185 нче) санында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган.

[1] *Гани бай* – Гани (Габделгани) Мөхәммәтгали улы Хөсәенов (1839–1902). Оренбургтагы атаклы Каргалы бистәсе сәүдәгәрләре өч бертуган Хөсәеновлардан. Хөсәеновлар Оренбургта, Урта Азиянең берничә шәһәрендә, Берлин һәм Лондонда сәүдә йортлары тоталар. 1889 елда Оренбургта җәдит ысулындагы «Хөсәения» мәдрәсәсен ачалар. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бинасын төзүгә һәм тотуга акчалата булышалар. Казан, Уфа, Оренбург, Самара губерналарында 60 тан

артык мәчет һәм мәктәп-мәдрәсә төзиләр, мөгаллимнәр тоталар. Гани бай ярдәме белән Оренбургта беренче мөстәкыйль татарча басмаханә ачыла.

[2] *Борһан Шәрәф* – Борһан Шәрәфетдин улы Шәрәф (1883–1942), җәмәгать эшлеклесе, язучы, нашир, педагог. «Мөхәммәдия» һәм «Хөсәения» мәдрәсәләрендә мөгаллим. Ул төзегән «Гани бай» китабы 1914 елда басылып чыга (Шәрәф Б. Гани бай: Тәрҗемәи хәле, мәктүбләре һәм аның хакында хатирәләр. Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1914. 300 б.). Китапта Гани Хөсәеновның тәрҗемәи хәле, киңкырлы эшчәнлеге яктыртылган, аның турында хатирә-истәлекләр, хатлар урын алган. Автор тарафыннан китапның керешендә үк Гани байның, ысулы җәдидәне киң җәелдерү өчен, күп көч куюы ассызыклана. Аның шәхесе һәркем өчен төрле яктан үрнәк булырлык, эш сөючән, фидакяр, игътибарлы әңгәмәдәш, киң карашлы һәм ышанычлы иптәш итеп тасвирлана.

[3] *Мөстәшрикъләр тәгъбиренчә Волга хәвазасында «яңа туып килә торган» бер милләт бар.* – Бу җөмләдә Г. Ибраһимов, үзенең элекке фикерләреннән аермалы буларак, беренче тапкыр исемен әйтмичә генә татарларны башка төрки халыклардан аерым бер милләт итеп күрсәтә – бу милләтнең яшәеш урынын «Волга хәвазасы», димәк, Идел буйлары дип билгели. Биредә Г. Ибраһимовның татарларны «яңа туып килә торган» милләт дип атау, XX гасыр башында татар зыялылары арасында «мөселман», «төрек» яки «болгар» үзбилгеләнүләреннән баш тарту, «татар» исемен куллануына ишарәли.

[4] *«Яңа туып килә торган» мәгънәсе белән булса да, ул милләтнең мәгънәвияте бар. Ул хәят икътисадия вә маддиясендә күрсәткән хәрәкәтене, мәгънәви, гыйльми, рухи хәятында да күрсәтә: аның егерме биш яшендә генә булса да – мәктәбе, әдәбияты, ун яшендә генә булса да, театры, әфкяре гомумия тудырырга бик ныклап хезмәт итә торган матбугаты бар.* – Биредә Г. Ибраһимов татар милләтенең икътисади үсешеннән тыш мәдәни алгарышларын да искә ала. «*Егерме биш яшендә генә була да, мәктәбе*» – сүз XIX гасырның ахырында барлыкка килә башлаган җәдит уку йортлары турында бара. «*Ун яшендә генә булса да, театры*» – 1906 елдан барлыкка килә башлаган беренче татар театр труппасы искә алына. «*Бик ныклап хезмәт итә торган матбугаты*» дигәндә, 1905 ел революциясеннән соң аякка басып килгән татар вакытлы матбугаты күздә тотыла.

[5] *Искәндәр кәбир...* – биредә сүз бөек гаскәрбашы, борынгы Македония һәм Греция патшасы Александр Македонский (б. э. к. 356–323) хакында бара.

[6] *Атиллалары...* – Аттила (Атилла) (…–453), Көнчыгыш Европа һуннар дәүләте башлыгы (434 елдан), җиһангир. Аттила җитәкчелегендә һуннар V гасырның 40 нчы елларында Көнчыгыш Рим империясенә (Византиягә)

һөҗүмнәр оештыралар. 451 елда Көнбатыш Рим империясенә каршы сугыш башлыйлар һәм ул дәүләтнең җимерелүенә зур өлеш кертәләр.

[7] *Чыңгыз* – Чыңгыз хан (Темучин) (1155 ел тирәсе – 1227). Монгол империясенә нигез салучы, аның беренче бөек ханы (1206 елдан), җиһангир.

[8] *Батый* – Чыңгыз ханның оныгы, Җүчинең улы Бату хан (1207–1256) турында сүз бара. Бөек Монгол империясенең гаскәр башлыгы, көнбатыш яуның җитәкчесе, җиһангир, Алтын Урдага нигез салучы.

[9] *Алтайның итәкләрендә хәйләсез гомер кичерергә алышкан татарга...* – Биредә Г. Ибраһимов аерым халык турында сүз алып бармый кебек, бәлки Алтай «бөтен төрки халыкларның туган бишекләре» мәгънәсендә күрсәтелә.

[10] *…мәктәптә укытучы «абыз» – ул дәвернең Гаспринские…* – Урта гасырларда яшәгән мәктәп-мәдрәсәләр ачкан диндар, тырыш татарларны Г. Ибраһимов мәшһүр җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, педагог, нашир Исмәгыйль Мостафа улы Гаспринский (1851–1914) белән чагыштыра. 1868–1871 елларда ук ул мәдрәсәдә укытуның яңа методын (ысулы җәдид) куллана. 1883 елдан Россиядә беренче төрки телдә газета («Тәрҗеман») чыгара.

[11] *Бакчасарайда чыккан «кигәвен»нең безелдәве...* – Биредә сүз 1883 елдан Бакчасарайда Исмәгыйль Гаспринский тарафыннан нәшер ителгән «Тәрҗеман» газетасы турында бара. Ул газетада мәгърифәт мәсьәләләре иң зур урын алып торган.

[12] *...мәктәп!... коры сүзне фәгалиятькә чыгару өчен, Ходайның бер сөекле бәндәсе Казалыда сәрмая җыеп ята иде.* – Казалы – Урта Азиядәге сәүдә шәһәре. Биредә Гани байның Урта Азия шәһәрләрендә, шул исәптән Казалыда да сәүдә йортлары, зур кибетләре булып, анда милләт, халык файдасына башкарасы зур эшләре өчен кирәкле акча туплау өчен тырышып хезмәт куюына ишарә.

[13] *...бу ике фидакяр Сәмәркандта очраштылар.* – «Гани бай» китабында Габделгани Хөсәеновның 1893 елда И. Гаспралы белән Сәмәркандта очрашуы турында мәгълүмат китерелә.

**Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы.** Беренче мәртәбә «Безнең юл» журналының 1922 елгы 1 нче (май) санында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган. Аннан соң кайбер өстәмәләр һәм төзәтүләр кертелеп, мәкалә «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» (1924, 1927) җыентыгына урнаштырылган.

[1] *Ризалар, Габәшиләр, Рәшидләр, Баязидлар, Бубилар, Мусалар, Зыялар* – дин һәм җәмәгать эшлеклеләре Ризаэддин Фәхреддин (1859–1936); Габәши Хәсәнгата (1863–1933); Габдерәшит Ибраһимов (1857–1944); Гатаулла Баязитов (1846–1911); Габдулла һәм Гобәйдулла

Бубилар; Муса Бигиев (1873/75–1949); Зыя Камали (1873–1942) хакында сүз бара.

[2] *Атласов Һади* – тарихчы, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, педагог Әхмәтһади Мифтахетдин улы Атласов (1876–1938). Икенче Дәүләт думасында «Мөселман хезмәт таифәсе» әгъзасы.

[3] *Халиди* – мәгърифәтче әдип, тәрҗемәче, драматургия жанрына нигез салучыларның берсе Фатих Хаммат улы Халиди (1850–1923).

[4] *Зәки Вәлиди* – сәясәт эшлеклесе, тарихчы, галим, публицист Әхмәтзәки Әхмәтша улы Вәлиди (1890–1970).

[5] *Һади Мөниров* – тарихчы Һади Мөниров (?–1913).

[6] *Газиз* – тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, публицист, язучы Габделгазиз Салих улы Гобәйдуллин (1887–1937).

[7] *Баттал* – тарихчы, филолог һәм журналист, җәмәгать эшлеклесе Габделбари Габдулла улы Баттал (1880–1969).

[8] *Солтан Рахманколый* – язучы, тәрҗемәче, лөгатьче Солтан Габделмәннан улы Рахманколов (1888–1916). Ул – Г. Кәрам белән бергә «Русча-татарча мөкәммәл лөгать»не төзүче, «Татарча-русча лөгать», «Балалар өчен татарча өйрәткеч» китапларының авторы.

[9] *Шәрәф Шәһидуллин* – нашир, календарьлар төзүче Шәрәфетдин Кәшшафетдин улы Шәһидуллин (1870–1925 елдан соң) хакында сүз бара. Ул «Заман» календарен, «Русия сәүдәсе» журналын нәшер итә.

[10] *Һади Максуди* – педагог, нашир, журналист, сәяси эшлеклесе Әхмәтһади Низаметдин улы Максуди (1868–1941).

[11] *Шакирҗан Таһири* – педагог, кульязма һәм басма китап остасы Шакирҗан Әхмәтҗан улы Таһиров (1858–1918).

[12] *Гыймад Нугайбәк* – тел галиме, журналист Гыймадетдин Шәрифҗан улы Нугайбәк (1881–1943).

[13] *Г. Шәрәф* – тел галиме, язучы, сәясәт эшлеклесе Галимҗан Шәрәфетдин улы Шәрәф (1896–1950).

[14] *Җ. Вәлиди* – тел һәм әдәбият галиме, педагог, тарихчы, публицист, җәмәгать эшлеклесе Җамалетдин улы Вәлиди (1887–1932). Репрессияләр чоры корбаны.

[15] *Нигъмәт Хәкимов* – тел галиме, әдәбиятчы Нигъмәт Гыйниятулла улы Хәкимов (1889–1937).

[16] *«Әсма», «Сәлимә»* – Ризаэддин Фәхреддиннең «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1899) романы һәм «Әсма, яки Гамәл вә җәза» (1903) хикәясе.

[17] *Садри Максудиның «Мәгыйшәтләре»* – язучы, җәмәгать эшлеклесе Садри Максудиның (Садретдин Низаметдин улы Максудов, 1879–1957) «Мәгыйшәт» (1898) романы хакында сүз бара.

[18] *...драматург Галиәсгар Камал* – язучы, нашир, җәмәгать эшлеклесе Галиәсгар Камал (1879–1933).

[19] *...«Тутам» мөхәррире Г. Чыгътай...* – Язучы Галиәсгар Мөгыйн улы Гафуров-Чыгътайның (1867–1942) «Тутам» повестеның ике кисәге бергә тупланган басмасы 1908 елда Казанда дөнья күрә. Әсәрдә язучы гаилә мөнәсәбәтләрендә яшәгән тәртипләргә каршы чыга, хатын-кыз хокукларын яклый, аның үз язмышын үзе хәл итәргә тиешлеген раслый.

[20] *Закир Һади* – язучы, мәгърифәтче, педагог Закир Һадиулла улы Һади (1863–1933).

[21] *Ярулла Вәли* – язучы, журналист Ярулла Вәлиулла улы Вәлиев (1879–1937). «Ахырзаман бәласе» (1907), «Ачлык кушты» (1908), «Оят, яки Күз яше» (1909) драмалары авторы. Репрессияләр чоры корбаны.

[22] *Г. Рәхим* – күренекле татар язучысы, әдәбиятчы-галим, фольклорчы, тәнкыйтьче Мөхәммәтгали Мөхәммәтшакир улы Габдерәхимов (Гали Рәхим, 1892–1943).

[23] *Рәфикъ Г.* – журналист, язучы, педагог, тәрҗемәче Гали Лотферахман улы Рәфыйков (1890–1945).

[24] *Алкиннар, Әхмәтовлар, Сәйдәшевләр, Тәфкилевләр, Бигловлар, Акчуралар...* – җәмәгать эшлеклеләре Сәетгәрәй Алкин (1867–1919), Әбүсогуд Әхтәмов (1843–1918 елдан соң), Әхмәтҗан Сәйдәшев (1840–1912), Котлыгъмөхәммәд Тәфкилев (1850–1917 елдан соң), Әкрам Биглов (1871–1919), Йосыф Акчура (1876–1935) турында сүз бара.

[25] *«Мөселман иттифакы»* – «Иттифак әл-мөслимин» Россия мөселманнарының либераль-демократик юнәлешле сәяси партиясе. 1905–1907 еллардагы инкыйлаб чорында туа.

[26] *Риза казыйның «Әхмәт бай»* – Риза Фәхретдиннең «Әхмәт бай» китабы 1911 елда Оренбургта нәшер ителә. Китапта Оренбург сәүдәгәре, миллионер һәм меценат Әхмәд Хөсәеновның (1838–1906) тәрҗемәи хәле һәм эшчәнлеге турында бәян ителә.

[27] *Борһан Шәрәфнең «Гани бай»...* – Җәмәгать эшлеклесе, педагог, язучы, нашир Борһан Шәрәфнең (1883–1942) «Гани бай» китабы 1913 елда Оренбургта басыла. Китапта Оренбург миллионеры, меценаты Гали Хөсәеновның (1838–1902) эшчәнлеге хакында бәян ителә.

[28] *Батталның «Вәли Яушев»...* – Тарихчы Габделбари Батталның 1912 елда Оренбургта басылган «Троиски байларыннан вә хәйрият ияләреннән Габделвәли Яушев» китабы. Яушевлар – Оренбург губернасы Троицк, Чиләбе шәһәрләре сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре, җәмәгать эшлеклеләре. Габделвәли Әхмәтҗан улы (1840–1906) – тире эшкәртү заводының уртак хуҗасы, Чиләбе шәһәрендә үз кибетләрен ачкан һәм бертуганнары белән «Габделвәли Әхмәтҗан улы Яушев һәм бертуганнары уртак сәүдә йорты»н нигезләгәннәр. Яушевлар – хәйрия җәмгыятен, Троицк шәһәрендә Яушевлар мәктәбен оештыручылар. Алар мәчетләр төзелешенә, мәдрәсәләр тотуга матди ярдәм иткәннәр.

[29] *«Галия»* – мәдрәсә, татар халкының иң зур мәгърифәт учакларыннан берсе. Мәдрәсә 1906 елда Уфа шәһәрендә ачыла. Нигез салучысы һәм җитәкчесе – Зыя Камали. 1920 елда мәдрәсә ябыла.

[30] *«Мөхәммәдия»* – мәдрәсә, 1882 елда Казанда ачыла. Мәдрәсәгә Г. Баруди нигез сала һәм җитәкчелек итә.

[31] *«Буби»* – мәдрәсә, Вятка губернасы Сарапул өязе (хәзерге ТРның Әгерҗе районы) Иж-Бубый авылында 1881 елда Габделгалләм Нигъмәтуллин тарафыннан Иж-Бубый мәчете каршында мәхәллә мәдрәсәсе буларак ачыла. 1895 елдан мәдрәсәгә аның уллары Габдулла һәм Гобәйдулла Бубилар җитәкчелек итә һәм укыта.

[32] *«Хөсәения»* – мәдрәсә, 1889 елда Оренбург шәһәрендә ачыла. Мәдрәсә иганәче сәүдәгәр Хөсәеновлар исеме белән атала. 1919 елда ябыла.

[33] *«Вакыт»* – сәяси һәм әдәби газета. 1906–1918 елларда Оренбург шәһәрендә нәшер ителә. Наширләре – бертуган Рәмиевләр.

[34] *«Ил»* – 1913 елдан алып 1918 елның апреленә кадәр төрле исемнәр («Сүз», «Безнең ил») белән нәшер ителгән газета. Нашире – Г. Исхакый.

[35] *«Сүз»* – 1915 елның декабреннән 1916 елның сентябренә кадәр Мәскәүдә чыккан газета. Нашире – Г. Исхакый.

[36] *«Кояш»* – 1912 елның 10 декабреннән 1918 елның 29 мартына кадәр Казанда татар телендә чыккан газета. Мөхәррире һәм нашире – З. Садретдинов.

[37] *«Тормыш»* – иҗтимагый-сәяси һәм икътисади газета. 1913–1918 елларда Уфа шәһәрендә нәшер ителә. Беренче мөхәррире – М. Нәүрузов. 1914 елдан – З. Кадыйри.

[38] *«Алтай»* – «Корылтай» газетасының дәвамы. 1918 елда Казанда 13 саны нәшер ителә.

[39] *«Корылтай»* – иҗтимагый-сәяси газета. 1917–1918 елларда Казанда татар телендә нәшер ителә. Мөхәррирләре – Ф. Туктаров, Г. Баттал.

[40] *«Шура»* – иҗтимагый-мәгърифәти һәм әдәби-публицистик журнал. 1908–1917 елларда Оренбургта татар телендә нәшер ителә. Наширләре: Ш. Рәмиев, Дәрдемәнд.

**Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?** Казанда Татарстан дәүләт нәшриятында басылган. Текстны беренче тапкыр, гамәлдәге хәрефкә күчереп, З.З. Рәмиев «Казан утлары» журналының 1992 елгы 3 нче (март) санында бастырды.

[1] *Владимир Ильич Ленин «О национальной гордости великороссов» исемендә бер мәкалә язды* В.И. Ленинның «Социал-Демократ» газетасының 1914 елгы 12 декабрь (35 нче) санында басылган мәкаләсе турында сүз бара.

[2] *ВПИ белән ТКУ* – ВПИ (Восточно-педагогический институт) – 1922 елда оештырылган Шәрык педагогия институты; ТКУ (Татарский коммунистический унивеиситет) – совет һәм партия органнары өчен хезмәткәрләр әзерләү максаты белән 1922 елда оештырылган Татар коммунистлар университеты.

**Шәрыкның бөек революционеры Мулланур иптәш Вахитов.** 1919 елда Казанда «Иҗтимагый революция» мәҗмугалары дип аталган сериянең Мулланур Вахитовка багышланган беренче китабында («Шәрыкның бөек революционеры Мулланур Вахитов», Галимҗан Ибраһимов карамагында, Казан: Мәркәз мөселман хәрби һәйәт нәшере, 1919. 95 б.) басылган. Текстның ахырына: «Галимҗан Ибраһимов, Казан, 1919, октябрь» дип куелган.

[1] *...социализм нәтиҗәсендә төзеләчәк гомуми мәдәнияттә борынгы гарәп мәдәниятенең зур тәэсире булачагына ышана...* – Мулланур Вахитов беркайчан да милли һәм дини җирлектән аерылмаган. Гарәп мәдәниятенә сылтавы, аңа таянырга теләве ислам цивилизациясенең бик җитди әһәмияткә ия булуын яхшы аңлап эш итүе һәм киләчәккә планнар коруы хакында сөйли. Хәер, 1909 елда язган «Борынгы ислам мәдәнияте» китабында Г. Ибраһимов үзе дә ул мәдәниятнең казанышларын горурлык белән күрсәтеп, замана мөселманнарын аңа иярергә чакырган.

[2] *...эш башына Столыпин килеп утыргач...* – 1906 елда Пётр Аркадьевич Столыпин Россиянең Министрлар советы рәисе һәм эчке эшләр министры итеп билгеләнә.

[3] *Кичәге социалист-революционер Гаяз Исхаков, Туктаров, Шакир Мөхәммәдъяров, Сәгыйть Рәмиевләр, социал-демократ Гомәр Терегулов, Ибнеямин Әхтәмовлар...* – Язучы, журналист Гаяз Гыйләҗетдин улы Исхакый (Исхаков) (1878–1954), публицист Фуад Фәсах улы Туктаров (1880–1938), хокук белгече, педагог Шакир Зариф улы Мөхәммәдъяров (1883–1967), күренекле шагыйрь Сәгыйть Лотфулла улы Рәмиев (1880–1926), сәясәт эшлеклесе, педагог Гомәр Хабибрахман улы Терегулов (1883–1938), хокук белгече, татар меньшевиклары җитәкчеләреннән берсе Ибраһим Әбүсогуд улы Әхтәмов (1880–1931).

[4] *Мин аны беренче мәртәбә Бөтенрусия мөселманнарының икенче корылтаенда Казанда очраттым.* – Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае 1917 елның 22 июленнән 2 августына кадәр Казанда уза.

[5] *Мулланур белән икенче очрашуым Петербургта мәшһүр Смольный институтында булды.* – Смольный институты бинасы 1806– 1808 елларда дворян кызлары уку йорты өчен төзелгән була. 1917 елның октябрь аенда уку йорты Новочеркасска күчкәч, бинаны большевиклар басып

алалар һәм кораллы баш күтәрү штабына әйләндерәләр. 1917 елның Октябрь революциясеннән соң биредә беренче совет хөкүмәте – Халык комиссарлары советы (Совнарком) урнаша.

[6] *Шәриф Манатов* – Шәриф Әхмәтҗан улы Манатов (1887–1936), иҗтимагый һәм сәясәт эшлеклесе, башкорт милли хәрәкәтенең җитәкчеләренең берсе, Башкорт үзәк шурасының рәисе, журналист, шәрык белгече.

**Тарихи кыңгырау өзелде** *(Рәшид бабай үлде).* «Татарстан хәбәрләре» газетасының 1922 елгы 1 март (51 нче) санында «Галимҗан Ибраһимов» имзасы белән басылган.

[1] *Ибраһим мирза Терегулов* – мәгърифәтче, педагог, дәүләт киңәшчесе Ибраһим Вәлиулла улы Терегулов (1852–1921).

[2] *Дәрдемәнд* – шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, иганәче Мөхәммәтзакир Мөхәммәтсадыйк улы Закиров (1859–1921).

[3] *Габдулла Буби* – педагог, җәмәгать һәм мәгърифәт эшлеклесе Габдулла Габделгалим улы Нигъмәтуллин-Буби (1871–1922).

[4] *Рәшид казыйның вафатын белдерделәр.* – Татар сәясәтчесе, дин әһеле Габдрәшит Ибраһимов 1857 елда Тубыл вилаятенең Тара шәһәрендә туып, 1944 елны Япониянең Токио шәһәрендә вафат була. 1922 елны татар дөньясында «Р. Ибраһимов үлгән» дигән ялгыш хәбәр тарала. «Татарстан хәбәрләре»нең 1922 елгы 24 февраль (46) санында «Казан хәбәрләре» исеме астында «Рәшит казый белән шагыйрь Вакыйф Җәлал үлгәннәр» дигән хәбәр басыла. Әлеге белдерү түбәндәгечә була: «Ташкентта чыга торган «Кызыл Байрак» гәзитәсенең язуына күрә, Рәшит казый белән шагыйрь Вакыйф Җәлал үлгәннәр. Рәшит казый 1919 елның көзендә Муса Бигиев һәм Һиндлы Әш-Шәйх Бәрәкәтулла илә берлектә Казан аркылы Төркестан, Әфганстан тарафларына киткән иде. Ул шуннан Япониягә барып, аннан кире Һиндстанга кайтып, Төркия аркылы Европага барып чыккан булган икән. Беркадәр вакытлар Европаның төрле мәмләкәтләрендә сәяхәт итеп йөргәннән соң, Швециягә кайтып вафат булган. Бу кадәресе «“Кызыл Байрак” хәбәре». Алга таба язмада: «Бәгъзе бу Сибириядән кайтучы кешеләр узган ел аның гаиләләре белән Сибириядә Тара шәһәрендә булганлыгын сөйлиләр. Бу хәбәрнең кайсысының дөрес икәнлеге хәзергә ачык мәгълүм түгел», – дип, «Кызыл Байрак»та басылган хәбәр шиккә алына. Шулай булуга карамастан, Галимҗан Ибраһимов «Татарстан хәбәрләре»нең 1 март санында биредәге мәкаләне бастырырга уйлый.

[5] *Диҗлә* – Багдад шәһәрен урап агучы елга.

[6] *Җамал Әфганилар* – дини һәм сәяси эшлекле Җамалетдин Ибраһим улы әл-Әфгани (1838–1897). Исламны яңарту, төп асылына кире кайта-

ру һәм панисламизм хәрәкәтләренә нигез салучы, мөселман халыкларын милли-азатлык көрәшенә рухландыручы.

[7] *Мөхәммәд Габдеһ* – Мисырда мөселман яңарышының күренекле галиме, нашир Мөхәммәт Габдеһ (1849–1905). Коръән тәфсиренең күренекле мөәллифләренең берсе. Шәригатькә реформа ясауга зур тырышлык куя. Мисырның баш мөфтие (1899–1905).

[8] *Мидхәт паша* – Госманлы дәүләт эшлеклесе Әхмәт Мидхәт паша (1822–1884).

[9] *Гаспринский* – мәгърифәтче, нашир һәм сәясәтче Исмәгыйль Гаспринский (Гаспралы, 1851–1914).

[10] *Мәрҗани, Курсавилар... уянган миләрнең мәгълүмрәге, көчлерәге иде.* – XIX гасырда татар мәгърифәтче галимнәре: Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗани (1818–1889) һәм Габденнасыйр Курсави (1776–1812).

[11] *Рәшидләр, Ризалар, Баязитлар, Ибраһим Мирзалар, Габәшиләр...* – XX гасыр мәгърифәтчеләре Габдерәшит Ибраһимов (1857–1944), Ризаэддин Фәхреддинов (1859–1936), Гатаулла Баязитов (1846–1911), Хасангата Габәши.

[12] *Бөтен гомерен әле Себердә, әле Уфада, Казанда, Питерда, Каһирәдә, Җәзаирдә, Истанбулда, Калькуттада, Багдадда йөреп, «Бетәбез, уяныгыз!» дип кычкырып үткәрде.* – Габдрәшит Ибраһимов 1895 елда Россиядән китә һәм Төркиягә барып урнаша. Аннан аның дөнья тирәли беренче сәяхәте башлана. Өч елга сузылган бу сәяхәтендә ул Мисырда, Хиҗазда, Фәләстыйнда, Италия, Австрия, Франция, Болгария, Сербиядә, Кавказда, Урта Азиядә, Төркестанда, Япониядә була. Бу сәяхәтнең төп максаты – дөнья халыклары, бигрәк тә мөселман илләре белән танышу, аларга Россиядә бер хокуксыз яшәүче төрки-мөселманнар турында хәбәр җиткерү, татар бәйсезлеге һәм ислам берлеге өчен көрәштә юлдашлар табу, соңыннан болар хакында язып чыгу була.

[13] *Аның каршында «мөселманнар бер милләт» булган кебек «кяфер дә – милләт вахидә»...* – Биредә «милләт» дигән сүз төп мәгънәдә кулланылмый. Сүз ике цивилизация турында бара: ислам дине берләштергән мөселман бердәмлеге (цивилизациясе) һәм аңа каршы булган кяферләр бердәмлеге.

[14] *Мусалар, Зыялар, Бубилар моны дәвам иттерделәр.* – Биредә татар дин белгече, философ, публицист Муса Бигиев (Муса, Ярулла, 1873–1949); мәгърифәтче, философ, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, мәдрәсә мөгаллиме Зыя Җамалетдин улы Камалетдинов (Зыя Камали, 1873–1942); «Буби» мәдрәсәсе җитәкчеләреннән педагог, җәмәгать һәм мәгърифәт эшлеклеләре, бертуган Гобәйдулла (1866–1938) һәм Габдулла Нигъмәтуллин-Бубилар (1871–1922) күздә тотыла.

[15] *Фуад – Гаяз компаниясе* – 1906–1907 елларда Казанда «Таң йолдызы» исемле газета чыгарып, шуның тирәсенә оешкан татар эсерлары төркеме – «таң»чылар күздә тотыла. Башлап йөрүчеләре: Гаяз Исхакый, Фуад Туктаров, Сәгыйть Рәмиев, Шакир Мөхәммәдъяров.

